ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР НӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№7 (366)
ИЮЛЬ 2022

АЗЫК-ТӨЛЕККӘ КЫТЛЫК БУЛМАЯЧАК



ПАРТНЕР
СӘҮДӘ ЙОРТЫ

Кошчылык һәм терлекчелек комплексларын авыл хуҗалыгы хайваннары өчен азык һәм азык өстәмәләре, түп, шрот, ашлык бөртеге һәм көшел калдыгы белән тәэмин итә

АЗЫК ӨСТӘМӘЛӘРЕ

Көнбагышның майсыз түбе (протеин 39%)
Сояның майсыз түбе (протеин 48-50%)
Көнбагыш түбе (протеин 30-32%)
Рапс түбе (протеин 36-38%)
Житен түбе (протеин 36-38%)
Рапс түбе (протеин 36%)
Тулы майлы соя (протеин 36%)
Монокальцийфосфат
Көнбагыш мае (чистартылмаган)
Рапс мае (чистартылмаган)
Үлән оны (гранулаларда)
Азык чүпрәсе
Спирт калдыгы
Фураж кукурузы (ГОСТ)
Бодай
Арпа

ӘЗЕР ПРОДУКЦИЯ

Шикәр
Карабодай
Тары ярмас
Борчак

«ПАРТНЕР СӘҮДӘ ЙОРТЫ» ҖЧҖ
Тел.+7 (937) 523-70-50, +7 (937) 775-23-33
Адрес: Казан ш., Мәскәү ур., 60, К43 б.
E-mail: partner.116@yandex.ru

WWW.PARTNERKZN.RU

Реклама

САТАБЫЗ
ҺӘМ САТЫП АЛАБЫЗ

ПАРТНЕР ЭКСПОРТ

Майлы, кузаклы, техник культуралар, берьеллык һәм күпьеллык үлән орлыклары белән тәэмин итә

БӨРТЕКЛЕЛӘР

КАРАБОДАЙ
ТАРЫ
СОРГО (МИСЫР ТАРЫСЫ)
БОРАЙ

КУЗАКЛЫЛАР

ВИКА (ТОРНА БОРЧАГЫ)
ЯСМЫК
НУТ (БӘРӘН НОГЫТЫ)

МАЙЛЫ КУЛЬТУРАЛАР

МАЙЛЫ ТОРМА
ГОРЧИЦА
МАЙЛЫ ҖИТЕН
КОРИАНДР
САФЛОР
ШЕПКӘН
РАПС

ҮЛӘННӘР

ЭСПАРЦЕТ
ФАЦЕЛИЯ
СОЛЫЧА
АЙРАВЫК
ТУКРАНБАШ
КОСТРЕЦ
ЛЮЦЕРНА
РАСТОРОПША
АРЫШБАШ
ЛЯДВЕНЕЦ
ЙОНЧА

«ПАРТНЕР ЭКСПОРТ» ҖЧҖ
Тел.+7 (996) 902-00-80, +7 (937) 523-70-50
Адрес: Казан ш., Мәскәү ур., 60, К43 б.
E-mail: partner-export@yandex.ru
WWW.PARTNER-EXPORTKZN.COM

Реклама

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская,
Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Сафа Гәрәев, Ксения Сёмина, Фаяз Хуҗин,
Луиза Шарова
Фотографлар: Динара Гобәйдуллина, Александр Ефремов,
Алсу Шакирова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Аксубай районы Иске Ибрай авылы фермеры
Марат Сафин.
Алсу Шакирова фотосы.

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.
Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: О–2029
Басарга кул куелды: 07.07.2022
Басмадан чыкты: 13.07.2022

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

КАРАБОДАЙ САТЫП АЛЫП ТАГЫН АШЫКТЫК, АХРЫСЫ

Һава торышы начар килгән ел булсынмы, сәяси тотрыксызлыкмы – безнең халык гадәттәгечә, берсеннән-берсе уздыра-уздыра, кибеткә карабодайга йөгерә. Кирәкме-кирәкмиме – анысы мөһим түгел. Һәм бары тик сандыгы тулып, инде гаиләсенең ач калмаячагын аңлагач кына тынычлана – кулына «Татарстан» журналын алып, азык-төлек мәсьәләләренә караган бөтен сорауларына җавап эзли. Язмаларыбыз белән танышып чыкканнан соң, тагын карабодайны артыграк алып ташлавын аңлый. Чөнки «Товарларның булуына, аларны кайтартуга бәйле проблемалар да юк. Азык-төлек куркынычсызлыгы мәсьәләсенә зур игътибар бирелә», – дип ышандыра ТР авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров. Инде хәзер ул карабодайны кая куярга?

Моннан тыш, «Татарстан»ның яңа саны бүген безнең нинди ризык ашавыбыз һәм нәрсә эчүебез турындагы сорауларга да җавап бирә. Чит илләрдән керә торган орлык һәм әчетелгән сөт бактерияләрен нәрсә белән алыштырырга? Һәм, әлбәттә, бүгенге көндә Татарстан чит илләргә нинди азык-төлек продуктлары чыгара ала?

Укыгыз һәм паникага бирелмәгез. Барысын да яхшы булыр.

Сезнең оптимист һәм реалист редакциягез.

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзүм Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **963 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 101 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 ҖӘҮҺӘРЕ

бары тик ТАТАРСТАНДА

ФӘЛСӘФИ АЛМАЛАР ТӘМЕ

Зөя утрау-шәһәрендә кайчандыр язучы Лев Толстой ярататып ашаган алмаларны татып карап була торган почмак бар. Бу 10 ел элек утыртылган алмагач бакчасы: 40 алмагач үсентесен бирегә язучының Ясная Полянадагы утарыннан алып киләләр. Утрауда Толстой почмагының пәйда булуы очраклы хәл түгел: язучы бабасының әтисе Андрей Толстой XVIII гасырда Зөя каласында воевода булып хезмәт итә. Бакчага «Уйланулар бакчасы» дигән исем дә очраклы гына бирелмәгән. Монда сез төрле чорларда яшәгән күренекле кешеләрнең сүзләрен табарсыз. Күпчелеге – Лев Толстойның «Круг чтения» китабы өчен җыелган гыйбарәләр. Шундыйларның берсе: «Тормыш – уңышсызлык уңышка караганда яхшырак укытучы булган мәктәп».

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр
ТӨП ТЕМА

6. Азык-төлек куркынычсызлыгы
Аны тәэмин итәргә хәлебездән киләме

10. Тәмле һәм сәламәт ризык турында
Ни өчен сыйфатлы ризык һәрвакытта да файдалы түгел

16. Альцгеймердан дәва табылганмы?
Шәмәхә бодайның сере нидә

22. Ит бәясе
Сыер ите җитештерүне ничек арттырырга

26. «МИРОВЕТ» рецепты
Тәмле диетик итне ничек алырга

28. Әчетелгән сөт ризыклары
Чит ил бактерияләрен нәрсә белән алыштырырга

38. Татарстанда җитештерелгән
Республика дөньяны нинди азык-төлек белән тәэмин итәргә сәләтле

игелекле эшләр

44. Җирдәге иң шәп урын
Ни өчен сарманлылар матуррак җырлый

46. Бар да чәчәк ата һәм гөрләп үсә торган як
Кайсы районда иң сөйкемле җирлек башлыклары яши

49. Өлкәннәр үрнәге
103 яшьтә дә ничек модадан калышмаска

52. Җәлил һәм җәлилләр...
Сурәтләргә төшерерлек бистә турында

54. Бәйрәмнәр тәме
Подкогольо белән кайда сыйлыйлар

62. Башлык үткәргән экскурсия
Лениногорскида кунакта

мәңгелек кыйммәтләр

76. Курсави һәм Әмирхан эзен саклаган мәчет
«Иске Таш» мәчете кай ягы белән күренекле

78. Ислам дине кабул ителүгә 1100 ел
Багдад осталары – Биләрдә

82. Китап киштәсе
Галим-археолог Фаяз Хуҗин нәрсәләр укый

86. Татарстан авыллары
Бай тарихлы Иске Ибрай

96. Ай кәефе
«Татарстан» журналы Истанбулны яулый

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Акыллы гамәлләр

16.06

Дмитрий Чернышенко, РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары, – XXV Петербург халыкара икътисадый форумында, Казан Киләчәк уеннарын уздыру хокукына ия булганнан соң:

– Татарстанның тарихта беренче мәртәбә Киләчәк уеннарын уздыру кебек мактаулы хокукка ирешүе белән котлыйбыз. Бу чыннан да лаеклы җиңү – шәһәр инде күптәннән илнең иң көчле спорт төбәкләренең берсенә әверелде. Татарстан клублары милли чемпионатларда да, халыкара дәрәҗәдә дә иң югары урыннар өчен көрәшә. Уеннар ачылырга ел ярымнан бераз гына күбрәк вакыт калды. Без моңа кадәр беркем дә эшләп карамаганны башкарып чыгарга тиеш. Бу, һичшиксез, җитди бурыч. Казан Уеннарны шәп итеп оештырыр һәм зур спорт чараларын үткәрү буенча яңа стандартлар үрнәге күрсәтер, дип ышанам.

Игелекле эшләр

08.06

Александр Усков, «Август» компаниясенең генераль директоры, – яңа элеватор төзелеше башланган Зөя төбәкара мультимодаль логистика үзәге территориясендә:

– Татарстанда Россия өчен уникаль инвестицияле климат урнашкан. Биредә проектларны тиз арада тормышка ашырып була. Шуңа күрә инвесторларга тудырылган мөмкинлекләр өчен зур рәхмәт. Без бүген башлап җибәргән проект республика авыл хуҗалыгын үстерүгә зур өлеш кертер, дип өметләнәм.

Мәңгелек кыйммәтләр

12.06

Гөлзадә Руденко, Алабуга музей-тыюлыгы генераль директоры, – Зур Кремль сараеның Георгий залында, Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә дәүләт премиясе алганнан соң:

– Россия – чыннан да искиткеч мөмкинлекләр иле. Мин Мәскәүдән мең километр ераклыкта урнашкан, 80 мең халкы булган үзебезнең кечкенә генә Алабуганы мисал итеп китерәсем килә. Соңгы 20 ел эчендә Алабуга кайчандыр ташландык хәлдә диярлек калган шәһәрдән Россия Федерациясенең иң шәп туристлык Мәккәләренең һәм иң нәтиҗәле махсус икътисадый зоналарының берсенә әверелде.

Фото: @Рамил Ситдыйков/«Яңалыклар» РМА, agbz.ru, Солтан Исхаков/tatar-inform

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

акыллы гәмәләр /

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

ТӨП ТЕМА

Бу санда тәкъдим итәбез:

Республикада азык-төлек куркынычсызлыгын **НИЧЕК** тәэмин итәргә

Без **НӘРСӘ** ашыйбыз һәм эчәбез

Сыер ите җитештерүне **НИЧЕК** арттырырга

Әчетелгән сөт бактерияләрен **НИЧЕК** алыштырабыз

Татарстан дөньяга **НИНДИ** азык-төлек тәкъдим итә ала

АЗЫК-ТӨЛЕК КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ: МӨМКИНЛЕКЛӘР

Сафа Гәрәев

Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре өчен сәяси тотрыксызлык һава торышы сюрпризлары кебек үк җитди сынау. Һәр ике очракта да, форс-мажор яки объектив сәбәпләр дип, бернинди ташламалар да ясалмый. Әмма теләсә кайсы шартларда да халык сыйфатлы һәм куркынычсыз азык-төлек белән тәэмин ителергә тиеш. Үзәктә – безнең азык-төлек куркынычсызлыгы.

Март аенда кибет киштәләрен бушатырга омтылган ыгы-зыгы дулкыны, бәхеткә, давылга әйләнмәде, бары тик кайбер бәяләрне генә үзгәртте. Асылда, бу безнең ресурсларга юнәлтелгән җитди тикшерү булды, һәм без аны уңышлы гына үтә алдык. Беренчедән, иң кирәкле әйберләрне гадәттә Татарстанда һәм үзебез өчен җитәрлек күләмдә җитештерәбез. Икенчедән, күп тапкырларга арткан, бик үк адекват булмаган ихтыяҗга да дөрес мөнәсәбәт күрсәтә алдык.

Май аенда Хөкүмәт йортында узган видеоконференциядә ТР вице-премьеры – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров болай дип аңлатты: «Ажиотажга бәйле вазгыятьне тотрыклыландыруга, шул исәптән социаль өлкә һәм икмәк пешерү предприятиеләре ихтыяҗлары өчен Татарстан Президенты күрсәтмәсе буенча төзелгән шикәр һәм он запасларының резерв фонды хисабына да ирешелде». Авыл хуҗалыгы ярминкәләрен уздыру да булышкан. Министр сүзләренә караганда, аларда, узган ел белән чагыштырганда, шикәр комы, суган, кишер – ике, ә бәрәңге дүрт тапкырга күбрәк сатылган. Сатарга китерелгән продукциянең гомуми бәясе 500 млн сумнан артып киткән.

– Хәзерге вакытта халыкта азык-төлек продукциясенә булган мондый ихтыяҗ тынды. Товарларның булуына, аларны кайтартуга бәйле проблемалар да юк, – дип ышандырды Марат Җәббаров. – Азык-төлек куркынычсызлыгы мәсьәләсенә зур игътибар бирелә.

Аңлашыла, яңа чынбарлык – яңа таләпләр. Без аларга ничек җавап бирәчәкбез соң? Санкцияләр, җәйләнгән логистик элемтәләрне бозу – көңелле күренеш түгел. Бәлки, аграрийлар, башка тармак вәкилләреннән аермалы буларак, аларның кискенлеген әле тулысынча тоеп өлгермәгәндер, әмма алга таба вакыйгаларның ничек үзгәрәчәген белмибез. Аңлашыла ки, бу вазгыятьтә үзгәрешләргә эш үткәннән соң җавап биргәнче, аларны кисәтү яхшырак.

ИМПОРТНЫ АЛЫШТЫРУ

– Хәзерге шартларда азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү тагын да актуальләшә бара. Татарстанда импортны алыштыру һәм үзебезнең җитештерүләрне саклап калуга юнәлеш алынган – бу сүзләрне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кичә генә түгел, моннан җиде ел элек әйткән иде. Әлеге сүзләр аграрийларның санкцияләр китереп чыгарган авырлыкларны ни өчен үз көчләренә ышанган хуҗалар кебек тыныч каршы алуын аңлата, дип уйларга урын бар. Көнбатыштагы «партнерларның» төрле явыз ниятләре сюрприз буларак кабул ителмәде, аңа шактый җитди әзерлек үтелгән иде.

Быелгы чәчүгә күз салыйк: кырык процентка якын кырга оригиналь һәм элиталы орлык чәчелгән. Контракт буенча кайтарылырга тиешле орлыклар тулысынча һәм вакытында алынган. Яшелчә һәм техник культура орлыкларына килгәндә исә, монда да кул кушырып утырма-

Фото: Александр Ефремов

ганнар: импортка бәйлелекне булдырмас өчен, үсемлекләрне саклау чаралары һәм орлык белән үзебезнең тәэминатчылар эзләп табылган, аларның реестры төзелгән.

Татарстан селекционерлары хәзер Белоруссия белән уҗым культуралары селекциясе өлкәсендә тыгыз хезмәттәшлек итә, уртак тырышлык нәтиҗәләренең берсе – көзге «Бета» тритикале сорты булдырылган. Белоруссиянең бәрәңгечелек һәм яшелчәчелек буенча Милли фәннәр академиясе белән селекция өчен башлангыч материал алмашу бәрәңгенең «Догода» дип аталган яңа сортын чыгарырга мөмкинлек биргән, хәзерге вакытта бу сорт буенча дәүләт сынаулары үткәрелә.

Техникага күз салганда, запас частьләр белән тәэмин итү тукталган очракта да, Татарстанда чит ил комбайннары паркына (ә андыйлар бездә аз түгел - комбайн паркының өчтән бере диярлек) куркыныч янамый. Монда да республика алдан уйлап эш иткән: ТР предприятиеләре чит ил техникасы һәм җиһазлары өчен ике меңгә якын төрдәге запас часть эшләп чыгаруны һәм ремонтлауны җайга салган.

РЕЗЕРВЛАР МӨМКИНЛЕГЕ

Санкцияләр аркасында ихтимал булган югалтуларны киметү – алда торган бурычларның берсе генә. Тагын да мөһимрәге – аграр секторда үз потенциалыбызны (ә ул, асылда, чиксез) куллана белү. Ничек кенә парадоксаль тоелмасын, Татарстанда җитди корылык булган узган елны мисалга алырга буладыр. Гадәттән тыш һава шартларында аграрийлар 2,4 миллион тонна ашлык җыеп ала алды. Игътибар: корылыклы 2010 ел белән чагыштырганда, өч ярым тапкырга диярлек күбрәк. Бу нәрсә, очраклылыкмы? Юк, элек файдаланылмаган резервларны эшкә җигү. Аерым алганда, дым саклау технологияләре, тиешле күләмнәрдә минераль ашлама кертү ярдәм итте.

Киресенчә, эшне оештырудагы җитешсезлекләрнең бөтенләй мәҗбүри булмаган проблемалар китереп чыгаруына да мисаллар бар. Узган елның язын – чит илдә түгел, үзебездә үстерелгән сезонлы яшелчәләргә бәяләрнең кинәт үсеп киткән вакытны искә төшерик. Ул чакта барысын да алдан фаразланмый торган базар конъюнктурасына сылтау иң җиңеле булыр иде. Ләкин ныклап тикшергәннән соң урыннарда җибәрелгән кайбер җитешсезлекләр ачыкланды. Соңрак Татарстан Президенты үзенең октябрь Юлламасында аларны хәл итүнең гади, әмма үтемле юлларын атады: «Киләчәктә мондый хәлләрне булдырмас өчен, яшелчә утырту күләмен арттырырга гына түгел, продукцияне эшкәртү һәм саклау буенча тиешле инфраструктура булдырырга, шулай ук артык авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу юнәлешендә дә халык белән актив хезмәттәшлек итәргә кирәк. Моның белән көз көне генә түгел, ә ел дәвамында шөгыльләнергә тиешбез».

Юлламада билгеләнгән бурыч тулысынча хәл ителсә, татарстанлыларга язын шул ук бәрәңгене мандарин бәясеннән сатып алырга туры килмәс – аны җитештерүне арттыру өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Өстәвенә, тәҗрибә шуны раслый: азык-төлек куркынычсызлыгы максатларын гамәлгә ашыру өчен федераль үзәк тә, республика да хәтта иң катлаулы вакытларда да кирәкле ресурсларны таба, акчаларны дөрес тоту, шулай ук проблемаларны хәл итү – аерым контроль астында. Конкрет мисал. Быел гарантияле уңыш алу өчен, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы алдына бер гектарга 70 килограммнан да ким булмаган күләмдә исәпләнгән минераль ашлама запасын булдыру бурычы куелды. Йөкләмәнең үтәлеше бишлелек: аграрийлар активында – гектарына 72,1 кг тәэсир итүче матдә.

НӘРСӘЛӘРЕБЕЗ БАР

Орлыкларның сыйфаты, ашламалар, уңдырышлылык һәм сөтчелектәге нәтиҗәлелек турында күпме генә сөйләсәк тә, татарстанлыларның күпчелеге аграр өлкә мөмкинлекләрен үзебездә нәрсә һәм күпме күләмдә үстерелүе, җитештерелүе күзлегеннән чыгып бәяли. Биредә нәтиҗәләр күз алдында.

Терлекчелек продукциясе: үзебезне тулысынча тәэмин итәбез. Татарстан элеккечә үк сөт җитештерү күләме буенча Россия Федерациясендә беренче урында тора: дүрт айда 615 мең тоннадан артык сөт савып алынган, бу – узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда күбрәк. 162 мең тоннага якын терлек һәм кош ите сатылган, шулай ук узган ел күрсәткеченә караганда артыграк. Йомырка җитештерү: биредә дә уңай динамика – узган елга карата плюс 10 миллион данә.

Сөендерми кала алмый торган тагын бер тенденция: авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү 8 процентка үскән. Татарстанда атланмай, эшкәртелгән сөт (балалар ризыгын да кертеп), әчетелгән сөт продукциясе, ярмалар күбрәк җитештерелә башлаган. Аңлашыла ки, үзебездә эшкәртү – өстәмә керемнәрдән тыш, бәяләр үсешен тоткарлау ягыннан да мөһим күрсәткеч. Өстәвенә, җирле продуктлар, кагыйдә буларак, тәмлерәк тә, сыйфатлырак та. Республикада җитештерелгән товарларга өстенлек бирүче татарстанлыларның күбәюе – моңа бер дәлил.

Кибет киштәләрендә үзебездә җитештерелгән товарларның тагын да күбрәк һәм сыйфатлырак булачагына шикләнергә урын калмый. Мөслим районында 2400 башка исәпләнгән сөт комплексының икенче чираты төзелеп килә, Минзәләдә 6000 башка исәпләнгән сөт комплексы корыла һәм 2400 башка исәпләнгән тагын берсенә нигез салынган. Әлки районында 1200 башка исәпләнгән сөт комплексы сафка басарга тора. Мамадыштагы «Азбука сыра» заводы, Касыймов сөт комбинатының «Ува молоко» предприятиеләренең куәтләре арта бара...

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ТАРМАГЫНДА ТОТРЫКЛЫ НӘТИҖӘЛӘРГӘ ИРЕШҮДӘ ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕ МӨҺИМ РОЛЬ УЙНЫЙ. Агымдагы елда бу максатларга 13,3 млрд сум акча каралган, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабыннан – 3,9 млрд сум, республика бюджетыннан – 9,4 млрд сум.

ТАТАРСТАН.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ САННАР ҺӘМ ФАКТЛАРДА

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ПРОДУКЦИЯСЕН ҖИТЕШТЕРҮ

ТРның И(б)ФО субъектлары арасындагы урыны		ТРның РФ субъектлары арасындагы урыны	
2019	**1**	2019	**4**
2020	**1**	2020	**4**
2021	**1**	2021	**7***

ҖИТЕШТЕРЕЛГӘН БАРЛЫК АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ПРОДУКЦИЯСЕ,

млн сум.

2019	**248781,2**
2020	**264328,7**
2021	**237156,3**

Шул исәптән үсемлекчелек продукциясе

2019	**124249,6**
2020	**136511,2**
2021	**94239,5**

Терлекчелек продукциясе

2019	**124531,6**
2020	**127817,5**
2021	**142916,8**

* Татарстан корылык сынавын узды.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ КУЛЬТУРАЛАРЫНЫҢ ТУЛАЕМ ҖЫЕМЫ

Бөртеклеләр (эшкәртелгәннән соңгы авырлыкта),	мең тонна
2019	**4167,9**
2020	**5200,8**
2021	**2353,0**

Шикәр чөгендере (фабрика)	мең тонна
2019	**2804,4**
2020	**2150,8**
2021	**1341,0**

Бәрәңге	мең тонна
2019	**1214,1**
2020	**1174,2**
2021	**871,3**

Ачык һәм ябык грунтта үстерелгән яшелчәләр	мең тонна
2019	**343,9**
2020	**325,8**
2021	**258,6**

ТӨП ТЕРЛЕКЧЕЛЕК ПРОДУКТЛАРЫН ҖИТЕШТЕРҮ

Сугымга үстерелгән терлек һәм кош-корт, сугым авырлыгында	мең тонна
2019	**349,1**
2020	**357,0**
2021	**366,0**

Сөт	мең тонна
2019	**1896,1**
2020	**1942,6**
2021	**1958,7**

Йомырка	млн данә
2019	**1501,8**
2020	**1468,8**
2021	**1512,8**

РОССИЯНЕҢ СӨТ ҖИТЕШТЕРҮ БУЕНЧА БЕРЕНЧЕ БИШ ТӨБӘГЕ**

	мең тонна
1. Татарстан	**1958,7**
2. Башкортостан	1614,1
3. Краснодар крае	1526,2
4. Алтай крае	1152,2
5. Ростов өлкәсе	1098,2

** *2021 ел өчен Росстат мәгълүматлары буенча.*

Фотолар Роспотребнадзорның ТР буенча идарәсе матбугат хезмәтеннән, «Татарстан» журналы архивыннан алынды.

МАРИНА ПАТЯШИНА: «ЯХШЫ СЫЙФАТЛЫ АШАМЛЫК ҺӘМ СӘЛАМӘТ РИЗЫК – ИКЕСЕ ДӘ БЕРДӘЙ КИРӘКЛЕ НӘРСӘ»

Ольга Туманская әңгәмәсе

«Иттә – антибиотиклар, кош итендә – үстерү гормоннары, сөттә – терлек мае...» Бу турыда сөйләшмәгән кеше юктыр да инде хәзер. Халыкның җитештерүчеләр тәкъдим иткән азык сыйфатына карата сораулары бик күп. Без үзебезне борчыган сорауларга абруйлы белгеч – Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсе җитәкчесе – Татарстан Республикасының баш дәүләт санитар табибы Марина Патяшинадан җавап бирүен үтендек.

– Марина Александровна, барысы да шулкадәр куркынычмыни? Татарстанда ашамлыклар сыйфатын контрольдә тоту вазгыяте ничегрәк?

– Яшермим, ашамлык җитештерүченең үз продукциясенә төрле зыянлы өстәмәләр (шул исәптән антибиотиклар һәм үстерү көйләгечләрен) кушу ихтималы чыннан да бар. Моннан берничә ел элек кенә безнең лабораторияләрдәге тикшерүләр вакытында ризыкка кушылган бик аз матдәне генә ачыклап була иде. Җитештерүчеләр исә, гел бездән алдарак барып, киресенчә, яңадан-яңа зыянлы өстәмәләрне уйлап чыгара торды. Бүген бу проблема хәл ителде инде. «Җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» феде-

раль проекты кысаларында Россиянең бөтен лаборатория үзәкләренә, шул исәптән безнең Татарстан Республикасындагы Гигиена һәм эпидемиология үзәгенә дә югары технологияле җиһазлар сатып алынды, алар азык продукциясендәге бик күп матдәне ачыкларга сәләтле. Сүз 60 төрле пестицид, 6 төркем антибиотик (составында күрсәтелмәгәннәрне дә кертеп), азык җепселләре һәм хәзер бигрәк тә актуаль һәм мөһим нәрсә – җитештерүче маркировкада күрсәтмәгән матдәләр турында бара. Мәсәлән, микроблы трансглютаминаза («ит җилеме» дип тә йөртәләр) – аны ит һәм балык продукциясенең тышкы кыяфәтен матурайту өчен еш кулланалар. Яки хәзер бик «модалы» азык өстәмәсе – «тәмне көчәйткеч» глутамин кислотасы тозы.

– Мондый көтелмәгән табылдыклар еш очрыймы соң?

– Бәхеткә, алар күпләп очрый, дип әйтә алмыйм. Мәсәлән, былтыр без иттә һәм итле ярымфабрикатларда антибиотик табылган нибары ике фактны ачыкладык. Ә безнең тикшерүләребезнең колачы шактый зур – ел саен якынча 80 меңләп проба алабыз. «Демография» проекты кысаларында «көтелмәгән табылдыкларның» шактый өлеше итчелек һәм кошчылык продукциясенә туры килә – аларда 19 стандарт булмаган проба ачыкланды, шулай ук балык продуктларында – 11, бөртектән эшләнгән иртәнге ашларда 10 шундый проба табылды. Бу йә гигиена нормативларын бозу, йә кулланучыга тәгаенләнгән маркировкадагы мәгълүматларга тәңгәл килмәү. Сүз безнең Татарстан җитештерүчеләре турында гына бармый. Кагыйдә бозуларның 71 проценты башка төбәкләрдә җитештерелгән продукциягә, 7 проценты чит ил җитештерүчеләренекенә туры килә.

«ИҢ КУРКЫНЫЧ НӘРСӘ» ТУРЫНДА

– Сез, хәзер продукциядә күрсәтелмәгән антибиотикларны ачыклый алабыз, дидегез. Ә аларның күрсәтелгәннәре дә буламыни?

– Ачыклык кертеп, аңлатып узам. Мәсәлән, без колбасаны анда антибиотиклар барлыгына тикшерәбез, ди. Эшне чималның документларын өйрәнүдән башлыйбыз. Мисалга, сыер итен алыйк. Ветеринария белешмәсендә хайванны левомицетин белән дәвалаулары, әмма сугымга ике атна кала әлеге дәвалауны туктату хакында хәбәр ителә. Мондый иттән колбаса ясарга ярый. Колбасаны тикшергәч, анда левомицетин табылмый, әмма тетрациклин табыла. Каян килгән ул колбасага? Димәк, чимал җитештерүче әлеге фактны яшергән, ә безнең лаборатория, киресенчә, ачыклаган булып чыга. Элек, югары технологияле лабораториябез булмаганда, безнең күрсәтелмәгән антибиотикларны табу мөмкинлегебез юк иде, хәзер исә бик төгәл ачыклый алабыз.



– Җәмгыятьтә бигрәк тә ГҮО (ГМО) – геннары үзгәртелгән организмнардан курку бар. Россиядә аларны файдалану тыела. Сезнең идарә әлеге тыюны бозучыларны туктатырга сәләтлеме?

– Без бу мәсьәләгә аеруча игътибар бирәбез. 17 ел дәвамында безнең экспертлар азык продуктларындагы ГҮОны ачыклау өчен ел саен меңгә якын проба ала. Әмма без аны соңгы тапкыр 2010 елда, Яшел Үзән районындагы төрек хосусый икмәк пешерүче кулланган Platin порошогында ачыклаган идек. Шуннан бирле бер генә тапкыр да очрамады. Шунлыктан ризыктагы геннары үзгәртелгән организмнарга кагылышлы бәхәс һәм куркулар нигезсез, дип ышанып әйтергә була.

АЗЫК СӘНӘГАТЕ ӨРӘКЛӘРЕ

– Роспотребнадзор мәгълүматлары буенча, Россиядә фальсификацияләнгән продуктлар рейтингында беренче урында консервлар, икенче урында сөт һәм сөт продуктлары тора...

– Узган ел безгә Татарстан җитештерүчеләренең Россия территориясендә ачыкланган фальсификацияләнгән сөт продукциясе турында 19 факт мәгълүм булды. Билгеле, маркировкада күрсәтелгән адресларда бернинди җитештерү дә урнашмаган иде. «Өрәк-предприятиеләр» исемлегенә исә «Сыродельный концерн Алексеевский», «Продуктовая База №1», «Гудпродукт», «МилкОпт» һәм Чирмешән районындагы сыр заводы өстәлде. Сыйфатсыз һәм куркыныч продукция сәүдә әйләнешеннән алынды. Быел да вазгыять әллә ни үзгәрмәде. Безгә илнең башка төбәкләреннән мондый мәгълүмат килә тора. Хокук саклау органнарына оператив-эзләү чаралары үткәрү өчен без инде 14 материал җибәрдек.

– Болары ялган продукция бит. Ә Татарстандагы «рәсми» сөт продуктларының сыйфаты турында нәрсә әйтеп була?

– Биредә хәлләр күпкә яхшырак. 2021 елда без Татарстан җитештерүчеләренең сөт продукциясе микробиологик күрсәткечләре буенча техник регламентлар таләпләренә туры килмәгән нибары 3 очракны ачыкладык. Менә алар: Арча районындагы «Деревенские продукты» компаниясенең «Деревенский» сыры, Бөгелмә сөт комбинатының пастеризацияләнгән сөте һәм Яр Чаллыдагы «Славица» туңдырма фабрикасының сыр тәме килә торган «Сырное» туңдырмасы. Быел балаларга белем һәм тәрбия бирү оешмасын тикшергәндә тагын бер тәртип бозучыны таптык – Түбән Кама сөт комбинаты сөтендә эчәк таякчыгы һәм микроорганизмнарның саны нормадан артык булуын ачыкладык. Сәбәпләре берничә – җитештерү технологиясен бозудан башлап, инде продукцияне комбинаттан читтә саклау шартларын үтәмәүгә кадәр булырга мөмкин.

##ҺӘРКЕМ ҮЗЕ САЙЛЫЙ

– Безнең Россиядәге сыйфат стандартлары «сәламәт ризык» төшенчәсенә никадәр туры килә? Бигрәк тә сүз Көнбатышта күптән тыелып, Россиядә һаман рөхсәт ителгән куркыныч азык өстәмәләре турында барганда?

– Безнең әйләнә-тирәдә ризык күп. Әмма этикеткасындагы составында дистәләп буяу матдәсе һәм өстәмә күрсәтелгән ашамлыкны сәламәт дип атап буламыни? Без шуны аңларга тиеш: сәламәт ризык – табигый ингредиентлардан, бернинди химик өстәмәләрсез, кыздырмый-какламый, яңа гына әзерләнгән тәгам ул. Шунлыктан әйдәгез, «сәламәт ризык» һәм «ашамлыкның сыйфаты» төшенчәләренә ачыклык кертик. Сыйфат стандартлары турында сүз башлауга, без барыбыз да кайчандыр «кышкы салатка» салына торган «Докторская» колбасасын искә төшерергә яратабыз. Ә хәзер? Элек азык продукциясе ГОСТның катгый таләпләре буенча җитештерелгән, бүген исә бизнеска ТУ – техник шартлардан тайпылмау җитә. Бу менә нәрсә дигән сүз: җитештерүче үз продукциясендә теләсә нәрсә куллана ала, иң мөһиме, моның гамәлдәге нормативлар буенча куркынычсыз булуын дәлилләү шарт. Шунлыктан тәмне, төсне яхшырткычлар, саклану вакытын озайткыч өстәмәләр файдаланыла... Болар барысы бергә продукцияне арзанрак та итә. Шул ук Е142 буявы Туклану продуктлары җитештерүдә куллану рөхсәт ителгән азык өстәмәләре исемлегенә кертелгән, аның өчен гигиена нормативлары закон белән расланган. Җитештерүче аларны үтәргә тиеш, без исә аның никадәр җаваплы булуын тикшерү өчен лабораториядә контрольдә тотарга бурычлы. 2021 елгы тикшерүләр нәтиҗәләре буенча без Татарстан җитештерүчеләре продукциясендә азык өстәмәләрен гигиена нормативларыннан артыграк куллануны ачыкламадык. Бусы сыйфатка кагылышлы иде. Сәламәтлеккә килгәндә исә, һәркемнең сайлау мөмкинлеге бар: балага составында Е142 булган ниндидер ярымфабрикат сатып алумы яки табигый ингредиентлардан тәмле итеп үзең ашарга пешерүме. Сүз уңаеннан, бүген Роспотребнадзорга тагын бер вазыйфа йөкләнгән – туклану гигиенасына өйрәтү. Безнең белгечләр социаль учреждениеләр, хезмәт һәм хәтта балалар коллективларында сәламәт туклану принциплары турында лекцияләр укый. Алар анда кечкенә генә бер порция сосискада тәүлеклек тоз нормасы булуы, сохари һәм чипсылардагы глутамат, аңа тиз ияләшү һәм аннары инде нормаль ризык тәменең төче булып тоелуы хакында сөйли.

– Димәк, дәүләт стандартлары телендә ашамлыкларның сыйфаты – иң әүвәл аларның куркынычсызлыгы булып чыга. Бу очракта кулланучыга аның нинди критерийлар буенча билгеләнүен аңлау мөһим.

– Без ашамлык куркынычсызлыгы нигезендә яткан өч төп критерийны аерып күрсәтәбез. Иң әүвәл, бу биологик күрсәткечләр – гади генә әйткәндә, без әлеге ризыктан агуланмаска тиеш. Аннары продуктның химик составы – анда сәламәтлеккә зыян китерергә сәләтле азык өстәмәләре, антибиотиклар, пестицидларның тиешле гигиена нормаларыннан артмавы зарур. Ризык радиологик контроль җәһәтеннән дә куркынычсыз булырга тиеш. Һәм, әлбәттә инде, ашамлыкның сыйфаты хакында сөйләгәндә, безгә бик мөһим аспектны да онытмаска кирәк: аның составында маркировкасында күрсәтелгән ингредиентлар гына булу зарур. Кулланучыны беркайчан да алдарга кирәкми.

– Җитештерүчеләр гадәттә нәрсәне санга сукмый?

– Яңа мөмкинлекләребез кысаларында без азык продуктлары сыйфаты күрсәткечләренә 264 пробадан торган комплекс формалаштырдык. 2021 елда шундый 4878 тикшерү үтәрдек. 56 пробада (һәр бишенчесе) гигиена нормативларыннан тайпылу ачыкланды. Мәсәлән, кулланучы, суытылган балык сатып алганда, аның бер тапкыр да туңдырылмаган булуына өметләнә. Безнең экспертларыбыз исә ялганны фаш итә: бу балык әллә ничә тапкыр туңдырып эретелгән инде. Шулай ук тикшерелгән пробалардан күбесе маркировкадагы азык һәм энергетика кыйммәте күрсәткечләренә туры килми. Бу еш кына җитештерүченең продукт составына үзе күрсәтәсе килмәгән ингредиентны кертүе хакында сөйли. Аның маркировкалавы «үз тормышы» белән яши. Мәсәлән, бу сөт майларын үсемлек майларына алыштыру булырга мөмкин – намуссыз җитештерүчеләр шул рәвешле сөт, сыр, туңдырма һәм башка сөт ризыклары җитештерүне арзанайта. Әйе, мондый состав кыска вакыт эчендә генә безнең сәламәтлекне начарайтмый, тик шулай да бу ашамлыкның сыйфаты түбән булуын күрсәтә. Яки кайвакытта без микроблы трансглютаминаза – «ит җилемен» табабыз, ул ит һәм балык продукциясенең тышкы кыяфәтен матурайту өчен файдаланыла. Аның микъдары гигиена нормаларыннан артмаска да мөмкин, әмма бит бу матдә маркировкада күрсәтелмәгән, чөнки составында нибары һәркемгә аңлаешлы «сыер ите, су, шикәр, лимон кислотасы» булган продуктны сату әллә никадәр «куркыныч» өстәмә кушылган ашамлыкны сатуга караганда күпкә җиңелрәк.

НАМУС КОНТРОЛЬДӘН КУӘТЛЕРӘК

– Роспотребнадзор арсеналында югары технологияле лаборатория пәйда булу ваемсыз җитештерүчеләрне бераз куркыттымы? Әллә аларга, штраф түләп, һаман сыйфатсыз продукция сатып табыш алуны дәвам итү файдалыракмы?

– Техник регламентларны бозган өчен штрафлар шактый кесәгә сугарлык һәм 100 меңнән алып миллион сумга кадәр җитәр-

гә мөмкин. Без әле предприятие эшен 90 тәүлеккә туктатып тору хокукына да ия. Зур җитештерүнең тулы бер квартал буе эшсез утыруын күз алдыгызга китерә аласызмы? Бизнес бетте дигән сүз бит инде бу! Өстәвенә, без шундук чарасын да күрәбез – декларацияләрен алабыз, һәм әлеге продукцияне бөтен Россия Федерациясе территориясендә сату тыела. Шул рәвешле, илебездә гамьсез җитештерүчеләргә тәэсир итү чаралары шактый катгый.

– Алайса, ни өчен кибет киштәләрендәге ашамлыкларның сыйфаты идеалдан һаман ерак әле?

– Советлар Союзы чорында санитария-эпидемиология хезмәте бер үк предприятиегә бер ел эчендә берничә тапкыр килә алса, бүген күзәтчелекнең мондый вәкаләте юк. Сатыла торган продукциясенең төре һәм күләменә бәйле рәвештә, кемдер безнең күзгә ел саен чалына, кемдер ике елга бер тапкыр тикшерелә, ә менә, мәсәлән, кайсыдыр шәхси эшкуарда без биш елга бер дә булмаска мөмкинбез. Татарстанда 650ләп азык сәнәгате предприятиесе эшли. 2021 елда без аларның 116сын тикшердек. Әмма аңлашыла ки, һәркайсына бер күзәтче куеп булмый бит. Җитмәсә, быел марттан башлап безнең план буенча тәгаенләнгән контроль-күзәтү чаралары бөтенләй үткәрелми диярлек. РФ Хөкүмәтенең 336 нчы «Дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» карары нигезендә мондый тикшерүләргә мораторий игълан ителде. Бүген без бик чикләнгән форматта эшлибез.

– Әмма әлеге вазгыятьтән чыгу юллары бардыр бит?

– Җитештерүченең үзенә шактый зур җаваплылык йөкләнә. Республиканың зур предприятиеләренең үз җитештерү лабораторияләре бар, алар чимал, ярымфабрикатлар һәм әзер продукциянең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын контрольдә тота. Алар ХАССП (инглизчә HACCP аббревиатурасыннан, сүзен сүзгә ул Хәвефләрне Анализлау һәм Критик Контроль Ноктлалары, дип тәрҗемә ителә) системасы принципларына нигезләнгән процедураларның үтәлешен саклауны контрольдә тотарга тиеш. Беренче тапкыр ул АКШта 1960 елда яшерен шартларда гамәлгә кертелгән һәм NASA хаҗәтләре өчен файдаланылган. Туклану продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тикшерү системаларының күпчелеге азаккы продуктны гына контрольдә тотуга нигезләнсә, ХАССП, чимал һәм продуктның сыйфатын җитештерүнең барлык этапларында да тикшереп, превентив чаралардан файдалана. Татарстанда 2021 елда без тикшергән 116 предприятиенең 104ендә шул система кертелгән.

– Сүз уңаеннан, фермерлар продукциясенең сыйфаты зур компанияләрдә җитештерелгәннән күпкә яхшырак, дип санала. Бу чыннан да шулаймы?

– Монда үз нюанслары бар. Ит яки сөт продукциясе җәһәтеннән бу шулай диярлек. Фермерларның күпчелеге үз җитештерүләрендә азык һәм химик өстәмәләрне кулланырга өйрәнмәгән әле, шунлыктан аларның продукциясе табигыйрак, озак саклана торган түгел. Һәрхәлдә, былтыр безнең идарә тарафыннан сыйфатсыз яки куркыныч сөт һәм ит продукциясе җитештергән бер генә фермер да ачыкланмады. Ә менә бер нәрсә шик уята: фермер хуҗалыкларында үстерелгән яшелчә һәм җиләк-җимештә нитратларның нормадан артыграк булу очраклары күбәя бара. Былтыр безнең белгечләр шундый бер генә фактны ачыкласа, быел инде ярты елда ук биш очрак теркәлде.

– Димәк, без агрохолдингларның «нитратлы» помидорларын юкка хурлыйбыз?

– Әйе. Зур агрокомпанияләрдә эчке контроль эше көйләнгән. Ул шактый катгый, чөнки мондый предприятиеләр продукциясе бөтен ил буйлап тарала. Һәм әгәр берәр төбәктә Роспотребнадзор тикшерүе әлеге яшелчә-җимешләрнең нормаларга туры килмәвен ачыкласа, предприятиенең проблемалары җитди булачак. Шуңа агрохолдингларның мондый хәвефкә баруын күз алдына да китерүе кыен.

БЕЗНЕКЕ – ДИМӘК, ИҢ ЯХШЫ

– Марина Александровна, ә сез үзегез кибеттән гаиләгез өчен гадәттә нәрсәләр сатып аласыз?

– Дөресен әйтим, мин һәрвакыт Татарстан җитештерүчеләре продукциясенә өстенлек бирәм. Чөнки аларның үз абруйларын ничек кайгыртуын яхшы беләм. Бүген башка төбәкләрдә дә фальсификацияләнгән продукция шактый күп, ә еракта китереп җиткерү өчен җитештерүче продуктка озак вакыт буе бозылмый саклану мөмкинлеге бирә торган матдәләр кушарга мәҗбүр. Шунлыктан мин үзебездә җитештерелгән ит, кош ите, сөт ризыклары сатып алам, шул исәптән фермерлардан да. Икмәкне исә мин күптәннән инде үзем пешерәм. Гаиләм өчен сәламәт ризыклар әзерләргә тырышам. Роспотребнадзор сайтында үзем өчен илһам чыганагы таптым – «Здоровое-питание.РФ». Сезгә дә әлеге ресурска күз салырга киңәш итәм, анда сәламәт туклану өлкәсендәге экспертларның бәясен алган әзер рецептлар бик күп. Идарәбезнең якын арадагы планы – республика рестораторлары белән бергәләп әлеге сайт базасын татар халык ашлары рецептлары белән дә баету.

ШӘМӘХӘ БӨРТЕК ЗИҺЕННЕ САКЛЫЙ

Ксения Сёмина

Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының* сабан бодае сортлары һәрвакыт сыйфаты, тотрыклылыгы, югары уңыш бирүе белән аерылып торды. Ә хәзер, ихтимал, Альцгеймер һәм Паркинсон авыруларына каршы көрәшү сәләте дә пәйда булыр.

Моннан берничә ел элек Омск селекционерлары шәмәхә бөртекле бодай үстерүгә кереште. Терлек азыгы буларак кулланылган бу бодайны, төсенә карап, икмәк пешерелә торганыннан аеру бик җиңел иде. Тик соңыннан шәмәхә төс бирә торган биологик актив матдә – антоцианнарның шундый бөртекле культуралардан әзерләнгән продуктларда да файда китерүе ачыкланды. Ул арада шәмәхә үсемлекләр белән тагын да җылырак мөнәсәбәттә булган Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни тикшеренү институтында (ТатНИИСХ) инде ашарга яраклы «Надира» сортын үстерергә дә өлгерделәр. Ул Куллануга рөхсәт ителгән селекция казанышлары дәүләт реестрына кертелгән беренче антоцианлы бодай сорты булды.

ШӘМӘХӘ ДӘВА

Быел Новосибирск галимнәре тычканнарда Альцгеймер һәм Паркинсон авырулары белән тикшеренүләр үткәргән. Тычканнарга гадәти һәм шәмәхә бодай бөртекләре ашатканнар. Нәтиҗәләр антоцианлы ризык ашаган хайваннарда нейроннарның савыгу процессы активлашуын күрсәткән. Шуңа күрә эре итеп тарттырылган «Надира» бодае оныннан ризык функциональ, ягъни дәвалау максатында туклануның нигезен тәшкил итәргә мөмкин.

Орлык материалын файдаланучы аграрийлар субсидия ала алсын өчен, сорт дәүләт реестрына кертелергә тиеш. «Надира» үз кулланучысын инде әллә кайчан тапкан.

Фото: vk.com/alina_boginia, «Татарстан» журналы архивыннан

* Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни тикшеренү институты – «Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәгенең аерымланган структур бүлекчәсе.

– Без «Надира»дан эре итеп тарттырылган онны бер өлеш һәм югары сортлы бодай онын ике өлеш алабыз. Икмәк бик тәмле булып пешеп чыга, – ди Арча районы фермеры Рафис Аксаков. Ул, ТатНИИСХ белән күп еллар хезмәттәшлек итеп, институтта булдырылган яңа сортларны сыный. «Надира» корылыкка чыдамлык, талымсызлык, югары уңыш бирүчәнлек кебек яхшы якларын күрсәтергә өлгергән, шуңа күрә хуҗалыкта аны инде өченче ел чәчәләр. Хәтта былтыргы корылык елында да гектарыннан 30 центнер уңыш алганнар. Җыеп алынган 45 тонна ашлыкның бөтенесен диярлек Свердловск өлкәсе һәм Татарстан фермерлары сатып алып бетергән.

– «Надира»дан он һәм ярма җитештерәбез. Тегесе дә, монысы да бик яхшы сыйфатлы. Былтыргы продукцияне сатып бетердек, яңа уңыш көтәбез, – ди Рафис Аксаков.

БОДАЙДАН – ТЕРЕКЛЕК СУЫ

Шәмәхә сорт классик авыл хуҗалыгы җитештерүчеләрендә генә түгел, ә азык-төлек аграр сәнәгате новаторларында да бик тиз кызыксыну уяткан.

– Мине сортның потенциаль дәвалау үзлекләре җәлеп итте. Антоциан – табигый антисептик ул. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, бу матдә ашказаны-эчәк тракты авыруларын, онкологик чирләрне кисәтә, иммунитетны ныгыта. Болар барысы да безнең продуктка бик яхшы туры килә, – ди Баулы фермеры Айрат Әхмәтов. Хатыны Алинә белән ул витграсс – үрдерелгән бодайдан сок җитештерү белән шөгыльләнә. Мондый сокта организм өчен файдалы матдәләр бик күп тупланган, шуңа күрә ул сәламәт яшәү рәвеше тарафдарлары арасында бик популяр. Витграсс модасы Россиягә моннан берничә ел элек килеп җиткән. Татарстанда аны бары тик Әхмәтовлар гына җитештерә. Аларның витграссы Россиянең кырык шәһәрендә сатыла.

– Минем өчен продуктның сыйфаты һәм куркынычсызлыгы мөһим. Гадәттә витграсс өчен әзер чимал сатып алалар, тик мин бодайны үзем үстерүгә өстенлек бирәм. Без даими рәвештә яңа сортлар үстереп карыйбыз, инде 20дән артык сортны сынадык. Хәзер тәҗрибә участогына «Надира»ны чәчтек. Көз көне анализ ясыйбыз. Әгәр ул яхшы нәтиҗәләр күрсәтсә, бары тик шушы бодайдан гына сок җитештерәчәкбез, – ди Айрат Әхмәтов.

АМБАР ИШЕКЛӘРЕ ҺӘРКЕМГӘ АЧЫК

«Надира» – институт карамагындагы бердәнбер мактаулы сорт түгел. Яңа сорт чыгару өчен 13–15 ел кирәк. Бодай селекциясе белән шөгыльләнгән егерме ел эчендә Фәнни тикшеренү институты белгечләре нәтиҗәдә Дәүләт реестрына кертелгән уннан артык сорт булдырган. Болар – «Экада 113» (Россиядә һәм Казахстан Республикасында патентланган), каротиноидларга бай «Хәзинә», икмәк пешерү өчен йомры бөртекле «Сакара», чәчүлек мәйданнары буенча Россиядә беренче унлыкка кергән «Экада 109». Сүз уңаеннан, республикада якынча 450 мең гектарлы язгы бодай басуларының якынча 190 мең гектарына ТатНИИСХ сортлары чәчелә.

Татарстанда эшне кыенлаштыра торган төп фактор – дым булмау. Шунлыктан институт бу үзенчәлеккә бәйле үзлекләргә зур игътибар бирә. Шул ук вакытта корылыкка чыдам, интенсив үсәргә сәләтле сортлар буенча да, сыйфатлылык һәм югары уңыш бирүчәнлек белән аерылып торган сортлар буенча да селекция алып барыла. Орлыкчылык белән шөгыльләнүче һәм башка төбәкләргә ашлык сатучы фермерларның үтенеч-теләкләре дә исәпкә алына. «Йолдыз», «Экада 109», «Экада 214», «Ситара» сортлары районлаштырылган, ягъни безнең Урта Идел тирәсендә генә түгел, Үзәк-Кара туфраклы районда, Урал, Идел–Нократ төбәкләрендә дә кулланууга рөхсәт ителгән.

Язгы бодай ТатНИИСХ селекция хәзинәсенең кечкенә бер өлешен генә тәшкил итә. Биредә вируска чыдам бәрәңге дә, урып-җыю вакытында кузагы ачылмый торган һәм шул рәвешле гадәттәге югалтулардан коткарган борчак та, составында аксым булган терлек азыгы арпасы да һәм башка бик күп культуралар бар. Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни тикшеренү институты чыгарган сортларны илебездәге селекция казанышларын кертү рөхсәт ителгән 12 төбәкнең 11ендә үстерәләр. Әмма монысы инде бөтенләй башка тема.

СЫЙФАТ ӨЧЕН «ПАРТНЁР» ҖАВАП БИРӘ!

Галимнәр бүген безгә яшәргә туры килгән яңа чынбарлыкның исемен уйлап тапкан. BANI-дөнья* – тотрыксыз, шомлы, туры булмаган һәм ирешмәслек. Мондый шартларда авыл хуҗалыгы бизнесын үстерү җиңел эш түгел. Эшлекле абруй, сыгылмалылык, лояльлек, сыйфат гарантияләре – «ПАРТНЁР» сәүдә компаниясе үз клиентларына һәрвакыт тәкъдим итә торган бөтен нәрсә аерым әһәмияткә ия.

Идел буе төбәгендә урнашкан дистәләгән терлекчелек предприятиесе, кошчылык фабрикалары, дуңгыз фермалары, фермер хуҗалыклары һәм Россиянең зур катнаш азык заводлары – әлеге компаниянең даими клиентлары аның абруен теләсә нинди рекламага караганда ачыграк күрсәтә. Якын һәм ерак чит илләрдәге предприятиеләр дә «ПАРТНЁР» белән эшләүнең өстенлекләрен күптән үз итте – товарлар Кытай, Германия, Польша, Сербия, Монголия, Казахстанга чыгарыла...

– Безне бу базарның трейдерлары дип атарга була, – дип сөйли **«ПАРТНЁР СӘҮДӘ ЙОРТЫ» генераль директоры Евгений Вернев**. – Без тәкъдим иткән ассортиментның бер өлеше чит илләрдә җитештерелә. Әйтергә кирәк, безнең хуҗалыкларда аларга ихтыяҗ зур. Дөньядагы җиңел булмаган сәяси һәм икътисадый вазгыять безнең эшчәнлегебезне катлауландыра. Логистика барыбыз өчен дә күпләгән билгесезлекләре булган тигезләмәгә әверелде. Әмма безнең өчен үз абруебыз кадерле, шуңа күрә бөтен көчебезне бу тигезләмәне чишүгә юнәлтәбез.

«ПАРТНЁР» тәкъдим иткән ассортимент та эшчәнлегенең географиясе кебек үк киң. Майлардан – рапс һәм көнбагыш, сөяк һәм үлән оны, түп һәм майлы түп, фураж ашлыгы, берьеллык

** BANI – Brittle (тотрыксыз), Anxious (шомлы), Nonlinear (туры булмаган), Incomprehensible (ирешмәслек) кебек инглиз сүзләрен кыскартып төзелгән.*

Фотолар «ПАРТНЁР СӘҮДӘ ЙОРТЫ»ннан алынды. РЕКЛАМА

һәм күпьеллык үлән орлыклары, люцерна, майлы культуралар – җитен, торма, киндер, горчица... Кайбер позицияләр буенча гомуми күләмнәр инде күптән меңнәрчә тоннада исәпләнә.

БИЗНЕСНЫҢ ЮГАРЫ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ

Бу сәүдә компаниясе эшчәнлегенең иң зур юнәлешләренең берсе – катнаш азык өчен компонентлар, аерым алганда, азык өстәмәләре, аминокислота һәм витаминнар сату. Хәзерге вакытта алардан башка нәтиҗәле эшли торган терлекчелек яки кошчылык хуҗалыгын күз алдына китерү кыен. Бу бизнесның нигезендә шул исәптән балансланган рацион ята. Кышкы чорда ашату – аерым игътибар үзәгендә. Терлекләр өчен витаминнар рационны кирәкле файдалы матдәләр белән баетырга булыша. Триптофан, треонин, лизин, метионин, монокальцийфосфат, трикальцийфосфат... Бу катлаулы исемнәр артында барыннан да элек терлек һәм кош-кортның сәламәтлеге һәм югары продуктлылыгы тора, димәк, ахыргы продукт – ит, сөт, йомырканың югары сыйфаты да шуңа бәйле.

Сүз уңаеннан, сыйфат турында. Бүгенге көндә, исән-имин калу өчен, кайбер хуҗалыклар үзләрен яхшы яктан күрсәткән азык өстәмәләрен премикслар белән алыштырырга омтыла. Тик арзан рацион артыннан куып, аларның кайберләре үз бизнесын куркыныч астына куя. Очсызлы аналогларны куллану терлекләр сәламәтлегенә һәм хәтта гомеренә җитди йогынты ясый. Бу авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре өчен гаять зур югалтулар белән исәпләнә.

Тәҗрибә шуны күрсәтә: премиксларны азык өстәмәләренә альтернатива буларак куллануның зур тәвәккәллек икәнен аңларга кирәк. Үзегез уйлап карагыз: тәҗрибәле фермер яки фабрикадагы зоотехник сыерга яки кош-кортка шул ук метионин яки лизинны артым яхшырсын һәм мал авырмасын өчен күпме һәм нинди пропорцияләрдә кушарга кирәклеген белә. Аз гына тайпылыш та терлек-туарның сәламәтлегендә чагылыш табачак. Премикслар составы исә һәрвакыт җитештерүче намусында кала.

– Без үз продукциябезнең, шул исәптән азык өстәмәләренең сыйфаты өчен җавап бирергә күнеккән, – ди Евгений Вернев. – Сыналган, үзләрен күрсәткән брендлар белән генә эшлибез. Бу мәсьәләгә аерым игътибар бирәбез, чөнки бүген базарда шактый еш ялган продукция пәйда булып тора.

САТЫП АЛУЧЫНЫҢ ФАЙДАСЫ

Бервакыт акчасын янга калдыру нияте белән бер фермер хуҗалыгы кирәкле азык өстәмәсен турыдан-туры җитештерүчедән сатып алырга була. Бу юлның иң беренче җитешсезлеге: кагыйдә буларак, заводлар вак заказ белән мәшәкатьләнми, шактый зур партиягә заказ бирергә кирәк. Икенчесе – бөтен товар өчен алдан түләп кую таләп ителә, чөнки заводлар кичектереп түләүне бөтенләй кабул итми. Йөрәге әрнесә дә, үз сакчыллыгына сөенеп, терлекчелек белән шөгыльләнүче бу бизнесмен килешү шартларын үти һәм тиздән бик үкенә. Сатучылар мошенниклар булып чыга.

– Бүген, чыннан да, мондый проблема бар, – дип шәрехли бу очракны Евгений Вернев. – Аферистлар йокламый: алар җитештерүче заводларның рәсми сайтларының фальсификацияләнгән игезәген ачып эшли. Фермер хуҗалыклары өчен мондый «экономиянең» гаять зур зыянга әйләнү куркынычы зур. Шуңа күрә, әлбәттә, җитди сатып алуларны профессионалларга ышанып тапшыру яхшырак. Өстәвенә, чыннан да, табышка ирешергә була.

Базарда ун ел эшләү дәверендә «ПАРТНЁР СӘҮДӘ ЙОРТЫ» үзен ышанычлы гына түгел, лояль тәэминатчы буларак та күрсәткән.

– Үз сатып алучыларына мондый шартларны башка беркем дә тудырмый, дип курыкмыйча әйтә алам, – ди Евгений Вернев. – Беренчедән, кирәк булганда, без продукцияне заводларга караганда күпкә азрак күләмдә җибәрә алабыз. Зур булмаган хуҗалыклар өчен бу хәлиткеч фактор булырга мөмкин. Өстәвенә, логистика һәм таможня белән катлаулы һәм шул ук вакытта арзанлы булмаган бурычларны да хәл итеп, ассортиментның зур өлешен без чит ил тәэминатчыларыннан сатып алабыз. Һәм иң мөһиме: бездә ышанычлы хуҗалыклар һәрвакыт түләүләрне кичектереп торырга мөмкин. Кайчагында бизнеста, бигрәк тә авыл хуҗалыгы турында сүз барганда, бу хәлиткеч булырга мөмкин. Һәм без, моны аңлап, клиентларыбыз белән мөнәсәбәтләрдә сыгылмалылык күрсәтергә тырышабыз. Т

ПАРТНЁР ЭКСПОРТ

«ПАРТНЁР СӘҮДӘ ЙОРТЫ»
Казан, Восстание ур., 100, офис 354
+7 (937) 523-70-50
+7 (937) 775-23-33
partner.116@yandex.ru
partnerkzn.ru

«АВГУСТ–АЛАБУГА»: МУЛ УҢЫШ ХИМИЯСЕ

«Август-Алабуга» предприятиесе Россиядә үсемлекләрне химик саклау чаралары базарындагы бөтен ихтыяҗның өчтән бер өлешен тәэмин итә ала. Рекордлы саннар – планнарның уйдырма булмавына иң яхшы дәлил.

Күптән түгел куелган рекордларның берсе: дүрт ай эчендә – гыйнвардан апрель аена кадәр предприятие кулланучыларга үсемлекләрне саклау өчен химик чараларны былтыр ел дәвамында җибәрелгән кадәр – 12 миллион литрдан артык (төгәлрәге 12387321 л) күләмдә төяп җибәргән. Продукция исемлегендә электән чыгарыла торган күпләргә билгеле препаратлар да («Балерина СЭ», «Миура КЭ», «Бицепс Гарант» һ.б.), шулай ук яңа төрдәгеләре дә («Бицепс 300 МКЭ», «Балий КМЭ», «Тирада», «Хет-трик») бар.

САТУ ГЕОГРАФИЯСЕ: КРАСНОДАР КРАЕННАН КАЗАХСТАНГА КАДӘР

«Август-Алабуга» продукциясенә ихтыяҗ артуны аңлату кыен түгел. Беренчедән, предприятие препаратлары аграрийларның ышанычын яулаган, үзләренең нәтиҗәлелеген исбатлаган, икенчедән, бүген үсемлекләрне саклау өчен кирәкле барлык химик чараларның яртысы гына үзебезнең илдә җитештерелә, калганы чит илдән кертелә. Бу вазгыятьтә «Август-Алабуга», җитештерү күләмнәрен арттыру өчен, мөмкин булганның барысын да эшли. Мәсәлән, ике ай рәттән (февраль һәм март айларында) әзер продукция чыгару буенча чираттагы рекордлы күрсәткечләргә ирешкәннәр (2 314 380 л һәм 2 522 600 л). Монда төп рольне сакчыл җитештерү принципларын куллану һәм хезмәтне оптимизацияләү уйный. Җитештерү һәм кулланучыга җибәрүнең мондый югары күрсәткечләренә нәкъ менә яз көне ирешү дә мөһим булган, чөнки бу продукцияне аграрийларга оператив рәвештә чәчү алдыннан озатырга мөмкинлек биргән.

Бүген продукциянең күп өлеше (83%ка кадәр) Россия Федерациясе төбәкләренә озатыла, калган 17%ы Казахстанга туры килә. Иң күп сатып ала торган төбәкләр арасында Краснодар һәм Ставрополь крайлары, Орёл, Липецк, Тула, Тамбов өлкәләре, Алтай төбәге бар. Быел сату географиясе Красноярск крае һәм Иркутск өлкәсе хисабына киңәйгән. Искә

Фотолар «Август–Алабуга» предприятиесеннән алынды. РЕКЛАМА

САННАР һӘМ ФАКТЛАР

– Заводны ачу тантанасы Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында **2019 елның 28 июнендә** булган.
– Завод **«барысы да бер түбә астында» дигән уникаль технология нигезендә** төзелгән.
– Проектка салынган инвестицияләрнең фактик **күләме 4,5 млрд сумнан** артык.
– Үсемлекләрне саклау чараларын җитештерү предприятиесендә эш процесслары югары дәрәҗәдә автоматлаштырылган, монда Россиядә һәм чит илләрдә ясалган заманча җиһазлар урнаштырылган.
– 2020–2021 елгы җитештерү сезоны йомгаклары күрсәткәнчә, предприятиедә **15,9 млн литр әзер продукция** җитештерелгән.

алынган төбәкләр исемлеге шуның белән чикләнмәячәге шик уятмый. Әйтик, Россия һәм Казахстандагы кулланучылардан хәзерге вакытта җитештерелә торган «Суховей» препаратына заказлар килә башлаган инде.

МИЛЛИ ПРОЕКТ РЕКОРДЛАРГА ЮЛ АЧА

Җитештерү күләмнәре үсеше өчен төп чыганаклардан берсе – предприятиенең «Хезмәт җитештерүчәнлеге» дип аталган милли проектта катнашуы. «Август-Алабуга» заводы генераль директоры Владимир Алин билгеләп куйган бурыч өч ел эчендә хезмәт җитештерүчәнлеген 30 процентка арттыру һәм даими нигездә сакчыл җитештерү режимында эшләүгә күчүдән гыйбарәт.

Сакчыл җитештерү принципларына өйрәтү быел башланып китүен дә искәртик, ел ахырына кадәр хезмәтне оптимальләштерү процессына персоналның 90 процентын җәлеп итү күздә тотыла. Ә җитештерүне оптимальләштерү буенча өч линиядә гамәлгә ашырылган сынау проекты инде хәзер үк хезмәт җитештерүчәнлеген 30 процентка арттырырга ярдәм иткән. Уңышның нигезен тәшкил иткән шартлар арасында һәр препаратка кагылышлы эш эзлеклелеген дөрес алып бару, хезмәт җитештерүчәнлеге программасын гамәлгә ашыру кысаларында мастер-технолог һәм аппаратчылар үтәргә тиешле җитештерү нормаларын җентекләп анализлау һәм билгеләү бар.

СОЦИАЛЬ ҖАВАПЛЫЛЫК СӘЯСӘТЕ

«Август-Алабуга» – аграрийларга бик кирәкле продукция һәм алдынгы җитештерү технологияләре генә түгел әле. Предприятие корпоратив социаль җаваплылык сәясәтен дә актив алып бара, Алабуга муниципаль районында хәйрия һәм иганәчелек проектларын тормышка ашыруда катнаша. Районда спортны үстерү әнә шундый проектларның берсе булып тора.

Быел, аерым алганда, район башлыгы Рөстәм Нуриев һәм «Август-Алабуга» заводы генераль директоры Владимир Алинның уртак идеясен тормышка ашыру – Алабугада профессиональ футболны торгызу турында карар кабул ителгән. «Август-Алабуга» өлкәннәр футбол командасының генераль иганәчесе булып тора, һәм бу максатларга 1,4 млн сум бүлеп бирелгән инде. Әлеге акчалар спортчыларны яңа форма, кирәкле инвентарь белән тәэмин итәргә, шулай ук күнегүләр өчен уңайлы шартлар булдырырга мөмкинлек биргән. Моның нәтиҗәсе озак көттерми: команданың икенче лигада җиңүләре һәм Кама аръягы зонасының беренче лигасында алда баруы шуны раслый.

БАРЫСЫ ДА – БЕР ТҮБӘ АСТЫНДА

«Август-Алабуга» – пестицидларның сыек формаларын эре тоннажлы җитештерү юнәлешендәге ультразаманча предприятие. Монда фармацевтика һәм косметика чаралары җитештерүгә тиңләшерлек экологик чиста җитештерү турында сүз бара. Ул «барысы да бер түбә астында» дип исемләнгән уникаль проект буенча төзелгән: производство бер зур бинада урнашкан, аның теләсә кайсы урынына хезмәткәрләр урамга чыкмыйча барып җитә ала. Заводны проектлау, төзү һәм техник яктан җиһазлау вакытында «Август» компаниясенең 20 елдан артык эш тәҗрибәсе һәм аның белгечләренең осталыгы файдаланылган.

Предприятиедә Россия, Германия, Италия, Чехия, Португалия, Япония компанияләре җитештергән заманча җиһазлар көйләнгән. Югары дәрәҗәдә автоматлаштыру һәм робот техникасын киң куллану җитештерү процессларының ышанычлылыгын, продукциянең югары сыйфатын һәм сакланышын, шулай ук хезмәткәрләр өчен куркынычсызлык техникасының саклануын тәэмин итә. Тулаем алганда, предприятиедә үсемлекләрне саклау чараларының 40 төренә кадәр бер үк вакытта чыгарырга мөмкин.

Предприятие 17,7 га мәйдан били, аның 45 мең квадрат метрдан артык өлешендә җитештерү-склад бинадары урнашкан. Предприятиенең җитештерү куәте елына 50 млн литр әзер продукция һәм 8 млн полимер канистра тәшкил итә. Кирәк очракта, резерв мәйданнар хисабына җитештерү күләмен шактый арттырырга мөмкин.

Завод белән элемтә:
«Август-Алабуга» ҖЧҖ. 423601,
Татарстан Республикасы,
Алабуга р-ны, Алабуга шәһәре,
«Алабуга» МИЗ территориясе,
Ш-2 ур., корп. 4/1.
Тел./факс: +7 (85557) 5-26-03.

ИТ КЫЙММӘТЕ: АШАГАН ТҮГЕЛ, ҮСТЕРГӘН БЕЛӘ...

Руфия Фазылова

Соңгы алты ай эчендә сыер итенең бәясе күзгә күренеп артты. Моның өчен базарга чыгып карау да җитә: килосы 500–550 сумнан да ким түгел. Ә мөгезле эре терлек үстерүчеләр җиңел сулап куйды: ниһаять, бу өлкә табыш китерә башлады. Ит базарында алга таба ни булыр? Ни өчен кинәт кенә әлеге мөһим ризыкка бәя кыйбатланды?

ИХТЫЯҖ АРТТЫ

Татарстан мөгезле эре терлекне сугымга тере килеш сату буенча Россиядә беренче урында бара, тулаем терлек һәм кош ите буенча алганда – алтынчы урында. Россиядә җитештерелгән итнең 3,5 проценты Татарстанга туры килә. Республика ит белән үз-үзен тулысынча тәэмин итә.

Тулаем алганда, итчелекнең иң зур өлеше кошчылык тармагына туры килә: 539 мең тонна итнең 228 мең тоннасы (42,5%) нәкъ менә тавык, күркә ите. Димәк, бездә халык күбрәк тавык итенә өстенлек бирә. Моның объектив һәм субъектив сәбәпләрен ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ленар Гарипов аңлатты:

– Кошчылык өлкәсен карасак, Россия буенча да шулай ул, ягъни башка төбәкләрдә дә тавык ите күбрәк җитештерелә һәм кулланыла да. Моңа гаҗәпләнәсе түгел, ул җиңел үзләштерелә, бәясе дә кулай. Ә базар мөнәсәбәтләре шуңа көйләнгән: нәрсәгә ихтыяҗ зур, шул өлкә алдыра.

Сыер ите җитештерү юнәлешендә эшлисе эшләр бар әле безнең. Бу өлкә яңа «уянып» килә дисәм була. Сер түгел: 2019 елга кадәр фермерлар өчен итчелек белән шөгыльләнү отышлы булмады, чөнки аның бәясе гел түбән торды. Бик эре фермер хуҗалыклары гына ит җитештереп табыш алды, чөнки алар күпләп мал үрчетте, системага салынган эш иде. Инде менә иткә бәя күтәрелгәч, кечерәк фермер хуҗалыклары да итчелек белән кызыксына башлады. Берәүнең дә минуска эшлисе килми бит...

Фермерлар дигәннән, сыер ите җитештерү буенча «Продпрограмма» агросәнәгать комплексы (Мамадыш районы, Мотыйгуллин Рифат хуҗалыгы) беренчеләр рәтендә. Узган

Фотолар «Татарстан» журналы архивыннан, pxhere.com

ел 7,8 мең тонна ит җитештергәннәр, бу республика буенча алынган барлык сыер итенең 4,5 проценты дигән сүз. Икенче урынны «Ак Барс» АҖ били. Алар 7,3 мең тонна ит саткан. Өченче урында – «Кызыл Шәрык» АҖ, биредә 7 мең тонна сыер ите җитештергәннәр. Әлбәттә, алар итне килолап сатмый, ә Россия күләмендә эшли. «Мироторг», «Оренбив» кебек бик зур ит эшкәртү компанияләре белән килешү төзелгән. Эре фермерлар яшерми: алардан итне югарыда аталган компанияләр яхшы бәядән ала. Югары бәянең хакы – югары сыйфат. Ягъни фермерның бурычы – югары класслы ит җитештерү. Ә моның өчен ашату рационы, авыруларга каршы көрәш һәм бүтән факторлар да исәпкә алына, шунсыз югары сыйфатлы ит җитештереп булмый.

Бүген тере авырлыктагы сыер итенең бәясе 220–225 сум тора. Чагыштыру өчен: бер ел элек кенә әлеге сан 100 сумга кимрәк иде. Шуның өчен дә бүген мөгезле эре терлек асрарга теләүчеләр арткан. Һәрхәлдә, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында безгә шулай дип белдерделәр.

– Минем уйлавымча, сыер итенә кулай бәя алга таба да сакланачак, – диде ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ленар Гарипов. – Чит илдән ит продукциясе кертү кимеде, шуңа күрә үзебездә җитештерелгән иткә ихтыяҗ артты. Ә Татарстанда итчелекне үстерү буенча эшләргә бөтен мөмкинлекләр бар. Эреләре дә, ваграк фермер хуҗалыклары да бу юнәлештә ныграк эшли башлар, дип фаразлыйбыз. Ләкин гади кешеләр өчен дә мөгезле эре терлек тоту файдалы, алар да калышмас.



АЗЫКНЫ КАПЧЫКЛАП...

Заманча технологияләр аграр өлкәгә дә килде. Малларны ашатуда да бүген заманча алымнар кулланыла. Шуларның берсе – маллар өчен азык әзерләү үзәкләре. Хәзер фермер, тракторына утырып, печән чабып, аннан аны киптереп, төреп утырмаса да, мал асрый ала. Телефоныңны аласың да малларга азык әзерли торган үзәккә шалтыратасың. Иртәгәсен сиңа вакуумлы капчыкларда күпме кирәк шуның кадәр терлек азыгы китереп бирәләр.

– Безнең халык печәннең йомшагын малларның астына сала, чөнки ул коелып, улакта калган була, – ди Кукмара авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Рафак Хәлиуллин. – Ә бит үләннең иң файдалы, витаминлы өлеше нәкъ менә аның яфракларында. Азыкны вакуумлы капчыкларга төреп әзерләгәндә, ул файдалы үзлекләрен югалтмый. Әлбәттә, анда печән генә булмый. Мал азыгы рацион нигезендә төзелергә, балансланган һәм макро-, микроэлементларга бай булырга тиеш.

2021 ЕЛДА 539 МЕҢ ТОННА ИТ ҖИТЕШТЕРЕЛГӘН.

ТАТАРСТАНДА **87 СУГЫМЧЫЛЫК КОМПЛЕКСЫ** БАР.

Азык, малның төркеменә карап, һәркайсына аерым төзелә икән. Рацион составында 21 төрле азык кушылмасы була: кукуруз, тарттырылган ашлык, көнбагыш түбе, премикс, тоз, печән, сенаж, силос һәм башкалар.

Рафак Шамил улы әйтүенчә, Кукмарадагы малларга азык әзерләү цехы компьютерлаштырылган, эш тәртибе таблода күренеп тора. Азык граммына хәтле төгәллек белән ясала, моның өчен махсус үлчәүләр куелган. Әгәр нинди дә булса кушылманың массасы тулып җитми икән, чираттагы операция башкарылмый. Азык тиешле дәрәҗәдә болгатылып, монокорм буларак терлекләргә барып җитә.

– Мондый юл белән әзерләнгән азык җиңел үзләштерелә дә, – дип дәвам итте Рафак Шамил улы. – Терлекләрдән мул продукция, югары үсеш алыйм дисәң, иң беренче чиратта, аларны дөрес ашатырга кирәк. Авыл хуҗалыгы алга киткән чит илләрдә күптән шулай эшлиләр. Маллары булган кешеләр сынап карады: мондый азык ашата башлагач, сыерның сөте, ким дигәндә, ун-унбиш литрга күбәйде, ә үгез-бозауларның көнлек артымы алты йөз грамм гына түгел, ә бер килодан артты.

Малларга азык әзерләү үзәкләре әлегә республикада бармак белән генә санарлык: Кукмарадан кала, Балтач, Саба районнары да яңалыкны кабул итеп алган. Ләкин якын киләчәктә республиканың башка районнарында да шундый үзәкләр барлыкка килер, ди белгечләр. Шундый цехлар ачу өчен ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы грант та бирә.

– Ә бәясе ничегрәк, вакуумлы азык капчыкларын бөтен кеше дә сатып алырлыкмы? – дип сорыйм әңгәмәдәшемнән.

– Әйе, бәя арзан түгел. Әмма савылган сөт, үгез-бозаулар җыйган көнлек артымны кушсаң, малларга моноазык ашату отышлы булып чыга. Беренче чиратта бу авыл кешесенең хезмәтен җиңеләйтү дә бит. Биш үгезенә утыз биш капчык азыкка заказ бирә дә атна буе тыныч кына яши.

– Моноазык тутырылган капчыкның авырлыгы күпме була?

– 30–35 килолы була, фермер ничек заказ бирә инде. Шул азыкны көн буена бүлеп ашата гына. Әлбәттә, терлекләргә су да эчертәсе.

Кыскасы, тагын бер ун елдан басудан печән җыйган кешене дә очратмаска бик мөмкинбез. Ә нәрсә, чагыштырмача күптән түгел генә гектаргектар чөгендер утый идек, хәзер инде бу тарихта гына калды. Шулай булгач, печән чабу да шулай югалырга бик мөмкин.

БӘЯЛӘР ТӨШӘРМЕ?

Россиягә каршы кертелгән санкцияләр итчелек тармагына да кагылды. Яшерен-батырын түгел, арзанрак бәягә кайдадыр айлар буе яткан катырылган ит кибет киштәләренә кайта иде. Бүген аларны үзебезнең фермерлар җитештергән яңа суелган ит алмаштырды. Иткә бәя арту шуның белән дә бәйле. Икенче мөһим фактор – малларга ашата торган азыкның бәясе арту. Көнбагыш түбен фермерлар узган ел 24 сумнан алса, бүген 38 сумга ала. Иген бәясе дә узган ел белән чагыштырганда бермә-бер артты. Шуңа күрә ит бәясенең ни өчен кисәк кенә кыйбатлануын аңлар өчен математик та, фермер да булу кирәк түгел.

Язгы кыр эшләре соңга калуга карамастан, быел иген уңышы яхшы булырга охшап тора. Әлбәттә, аны әле җыеп алырга да кирәк. Монысы инде һава торышына бәйле. Барысы да әйбәт булган очракта, ягъни иген, печән мул булып, бәясе 2021 елгы күрсәткечләргә кайтса, итнең дә хакы арзанаерга мөмкинме?

– Мин әлегә бернинди фараз да бирә алмыйм, – диде Ленар Гарипов. – Иген, печән уңышы турында да сөйләргә иртәрәк. Бүген фермерлар яшел үлән әзерләргә керește, ләкин ун-унбиш көнгә соңга калдык. Димәк, бер фазасын югалтабыз дигән сүз. Шуңа күрә хәзер максат – бу эшне тиз арада дөрес итеп төгәлләү.

Татарстанда җитештерелгән ит бүген Россиянең төрле өлкәләренә тарала. Ә менә Россия чикләреннән узмый. Әлегә. Максат – беренче чиратта Татарстанны ит белән тәэмин итү.

– Бер ай элек Казахстаннан элемтәгә чыктылар, – дип дәвам итте Ленар Наил улы. – Бик зур күләмдә үгез ите сорыйлар. Бүгенгесе көндә андый күләм бирә алмыйбыз. Без аларның контактларын фермерларга бирдек. Андый ук зур күләмдә булмаса да, бәлки, алар сораганның чиреген җитештерә алырлар.

Сыер итеннән кала, сарык итенә дә ихтыяҗ зур. Узган ел республикада 16 мең тоннадан артык сарык ите җитештерелгән. Шулай булгач, киләчәктә бу өлкәне үстерергә кирәк, ди белгечләр. Ә менә дуңгыз итен 106,7 мең тонна җитештергәнбез. Бу тавык, сыер итеннән кала, өченче урында. Дуңгыз итен Россия күләмендә эшли торган компанияләр күпләп сатып ала. Шуңа күрә бу тармакны да бик рәхәтләнеп үстерергә була.

«ЖИГУЛИ»МЫ, «МЕРСЕДЕС»МЫ?

Берничә ел элек ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы үткәргән зур съездда катнашырга туры килгән иде. Шул вакыт ул чактагы авыл хуҗалыгы министры Марат Әхмәтов мөгезле эре терлекне җиңел машина белән чагыштырды: «Мерседес» яхшымы, «Жигули»мы? Әлбәттә, беренчесе! Терлек асраганда да шулай: нәселле мал яхшы. Соңгы дистә елда республика шушы юнәлештә нык-лап эшли башлады. Бүген Татарстанда 63 нәселле терлек үрчетү хуҗалыгы бар. Аңлашыла ки, алар гына республиканы нәселле терлекләр белән тәэмин итә алмый. 2021 елда 17480 баш мөгезле эре терлек кертелгән. Нигездә бу – таналар. Шуның 8 767се чит илләрдән, ә 8 713 башы Россиянең төрле өлкәләреннән кайтарылган.

– Санкцияләр кертелгәч, нәселле малларны күбрәк Россиядән кертә башладык, – ди Ленар Гарипов. – Шулай да Дания, Эстония кебек илләрдән мөгезле эре терлек кайта тора. Бу юнәлештә зур проблема юк. Шулай ук кошкортларга да санкцияләр кагылмады, элеккечә Франция, Англия белән эшлибез.

Читтән кертү белән проблема булмаса да, министрлыкта яхшы аңлыйлар: «Мерседес»ларны үзебездә җитештерергә кирәк. Шуның өчен дә селекция эшенә зур игътибар бирелә. Якын киләчәккә максат – нәселле терлек базасын булдыру, аны саклау һәм үстерү.

...Иткә кытлык булмаячак, монысы – бәхәссез. Ә бәягә килгәндә, бүген бөтен нәрсәгә хак артты. (Җиләк-җимеш, башка продуктлар белән чагыштырып карарга була). Монысына инде ияләнергә генә кала...

«МИРОВЕТ» КОМПАНИЯСЕ ПРОЕКТЫ: СӨТ ТОКЫМЫ БОЗАУЛАРЫН ИТКӘ ҮСТЕРҮ

РФ азык-төлек куркынычсызлыгы доктринасы буенча россиялеләрнең ит һәм ит продуктлары белән үз-үзен тәэмин итү дәрәҗәсе 85%тан да ким булмаска тиеш. Азык-төлек куркынычсызлыгы нигезендә үсемлекчелек һәм терлекчелектә нәтиҗәле селекция ята.

Төрле токымдагы үгезләрне симертүнең 16 айлык чор өчен чагыштырма нәтиҗәләре			
Үгез токымы	16 айлык тере мал авырлыгы, кг	Суелган терлек авырлыгы, кг	Ит чыгышы%
Кроссбрид үгез (Голштин х Ак-зәңгәр Бельгия токымы)	660–730	400–450	58–62
Симменталь	420–480	210–250	55
Герефорд	496–510	250–270	55
Абердин-ангус	550	302	55

Ит терлекчелеген заманча үстерүнең тиз үсә торган һәм керемле юнәлешләреннән берсе – кроссбридинг технологиясе – генетик яктан ярашмаган, бер-берсенә охшамаган сорт, линия һәм токым вәкилләрен кушу.

Россиядә ит терлекчелеген үстерү перспективалары күбесенчә Ак-зәңгәр Бельгия токымлы мөгезле эре терлекнең генетик материалын куллануга бәйле. Әлеге орлык аеруча куәтле санала, шунлыктан аны гади үгез орлыгы белән 2–4 тапкыр аталандырып та буазланмаган сыертаналарда сынап карарга тәкъдим ителәэ. Илебездә әлеге токым орлыгы белән эксклюзив рәвештә тәэмин итә торган ширкәт – «МИРОВЕТ» ҖЧҖ. Бүген компания Татарстан Республикасында нәселле продукция җитештерә һәм аны китереп бирә торган «Элита» ҖЧҖ белән тыгыз хезмәттәшлек итә.

Төрле токымны кушып чыгарылган хайваннарның төп өстенлеге – асрау һәм ашату шартларына талымсызлык, авыруларга чыдамлык һәм, иң мөһиме, җитештерелә торган итнең тәм ягыннан югары сыйфатлы булуы. Бу ит майлы түгел, диетик, тәмле һәм кеше сәламәтлеге өчен файдалы.

Моннан тыш, катнаш токымлы яшь ярымлык тана һәм үгезләрнең тере авырлыгы 680–720 кг га җитә һәм шул ук яшьтәге гадәти терлекнекеннән 100–200 кг га артып китә. Бу исә авыл хуҗалыгы җитештерүчесенә терлек азыгының югары конверсиясе хисабына гадәти рационда 20–50 мең сум күләмендә өстәмә табыш китерә. Шуңа күрә «МИРОВЕТ» ҖЧҖ эшендәге өстенлекле юнәлешләрнең берсе – сөт токымы терлекләреннән ит токымлы кроссбрид бозау алу технологиясе. Симертүнең нәтиҗәләрелеге буенча алар ит токымнарын да шактыйга узып китә.

Бар сер йөзьеллык селекциядә яшерен. Генетик сайлап алу нәтиҗәсе бүгенге кебек терлекләрнең барлыкка килүенә мөмкинлек биргәнче, бинигә күп вакыт узган.

Компания шулай ук терлекчелек хуҗалыкларын төрле чирләрдән дәвалауның инновацияле системасын, сыерларның баш санын арттыруны стимуллаштыру һәм үрчү сыйфатларын торгызу алымнарын, антибиотиклар кулланмаска мөмкинлек бирә торган, үз илебездә җитештерелгән нәтиҗәле дәвалау-профилактика препаратларын тәкъдим итә.

«МИРОВЕТ» ҖЧҖ белгечләре раслаганча, җитештерүнең нәтиҗәлелеге һәм продукция сыйфаты терлек үстергәндә кулланыла торган азык һәм су сыйфатына гына түгел, мал-туарны дәвалаганда препаратларны профессиональ дәрәҗәдә файдалануга да бәйле. Бүген компания кейсында тиңе булмаган шундый берничә препарат һәм вакцина бар. Аларның нәтиҗәлелеге фәнни тикшеренүләрдә һәм тормышта күп тапкырлар исбатланган. Компания тәэмин иткән орлык материалына һәм дәвалау препаратларына карата җитештерүче терлекчеләрдән мактау сүзләре – иң яхшы рәхмәт белдерү формасы, дип саный «МИРОВЕТ» ширкәтенең Татарстан һәм Башкортостан республикаларындагы вәкиле Рәсүл Саттаров:

– Бүген без гамәлгә ашыра торган проект авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын җайга салуны күздә тоткан дәүләт программасына туры килә, россиялеләрнең сыйфатлы һәм экологик яктан чиста азык-төлек продуктларына ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерүгә һәм кешеләрнең тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән. Бу киләчәк проекты түгелмени?

P.S. «МИРОВЕТ» ҖЧҖ 2 атналык, 6 айлык, 1,5 яшьлек үгез һәм таналарны базар бәясеннән югарырак хакка сатып алырга әзер.

Компаниянең сайты: **bbb.moscow**
E-mail: **bbg-bbb@bk.ru**
Адресы: **141201, Мәскәү шәһәре, Приозерная ур., 58 нче йорт.**
Тел.: **8-965-136-13-36**
«МИРОВЕТ» ҖЧҖнең Татарстан һәм Башкортостан республикаларындагы вәкиле – **Рәсүл Саттаров**
Тел.: **8-937-488-80-50**
Сайт: **molvet.ru**

Фото «МИРОВЕТ» ширкәтеннән алынды. РЕКЛАМА

«ГУДАКЕН» – ИҢ ТӘМЛЕ СЫЙ КАЙДА?

Кан тартмаса, җан тарта, диләрме әле? Әлеге гаилә бизнесының тарихы да шундыйрак. «Гудакен» фермер хуҗалыгы җитәкчесе Кадэрия Лотфуллинаның әтисе дә заманында фермер була. Кадэрия ханым башта хәрби юнәлешне сайласа да, аннан барыбер авыл хуҗалыгы тармагына әйләнеп кайта. Соңрак улы Илнар да фермерлык эшенә кереп китә.

ИСКЕНЕ ЯҢАРТУ

Монда тулы цикл белән эшлиләр: кош-кортларны үстереп, кибет киштәләренә урнаштыралар. (Инкубаторлары юк, яңа йомыркадан чыккан бәбкә, чебиләрне Оренбург өлкәсеннән, Башкортостан, Чувашия республикаларыннан алып кайталар.) Шуның белән бергә, «Гудакен» исеме астында ресторан, кафе, банкет заллары да бар. Менюда – фәкать үзләре җитештергән натураль кош-корт ите.

– Узган ел ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан бирелә торган грантны оттык, – дип сүзен башлады җитәкче. – Күркәләр үрчетү өчен 17 миллион сум акча алдым. Программа барлыгы 28 миллион сумга исәпләнгән, кырык проценты үзебезнеке иде. Шуңа күрә күркәләрнең баш санын алтмыш меңгә җиткердек. Күркәләрне ел саен арттырырга бурычлыбыз. Әле шушы акчага трактор да алырга ниятлибез, ферма булгач, техника гел кирәк.

Чынлап та, хуҗалыкның берничә ферма бинасы бар. Беренчесе – Яшел Үзән районының Осиново бистәсендә, элеккеге кошчылык хуҗалыгының иске биналары. Икенчесе Алексеевск районында урнашкан, шулай ук элеккеге ферма утарлары. Беренчесендә кырыкка якын кеше хезмәт куя, икенчесендә унбиш кеше эшли.

– Ике районда да ферма биналарын сатып алдык, – дип дәвам итте Кадэрия ханым. – Әле төзекләндерү эшләре һаман дәвам итә. Яшел Үзән районында сугым цехын да оештырдык. Нәфес ашаганда уяна, диләр бит. Бер урында гына туктап каласы килмәде.

Егерме елга якын шушы өлкәдә эшләү дәверендә «Гудакен» фермер хуҗалыгы үз кулланучысын тапкан. Иртә яздан кош-кортларны тере килеш сата башлыйлар, ихтыяҗ зур. Ә суелган тавык, күркә, үрдәк түшкәләрен авыз итәргә шәһәрнең төрле почмакларыннан киләләр. (Ит ризыкларын заказ белән дә илтеп бирәләр.) Алай гына түгел, Осиновода җитештерелгән кош-корт итен бүген Мәскәү, Мәскәү яны халкы да үз иткән. Атнага бер тапкыр зур машина белән Россиянең башкаласына да алып китәләр.

РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Ләкин, алда әйтелгәнчә, Кадэрия Минетулловна кош-корт үстерү, сату белән генә дә чикләнми. Үзләре җитештергән иттән алар өчпочмак, пилмән, мантый, шашлык кебек ризыклар да ясап саталар. Осиново бистәсендә зур кибетләре бар.

– Берничә ел элек кафе да ачтык, – ди Кадэрия Лотфуллина. – Бәяләрне кыйммәт итмәдек – ит ризыкларын үзебез җитештергәч арадашчыларга акча түлисе юк. Башта бәя белән алдырдык. Һәм, әлбәттә, тәмле ризык. Кешегә бер тапкыр сыйфатсыз ризык ашатсаң, бүтән ул килми. Монысы көн кебек ачык.

Осиново бистәсендә урнашкан «Гудакен» кафесыннан бүген кеше өзелми. (40, 80 урынга исәпләнгән ике залы бар.) Балалар өчен тел йотарлык ризыклар кертелгән аерым меню бар. Шуның өчен дә «Гудакен» ресторан, кафе биналары буш тормый. Банкет залында да юбилейлар, зур мәҗлесләр даими булып тора.

– Кадэрия ханым, сезнең уңышның сере нидә? – дим.

– Тәвәккәллек кирәк, монысы иң мөһиме. Аннан тагын бер мөһим нәрсәне әйтим – грант, кредитлар алудан курыкмаска кирәк. Ансыз гына мөмкин түгел. Бүген фермерлыкны үстерү өчен бик күп дәүләт программалары бар. Заманында әнә шулар аякка басарга ярдәм итте безгә. Хәер, әле бүген дә дәүләт ярдәменә таянам. Мисал өчен, «Россельхозбанк»тан ташламалы кредит алдым. Шулай ук әлеге банк оештырган онлайн-сату мәйданына теркәлеп, клиентлар таптым.

Әйе, Кадэрия Минетулловна кыю ханым. Әле ул моның белән генә чикләнмәячәк. Инде уртаклашты: туристлык юнәлешендә дә планнары бар. Тик алдан кычкырып куярга ярамый, монысы хакында соңрак...

Фото: Кадэрия Лотфуллинаның шәхси архивыннан. РЕКЛАМА



БАКТЕРИЯЛӘР АЗЫК-ТӨЛЕК ИМИНЛЕГЕ САГЫНДА

Ольга Туманская

Ит белән йомырканың сыйфатын ничек яхшыртырга, әчетелгән сөт продуктларының дәвалау үзлегенә ни рәвешле ирешергә? Боларның барысын да безнең кечкенә генә «якташыбыз» – Казан университеты, КМТТУ һәм Ветеринария академиясе галимнәренең уртак фәнни эшчәнлеге нәтиҗәсендә табылган лактобактерия эшли ала икән. Импортны алыштыру һәм илнең азык-төлек иминлегенә таба тагын бер адым – әлеге тырыш хезмәт шундый күңелле «бонус» та бирергә сәләтле.

Күз алдыгызга китерегез, алар – бөтен җирдә! Туфракта, үсемлек тамырларында һәм хәтта, гафу, кеше һәм хайваннарның тормыш эшчәнлеге калдыкларында да! Әйе, әйе, фәкать файдалы әчетелгән сөт ризыклары белән күзаллана торган шул лактобактерияләр. Шуңа күрә белеп эшләгәндә аларны һәркайдан аерып алырга мөмкин. Тик бу фәнни тикшеренүләрнең конкрет файдасы һәм яңалыгы нидә соң?

БӨТЕН ҖИРДӘГЕ КЕБЕК ТӘ, ӘММА АЛАЙ УК ТА ТҮГЕЛ

– Табигатьтә йөзләгән төрдәге лактобактерия бар, – дип аңлатты миңа **биология фәннәре докторы, КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институты-**

Фотолар «Татарстан» журналы архивыннан, pxhere.com

ның генетика кафедрасы мөдире Айрат Каюмов**. – Шул ук вакытта бер төр эчендә генә дә бактерияләр төрле, бер-берсеннән күпмедер дәрәҗәдә аерыла, чөнки һәркайсы үзенең яшәү шартларына җайлашкан. Әмма безнең фәнни тикшеренүләрнең катлаулылыгы шунда: күп кенә җирле бактерияләр арасыннан нәкъ менә үзлекләре буенча оптималь ярашканнарын һәм, мәсәлән, ветеринария, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек сәнәгатендә кулланганда сизелерлек файда, шифа гына түгел, бәлки коммерция ягыннан да табыш китерерлекләрен сайлап алу. Без моңа ирештек.

Барысы да сигез ел элек башланган. Каюмов лабораториясендә эшләүче бер студент кызга эш кушалар: туган авылыннан шәһәргә килгәндә ул силос алып килергә тиеш була.

– Гомумән алганда, без силоста ике йөзгә якын төрдәге бактерияне ачыклый алдык, – дип искә ала ул чакларны Айрат Каюмов. – Аларның патогеннар үсешен киметә һәм үз мохитен ачыта алу үзлеген тикшерү бурычын куйдык.

Бүген Казан тикшеренүчеләре коллекциясендә йөзгә якын лактобактерия бар, аларның алтысы гына киләчәктә эшләү өчен сайлап алынган.

Быел җәй яңадан силос белән эшли башлаячаклар, әмма инде бөтенләй башка дәрәҗәдә – галимнәргә үзләренең силос әчеткече «рецептын» табарга кирәк. Менә сезгә җирле бактерияне коммерция ягыннан файдалануның беренче варианты да, импортны алыштыруга беренче адым да, чөнки бүген Россия терлекчелегендә бу максатлар өчен бик еш кына элек чит илдән кертелгән препаратлар кулланыла.

– Кызганычка каршы, әчеткечне бөтенләй кулланмау мөмкин түгел – силосның бозылу куркынычы бар, – ди Айрат Каюмов. – Алар күгәрек бактерияләренең үсешен бастырып, әчү процессын дөреслэп җибәрә. Ә авыл хуҗалыгы хайваннары өчен дөрес азык кибет киштәләренә кайтачак файдалы, бозылмаган ит һәм сөт дигән сүз.

– Ә нәрсә, безнең бактерияләр чит илнекедән яхшыракмы? – дип сорау бирәм галимгә.

– Алай дип әйтеп булмый, алар башка, нәкъ менә безнең мохиткә – микрофлорага, климат шартларына җайлашкан бактерияләр. Шуңа күрә үз функцияләрен дә нәтиҗәлерәк итеп башкарачак.

Быел җәй яңадан силос белән эшли башлаячаклар, әмма инде бөтенләй башка дәрәҗәдә – галимнәргә үзләренең силос әчеткече «рецептын» табарга кирәк.

ТӘМЛЕ ДӘ, ФАЙДАЛЫ ДА

«Иммунитетыңны ныгыт!» – бу сүзләрне ишетүгә шәхсән мин үзем танылган бер брендның кечкенә генә шешәдәге эчемлеген күз алдына китерәм. Әлбәттә, күп еллар дәвамында алып барылган реклама кампаниясе үз нәтиҗәсен бирә. «Без бөтен дөнья күләмендә кешеләрнең иммунитетын ныгытабыз, – дип белдерә француз җитештерүчесе, – чөнки шундый бер шешәдә 20 миллиард пробиотик бар!»

– Ә нәрсә, бу чыннан да шулаймы? – дип сорыйм мин **биология фәннәре кандидаты, КМТТУның «Ит һәм сөт продуктлары технологияләре» кафедрасы доценты Елена Никитинадан**.

– Әйдәгез, проблемага киңрәк карыйк. Тикшеренүләр буенча, файдалы бактерияләр, чыннан да, сәламәтлекне ныгытырга булыша. Шул ук вакытта, аларны кеше организмына фармацевтик препаратлар ярдәмендә дә кертергә була, әмма медицина өлкәсеннән дөрес туклану тармагына күчәргә дә мөмкин.

Якындагы киләчәкне күз алдыгызга китерегез: кибет киштәләрендә холестеринны киметүче, кандагы шикәрне нормальләштерүче йогуртлар, симерүгә каршы искиткеч корал – аерым бактерияләр белән баетылган кефир пәйда була. Җитмәсә, барысы да Татарстанда җитештерелгән... Чыннан да Казан галимнәре сәламәт яшәү рәвеше тарафдарларының әлеге хыялына таба беренче адымны ясаган да инде.

– Безнең бурыч булган сөт продуктлары ассортиментын киңәйтү һәм аларның файдасын арттыруны күз уңында тота, – дип сөйли Елена Никитина. – Әлеге бурычны без Татарстан Республикасы территориясендә ачыкланган лактобактерияләр ярдәмендә хәл итәбез. Димәк, шундый ук, әмма чит илләрдән кертелгәннәргә караганда безнең шартларга, шул исәптән климатка яхшырак яраклашкан.

Баетылган продуктлар җитештерүдә төп кыенлык – әчетелгән сөт бактерияләренең ашказаны-эчәк сокларына бирешмәүчәнлегенә ирешү. Кызганычка каршы, бу көрәштә күпчелек лактобактерияләр оттыра – файдалы флора тиешле урынга барып җитә алмый. Нәтиҗәдә сөт ризыклары җитештерүчеләрнең күбесе аларның яхшы консистенциясенә, куелыгына һәм тәменә ирешсә дә, көтелгән файдалы пробиотик нәтиҗә ала алмый.

– Без ачыклаган әчетелгән сөт бактерияләреннән алтысы кешенең үт сыекчасына һәм ашказаны согы тәэсиренә чыдам булып чыкты, – дип сөйли Елена Никитина. – Аларның аз өлеше генә булса да эчәклекнең түбәнге бүлегенә барып җитә алса, пробиотикның файдасына ирешәчәкбез. Өстәвенә, чыннан да, безнең тикшеренүләр функциональ азык-төлек продуктлары исемлеген киңәйтергә сәләтле, ә бу инде халыкара тренд дигән сүз. Моны онкологиядә таргет терапиясе белән чагыштырып буладыр, мөгаен, ул вакытта авыру күзәнәккә адреслы йогынты ясала. Бизнес белән бергә, без әчетелгән сөт ризыклары җитештерә алыр идек. Бу ризыклар шулай ук сәламәтлекнең аерым бер проблемаларын «адреслы» хәл итәргә сәләтле булачак. Шуңа күрә «диабетиклар өчен кефир» – бүгенге көндә без башкара алырлык бурыч.

Бу бик шәп яңалык, әмма шәхсән миңа бу идеянең якындагы супермаркет киштәләренә ничек һәм кайчан күчә алуы кызык. Кызганычка каршы, фәнни лабораториядән кибет киштәсенә юл шактый озын булып чыкты.

– Барысы да Татарстанда әчеткечләр җитештерү тармагының ни дәрәҗәдә тиз үсүенә бәйле, – ди Елена Никитина. – Әлегә бездә мондый бер генә завод та юк.

Сүз уңаеннан, «җирле» бактерияләр нигезендә әчеткечләр җитештерү актуаль пробиотик мәсьәләне генә түгел, ә кискен икътисадый бурычны да хәл итә ала. Әйе, сүз илнең азык-төлек куркынычсызлыгы һәм импортны алыштыру турында бара. Бүген әчетелгән сөт ризыклары җитештерү линияләре, бигрәк тә зур булмаган предприятиеләрдә, тулысынча чит илдән кертелгәннәргә җайлаштырылган. Әчеткечләр кертү туктала икән – җитештерү технологиясен дә үзгәртергә туры киләчәк, ә бу бер генә көнлек эш түгел.

Бүген Россиядә әчетелгән сөт продуктларын җитештерүне, мөгаен, ил автосәнәгатендә машиналар җыю белән чагыштырырга мөмкиндер: беренче мәлләрдә, әлбәттә, әзер чит ил технологиясен сатып алу һәм эшләтеп җибәрү арзанрак та, җиңелрәк тә иде. Тик заманалар үзгәрде: нибары ике-өч кенә агрегат кайтартудагы проблема аркасында да эш туктала… Үз сөт ризыклары җитештерү технологиясе нигезендә, баштан ук безнең шартларга җайлаштырып һәм хәтта ки моның белән аерым бер ныклык запасы өстәп, үзебезнең әчеткечләрне ясау җирле предприятиеләрне әлеге проблемалардан сакларга һәм якларга мөмкинлек бирәчәк.

– Бүген Россиянең май һәм сыр сәнәгате җитештерүчеләре арасында беренче һәм әйдәп баручы рольне Угличтагы Бөтенсоюз май һәм сыр ясау сәнәгате фәнни тикшеренү институты уйный. Аның үзенең зур булмаган производствосы бар, әлбәттә, ил күләмендә ул җитештергән продукция җитми, – дип сөйли Елена Никитина. – Бу бигрәк тә үз лабораторияләрен тотар өчен акчалары җитмәгән кечерәк предприятиеләр өчен актуаль. Ә мондый заводлар безнең республикада шактый күп.

Сүз уңаеннан, предприятиедә мондый лабораториянең булуы да глобаль проблеманы хәл итми: үз көчең белән әчеткечләр күләмен «арттырырга» була, тик аны тулысынча тәэмин итеп булмый. Шулай булгач, зур заводлар өчен бу, бәлки, алай ук кискен булмаса да, көн кадагындагы мәсьәлә.

Бүген Татарстанда сөтне «ак нефть» дип атыйлар. Ун елдан артык без сөт җитештерү буенча лидер булып, сөт саву буенча ил беренчелеген тотып торабыз. Башка республикаларда җирле продукциягә ихтыяҗ арта бара... Нәтиҗәләр ясау артык кыен түгел.



«СӘЛАМӘТЛЕГЕБЕЗ НӘРСӘ АШАВЫБЫЗГА БӘЙЛЕ»

Кабан, буйвол, мөгезборын, филләр – пычрак һәм тузан ванналарын яратучыларны дөньяның теләсә кайсы почмагында табарга була һәм Татарстан да бу яктан искәрмә түгел. Әйе, кыргый хайваннар мондый табигый коенуның дәвалау үзлекләре турында күптәннән белә. Табигатьне күзәтеп, Казан ветеринария академиясе галимнәре бу тәҗрибәне кешелек файдасына кулланырга уйлаган. Ә инде Татарстанда да аяк астында гына ятучы файдалы матдәләрнең иге-чиге юк.

Сүз республикабызда бай ятмалары булган төрледән-төрле минераллар турында бара. Күп гасырлар дәвамында төче сулыкларда утырма хасил иткән органик черемә, ләм генә дә буа буарлык!

– Табигый минераллар составында 60тан артык микро- һәм макроэлемент бар, – дип сөйли **биология фәннәре докторы, Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе профессоры Асия Ежкова**. – Алар теләсә кайсы тере организмга уңай йогынты ясый, авыр металл, радионуклид һәм башка токсиннарны яхшы җыя, иммунитетны ныгыта, минераль матдәләр балансын торгыза, терлекләрнең баш санын арттыра. Һәм бу безгә терлекчелек продукциясенең сыйфатын яхшыртуда аларны

уңышлы кулланырга мөмкинлек бирә. Әмма без тагын да алгарак китеп, яңа буын симбиотик – Татарстанда ачыкланган лактобактерияләр белән минералларны берләштереп, азык өстәмәләре җитештерергә булдык.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, табигый минераллар әчетелгән сөт бактерияләре өчен яхшы субстрат, ягъни туклану чыганагы, шулай ук аларны билгеләнгән пунктка, ягъни хайванның ашказаны-эчәк трактына турыдан-туры китерүче ышанычлы «транспорт чарасы» булып хезмәт итә ала. Шул ук вакытта универсаль илтеп җиткерүче, чөн-

ки бу «транспорт чарасы» үзе дә бик файдалы микро- һәм макроэлементларга бай.

– Берничә ел элек без нанотехнологияләр белән мавыгып киттек һәм кайбер минералларның күләмен 5тән 100 нанометрга кадәр җиткерә алдык, – дип сөйли Асия Ежкова. – Эш шунда ки, хайваннар күзәнәге 60 нанометрга кадәр. Әгәр без хайванга туклыклы матдәне наноразмерлы халәттә бирсәк, аның организмы матдәне таркату өчен вакыт та, энергия дә сарыф итмәячәк. Турыдан-туры китереп җиткерү иң тизе дә булып чыга!

Балансланган рацион төзеп, азык өстәмәләрен эксперимент рәвешендә лабораториядә сынала торган терлекләргә, ә аннан соң сәнәгать терлекчелеге шартларында бирү ит, сөт һәм йомырканың продуктлылыгын 12 процентка кадәр арттырып булу мөмкинлеген күрсәтте. Бүген ветеринария академиясендә мондый тикшеренүне симбиотиклар уза. Матдәләрнең организм уңай йогынты ясарлык оптималь күләме билгеләнә, аның хисабына терлек-туарның сәламәтлеге ныгый, агрессив тышкы мохиткә чыдамлыгы арта, тере массаның артымы үсә һәм терлекчелек продукциясенең сыйфаты яхшыра.

– Хайваннар һәм кошларның агрессив азыкка каршы торучанлыгын арттыру – аерым игътибар үзәгендә, – дип сөйли Асия Ежкова. – Хайваннарга бирелә торган ашлыкның бер өлеше гөмбә белән зарарланган булуы беркемгә дә сер түгел, ә җитештерүченең еш кына бу азык базасын алыштыру мөмкинлеге булмый.

Әлбәттә, мондый симбиотикларның дөнья күләмендә тиңнәре бар, әмма Казан препаратларының бәхәссез өстенлеге шунда: алар җирле минераль чимал һәм лактобактерияләр нигезендә эзерләнгән. Һәм инде, белгәнебезчә, табигатьтә барысы да үзара бәйләнештә.

Әзер терлекчелек продуктының куллану үзенчәлекләренә килгәндә, симбиотиклар анда аксымның булуына һәм минераль матдәләр составына турыдан-туры йогынты ясый. Чөнки ашказаны-эчәк системасы аша узганда алар хайванның ашказанында һәм эчәклегендә азыкны тоткарлый, димәк, үзләштерелә торган туклыклы матдәләр күләмен дә арттыра.

– Сәламәт хайван, ахыр чиктә, сыйфатлы ит, йомырка һәм сөт ул, – ди Асия Ежкова. – Сәламәтлегебез нәрсә ашавыбызга бәйле.

Тик гади кулланучы үзе өчен чыгарырга мөмкин булган иң мөһим нәтиҗә шундый: кошчылык һәм терлекчелектә симбиотиклар куллану әлеге дә баягы антибиотикның кирәклеген киметә. Ә антибиотик, белүебезчә, ашказаны-эчәк трактында зарарлы микрофлораның артуына юл куймас өчен кулланыла. Үз тирәсендә файдалы микрофлора формалаштырырга сәләтле кечкенә генә лактобактерияләр авыруга каршы препаратлар куллануда җитди көндәшлек тудырырга сәләтле.

ЭКСПЕРТ: «СЫР ЯСАУ ТАРМАГЫНА КАДРЛАР КИРӘК»

«Вамин – Татарстан» Компанияләр төркеме җитәкчесе **Минтимер Минһаҗев** чит ил җитештерүчеләренең базардан китүе нәрсәгә китерәчәге, Белоруссия сырлары белән көндәшлек һәм илдә сыр җитештерүгә нәрсә җитмәве турында фикер йөртә.

Сезнеңчә, быел Россиядә сыр базарында вазгыять ничегрәк үзгәрә? «Вамин» җитештерүне арттырачакмы?

Минемчә, Россиядә сырны зур күләмдә җитештерүчеләр аны чыгаруны хәзер үк арттыра инде һәм моны киләчәктә дә дәвам итәчәк.

Тотрыксыз икътисадый вазгыять һәм түли алу сәләте кимү фонында төбәктәге зур булмаган җитештерүчеләр, ихтимал, рентабельлекнең кимүен күтәрә алмыйча, өлешчә базардан китәргә мәҗбүр булыр, калганнар исә җитештерүне арттыруның тотрыклы күрсәткечләренә ирешергә омтылыр.

Хәзер икътисад хәрәкәте көн саен үзгәрергә мөмкин, шуңа төгәл фаразлау кыен.

Без җитештерү процессларын җайга салабыз һәм сөт эшкәртү күләмен көн саен арттырабыз. Реконструкциядән соң Арча заводын эшләтеп җибәрдек, ул тулы куәтенә эшләгәндә тәүлегенә 420 тонна чимал эшкәртергә сәләтле. Югары җитештерүчән яңа линия тәүлегенә 38 тоннага кадәр ярымкаты һәм каты сыр ясау мөмкинлеген бирә. Балтач һәм Аксубайдагы заводларның куәте дә арттырылырга мөмкин.

Чит ил җитештерүчеләре базардан киттеме, үзебезнекеләр ихтыяҗны капларлык күләмдә сыр ясарга сәләтлеме?

Һичшиксез, Россиядә без чит илнекен тулысынча алыштырырлык продукция җитештерә алабыз. 100% булырмы ул, дисәк, юктыр, дип уйлыйм. Шул ук вакытта 100%ка алыштыру кирәкме соң, дигән сорау туа. Сыр базарының сыйдырышлылыгы зур – каты, ярымкаты, йомшак, эремчекле, нәрсәдер кушылган, күгәрекле... Эшчәнлек кыры иркен – төрле кешегә төрле тәмдәге сыр ошый бит.

Халыкның кереме артмый, шунлыктан кайбер төбәкләрдә арзанрак позицияләрдәге сырны сатып алучылар ишәя. Моңа бәйле рәвештә премиаль позициядәге сырга да ихтыяҗ элеккеге кебек түгел.

Иң күп сатыла торган сырлар кибет киштәләрендә гел булачак – монысы факт. Кайбер брендлар гына алышыначак. Тора-бара башка брендлар, башка тәмнәрне яратучылар да пәйда булачак. Пандемияле 2020 ел күрсәткәнчә, халыкның 40%ы башка брендларны татып караган һәм моңа үкенмәгән, алай гына да түгел, аларны күпләп сатып ала башлаган.

Әлеге җәһәттән үз продукциягезне тәкъдим итү яки киштәләрдә аның ассортиментын киңәйтү буенча сәүдә челтәрләре белән элемтә урнаштыру җиңеләйдеме?

Һичшиксез, элемтәләр артыр, дип уйлыйм. Әмма күп нәрсәне истә тоту мөһим. Продукцияне тиз генә өлгертеп һәм шул арада гына тәкъдим итеп булмый. Һәрнәрсә-

Фотолар «Вамин» Компанияләр төркеменнән алынды. РЕКЛАМА

нең үз вакыты бар. Киләсе елда бу процесслар активрак барачак.

Безнең продукциягә килгәндә, без товарның матрицасын эшләү белән мәшгуль. Кибет киштәләрендә һичшиксез үлчәп төрелгән яңа сырлар пайда булачак. Әлегә без 5 төрле төргәкле сыр, 72,5%лы атланмай һәм барлыгы 17 төрдәге үлчәп сатыла торган сыр җитештерәбез.

«Вамин» компаниясе Арча заводын реконструкциядән соң катлаулы чорда эшләтеп җибәрде. Барысы да планлаштырганча килеп чыктымы?

Әйе. Заводны туктатып яңарта башлауга нәкъ бер ел үткәч, яңа җиһазлар белән эш башладык. Иң мөһимен эшләдек – җитештерүгә керештек һәм «евробрус»ны өлгертергә куйдык.

Шунысы игътибарга лаек: азык сәнәгате ветераны – Арча сөт комбинаты үзенең 90 еллык юбилеен тулысынча яңартылган килеш каршылый. Комбинатны реконструкцияләүгә 563 миллион сум акча кертелде. Сыр майсыз булмый. Без май ясау цехын да яңарттык. Анда илебездә җитештерелгән яңа җиһазлар куелды. Якын арада үлчәп төрү линиясен эшләтеп җибәрергә һәм ел азагына кадәр 1500 тонна сыр өлгертерлек яңа склад биналарын төзергә ниятлибез.

«Агроэкспорт» аналитика күзәтүләреннән берсендә Россия сырларының бәясе һәм сыйфаты буенча Белоруссия сырларына көндәш була алмавы бәян ителгән иде. Сезнеңчә, бу ни белән бәйле?

Бу сорауны «Агроэкспорт» күзәтүчесенә бирергә кирәктер.

Минемчә, «Российский» һәм «Голландский» төрендәге сырларда сез аерма тапмаячаксыз. Ихтимал, моннан 10 ел элек аерма булгандыр. Хәзер исә җитештерүдәге җиһазлар да, технологияләр дә бөтенләй башка сыйфатта.

Россиядә дә, Белоруссиядә дә сырны күпләп җитештерүчеләрнең дә, азлап җитештерүчеләрнең дә проблемасы уртак. Бу – сыйфатлы чимал кытлыгы. Россиядә сыр ясарлык сөт табарга кирәк. Ә яхшы сырны бары тик югары сыйфатлы сөттән генә кайнатып була.

Сатып алучыга исә һәрвакыт тәмле, файдалы һәм арзанлы продукт кирәк.

Әлеге вазгыятьне үзгәртү өчен нишләргә кирәк?

Авыл хуҗалыгы белән җитди шөгыльләнергә, чәчүлек мәйданнарын киңәйтергә, авыл хуҗалыгы культураларының уңышын (бигрәк тә техник культураларныкын) арттырырга, терлекчелекне үстерергә, тулаем авыл хуҗалыгы җитештерүен куәтләндерергә кирәк.

Тагын бер тапкыр кабатлыйм – бу тиз арада эшләнә торган эш түгел. Аны берничек тә тизләтеп, табигатькә каршы барып булмый.

Авыл хуҗалыгын торгызу, терлекчелек комплекслары төзүчеләргә субсидияләр бирү һәм ташламалы шартлар тудыру зарур. Яшьләрне авылга кайтарырлык шартлар тудыру мөһим.

Гыйнварда төзелә башлаган «Северный» АХП сыйфатлы сөт җитештерүгә булышачакмы һәм нинди күләмдә?

5960 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән терлекчелек комплексыбызны шуның өчен төзи башладык та инде. Иң беренче чираттагы бурыч – үз җитештерүләребезне сөт белән тәэмин итү. Бүген без эшкәртергә хәлебездән килгән сөтнең нибары 10 процентын гына җитештерәбез. Соңгы өч елда «Северный» җәмгыятендә комплекс модернизацияләнде, автотехника паркы яңартылды, терлекчелекне цифрлаштыру системасы кертелде – барлыгы 350 миллион сум акча тотылды. Төзелеш башланды. Ул этаплап гамәлгә кертеләчәк. 2027 елда төгәлләргә планлаштырабыз.

Продукцияләренең сыйфатын яхшырту өчен Россия сыр ясаучыларына нәрсә җитеп бетми?

Беренче чиратта кадрлар кирәк, үз һөнәренең остасы булган белгечләргә, технологларга кытлык зур. Үз тәҗрибәмнән һәм сыр ясаучы заводлар белән аралашуымнан чыгып әйтә алам – сыр кайнату иҗади эш ул. Белемле, талантлы сыр ясаучыларны үстерү таләп ителә.

Бүген җитештерүчегә экспортка чыгу никадәр катлаулы? Моның өчен нәрсә җитми?

Кичә мөһим булган һәрнәрсәнең бүген инде яңа формалары һәм кагыйдәләре бар. Нәрсәдер эшләү өчен – теләк кирәк. Эшкуарларга ярдәм фондларында консультация алырга була. Продукцияне күчерүгә, ил эчендә һәм чит илдәге склад чыгымнарына китәчәк акчаны алдан исәпләү зарур. Чикләрне узганда Россельхознадзор, Роспотребнадзор һәм ФТХ таләпләрен дә катгый үтәргә кирәклеген онытмаска иде. Иминиятләштерү дә мәҗбүри.

Сыр ясау перспективаларын ничек бәялисез?

Шәхсән үзем перспективаларны бары тик яхшыга өметләнеп кенә бәяли алам. Безнең команда көн саен җитештерүне үстерү өчен кирәкле әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итә. Хәзер нәкъ менә перспективалар вакыты. Уңайлылык зонасыннан чыгып, барлык процессларга башка яктан карарга кирәк. Хыялларны тормышка ашыру вакыты җитте! Т

ТЕЛӘЧЕ СЫРЫ: ТЕЛ ЙОТАРЛЫК!

Руфия Фазылова

Сер түгел, санкцияләр һәр өлкәгә кагылды, шул исәптән ул сыр-май җитештерә торган заводларны да читләтеп узмады. Тик Теләче сөт-май заводында проблеманы хәл итү юлын тапканнар. Нинди юллар ул? Чын сыр ничек ясала? Язма шул хакта.

ЗАВОДНЫҢ ЯҢА ТОРМЫШЫ

Әйе, республикада сыр-май заводлары җитәрлек. Мамадыш, Арча, Балтачта гына да көненә йөзәр мең тонна сыр-май җитештерелә. Шулар рәтендә «Нәүрүз» кооперативына караган Теләче сөт-май заводы да бар. Зурлыгы ягыннан алда саналган заводлардан калыша, әлбәттә. Алар тәүлегенә алты-җиде тонна сыр, бер тоннадан артык атланмай ясый. Әмма биш-алты еллап туктап торуын исәпкә алып, соңгы ике елда аның азык-төлек базарында үз кулланучысын табуын Теләче сөт-май заводының зур җиңүе дип карарга кирәк.

Сүз дә юк, көндәшлек көчле. Биредә эшләүчеләр моны яхшы аңлый, шуның өчен бер урында гына торырга җыенмыйлар.

– Март аеннан йомшак сыр ясый башладык, – дип сөйли **Теләче сөт-май заводы җитәкчесе Раилә Хисмәтуллина**. – Технологиясе бик гади – ярымкаты сырны эретеп, табигый тәмләткечләр кушып, эретелгән сыр ясыйбыз. Дөресен генә әйткәндә, үзебездә эшләүчеләр дә аны бик ярата – кибетләрдә көне белән үк сатылып бетә.

– Алайса йомшак сыр линиясен күбрәк эшләп булмыймы? – дим.

– Әлегә юк. Безнең төп эш – ярымкаты сырлар җитештерү, бөтен җиһазлар шуңа көйләнгән. Әлбәттә, йомшак сыр ясау отышлырак: калдыкларсыз җитештерү, сөт тулысынча кулланылышка кереп бетә. Ярымкаты сырларга бернәрсә салмаган кебек, монда да фәкать табигый продуктлар гына кулланабыз: сыер мае, сыр.

Сыр ясаганда сыйфатлы сөт белән яхшы оеткы кирәк. Беренчесе белән проблема юк, Кукмара, Теләче, Балтач районнарыннан сатып алалар. Быел «Нәүрүз» кооперативы үзе дә сыерлар үрчетә башлаган. Ә менә оеткы Италиядән кадәр кайтарыла. Санкцияләр кертелгәч, бермәл заводта куркуга калганнар. Ләкин оеткы мәсьәләсе хәл ителгән:

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

– Бүтән, урау юллар аша алып кайта башладык, – дип елмайды җитәкче. – Әлбәттә, шуңа бәйле оеткының бәясе күтәрелде. Хәер, аның гына түгел, сырны төрә торган махсус пакетларның да хакы артты. Ләкин аңа карап без продукциянең бәясен арттырмадык. Базар бит азык-төлеккә бәяне үзе куя, без, җитештерүчеләр, шуңа яраклашабыз гына.

Нәрсә, без үзебездә оеткы да ясый алмыйбызмы? Раилә Нәкыйп кызы сөйләгәндә, шушы сорау тынгылык бирмәде. Баксаң, үзебезнең оеткы да бар икән. Һәм Теләче сөт-май заводында аны да кулланып караганнар.

– Унбиш көн үзебезнең оеткы белән эшләдек. Әлегә ул сырлар салкында өлгереп тора, – диде җитәкче. – Бер ай торды инде, тагын шуның кадәр вакыт көтәсе. Аннан соң нәтиҗә чыгарып булачак. Әлбәттә, Россиядә ясалган оеткыга өметләнәбез, ул күпкә арзанрак. Әгәр сыйфаты буенча чит илнекеннән калышмаса, һичшиксез, алга таба үзебезнең оеткы белән эш итәчәкбез.

СЫР БИРӘ ТОРГАН СЫЕРЛАР?!

Теләче сөт-май заводында бүген ике төрле сыр – «Голландский», «Российский» сортларын җитештерәләр. Бу урында тагын шуны әйтү мөһим: завод «Нәүрүз» кооперативына карый. Ә алар алга таба да киңәергә планлаштыра. Раилә Нәкыйп кызы: «Кукмара районында мини-парк оештырдык. Хәзер заводның туксан алты баш токымлы сыеры бар», – дигәч аптырап киттем. Баксаң, заманча фермаларны мини-парк дип атыйлар икән. Дүрт ферманы берләштергән, тирә-ягы чәчәккә күмелгән урын бу. Фермада сыерлар да гади түгел – «Швиц» токымлылар. Уналтынчы гасырларда Швейцариядә селекция юлы белән барлыкка китерелгән әлеге сөтлебикәләр узган гасыр азагында Россиягә дә килеп җиткән. Күптән түгел исә «чит ил кунаклары» Кукмара районының Ядегәр авылына да кайткан.

– Бу төр сыерларның иң зур файдасы – сөтләрендә аксым, майлылык бик югары, - ди Раилә Хисмәтуллина. – Швейцариянең яхшы сырларын нәкъ менә «Швиц» сөтеннән ясаганнар, хәзер дә шулай. Шуның өчен әлеге нәселле сыерларга күптән кызыгып йөри идек. Ниһаять, хыял тормышка ашты. Әлегә уналты сыер гына бозаулады, сөтләре бик күп түгел. Шуның өчен аны аерып утырмыйбыз. Ә киләчәктә әлеге токымлы сыерлар сөтен аерым җыеп, сыр ясыйсыбыз килә. Мондый сырның тәме башкарак, тагын да тәмлерәк булырга тиеш, дип өметләнәбез.

– Токымлы сыерларны кайдан алып кайттыгыз? – дим.

– Фураларга төяп Смоленск өлкәсеннән алып кайттык. Сыерлар безнең шартларга тиз ияләнде. Алар салкынга да чыдам, шуның өчен ферманың тәрәзәләренә пыяла түгел, пакет кына куйдык. «Швиц»ларның бердәнбер кимчелеге – башка төр сыерларга караганда сөтне азрак бирәләр.

– Эшне дәвам итү өчен Россиядә ясалган оеткыга өметләнәбез. Әгәр сыйфаты буенча чит илнекеннән калышмаса, һичшиксез, алга таба үзебезнең оеткы белән эш итәчәкбез, – ди Теләче сөт-май заводы җитәкчесе Раилә Хисмәтуллина.

Җитәкче белән сыр заводына кердек. Монда һәр кеше эштә: берәү сөт белән оеткы катнашмасының зур савытта әйләнгәнен күзәтә, икенчесе әзер массаның аппаратта вакланып туралганын тикшерә, өченчесе шул массаның савытларга тутырылганын карый... Ләкин иң беренче эш махсус лабораториядә башлана. Монда сөт сыйфатының физик, химик күрсәткечләр буенча дәүләт стандартларына туры килүе, майлылыгы, тыгызлыгы һәм башка үзенчәлекләре тикшерелә. Төрле консервантлар, майлар, өстәмә тәмләткечләр турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Шунысын да әйтергә кирәк: заводка ветеринария хезмәте белешмәсе булмаган сөт кертелми.

– Бездә ярымавтомат җиһазлар, – дип таныштырып йөрде заводның баш инженеры Радик Хуҗин. – Шуның өчен һәр станок янында бер кеше тора. Заводта сиксәнгә якын хезмәткәр бар. Эшчеләр бер көн эшләп, бер көн ял итә. Тәҗрибәле егет-кызлар, алар белән эшләргә бик җайлы. Хезмәт хаклары утыз мең тирәсе. Район җире өчен бу начар түгел, дип уйлыйм.

Биредә җитештерелгән сөт-майны, Теләчә сәүдә үзәкләреннән башлап, якын-тирә район кибетләрендә сатып алырга була. Шулай ук Казан базарларында заводның аерым нокталары бар. Әлегә күбрәк күпләп сату белән шөгыльләнәләр – зур фураларга төяп, сырны Новосибирск, Санкт-Петербург, Түбән Новгород, Мәскәүгә озаталар.

Тиздән заводта пакетларга тутырып сөт тә сатуга чыгарырга ниятлиләр. Зур цистерна алып кайтканнар инде. «Гел алга таба барырга, продукция төрен арттырырга уйлыйбыз», – диде Раилә Нәкыйп кызы.

...Татар тотып карамыйча ышанмый бит. Завод эшчәнлеге белән танышкач, чисталыкка ис китте: һәр җайланма ялтырап тора. Биредә көн саен эш беткәч бөтен җиһаз 80-90 градуслы кайнар су белән автомат рәвештә юдырыла. Нindидер ят исләр турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Ә сыр, майның фәкать табигый сөттән ясалуын исәпкә алсак, Теләчедә эшләнгән бу затлы ризыкларны курыкмыйча сатып алырга була дигән нәтиҗәгә килдек. Күрдек, авыз иттек, инандык: тел йотарлык, билләһи! Җитмәсә үзебезнеке – Татарстанныкы!

ЭКСПОРТ. МАЙЛАНГАНДАЙМЫ?

Олеся Бондаревская

Татарстанда пешерелгән тәм-томнар белән кайнар чәй эчәргә бездә генә түгел, әйтик, Кытайда да яраталар. Татлы кондитер ризыклары – Татарстан дөньяга бирә алган продукциянең бер өлеше генә. Тик ул моны телиме икән?

Чаллының «Акульчев» бренды Кытай кондитер эшләнмәләре базарына беренчеләрдән булып чыга һәм хиткa әйләнгән «Птичье молоко» конфеты белән анда үз урынын яулый. Бүген Кытай – Татарстанның агросәнәгать продукциясе экспортерлары өчен үсешкә алып баручы тренд. Перспективалы да, чөнки республика җитештерүчеләренең һәм дистрибьюторларының Азия базарларында тупланган эш тәҗрибәсе бар. Беренче чиратта – ул якларның үзенчәлеге өйрәнелде, бу эш бик җиңел түгел. Шул ук Казахстан гына да 19 миллион кеше яши торган гаять зур территория. Биредә авыл хуҗалыгы – эшчәнлекнең төп өлкәсе. Терлекчелек – халыкны – азыктөлек белән, җиңел сәнәгатьне чимал белән тәэмин итүче традицион тармак. Казахстан бөртекле культуралар һәм он буенча иң эре җитештерүчеләр һәм экспортерлар арасына керә. Он экспорты буенча ил дөнья базарында алдынгы урынны били. Бу вазгыятьтә без Казахстанга, башка БДБ илләренә, Төркия, Монголия, Согуд Гарәбстаны һәм Мисырның агросәнәгать җитештерүчеләренә нинди яңа нәрсә тәкъдим итә алырбыз кебек? Әмма бирер нәрсәләр шактый икән...

ТАТАРСТАН ЛАТВИЯДӘН АЛЖИРГА КАДӘР

– Казахстанда Татарстан тәм-томнарын беләләр, алар бик популяр. Казахстан супермаркетларында безнең традицион чәкчәк тә, «Акульчев» продукциясе дә, Mr.Ricco һәм «Махеев» соус һәм майонезлары да,

Фото: Солтан Исхаков, tatar-inform.ru

«Татспиртпром» һәм «Болгар Пиво» эчемлекләре дә, Vivid көнбагыш мае һәм «ЭМИЗ» йөзем эчемлекләре дә тәкъдим ителгән. Биредә казылыкка да, хәтта Татарстанда пешерелгән икмәк-күмәч продукциясенә дә ихтыяҗ бар, – ди Татарстан Республикасының Казахстандагы Тулы вәкаләтле вәкиле Денис Вәлиев.

Татарстан үзенең авыл хуҗалыгы продукциясен дөньяның 54 иленә сата. «Агроэкспорт» агентлыгы билгеләп үткәнчә, бу юнәлештә төп партнерларыбыз арасында Төркия, Казахстан, Латвия, Беларусь, Үзбәкстан, Германия, Польша, Алжир* бар.

Сату күләме буенча беренче урында – көнбагыш, мамык һәм сафлор мае, алар Төркия, Казахстан һәм Алжирга озатыла. 2021 елда әлеге продукция 203,3 млн доллар күләмендә сатылды. Икенче урында – Казахстан, Белоруссия һәм Үзбәкстанга сатылган майонез һәм башка соуслар (50 млн долларга якын). Латвия, Белоруссия һәм Азәрбайҗанга озатылган түп өченче урынны (20 млн долларга якын) биләп тора. Татарстан экспортка чыгарган беренче 10 продукция исемлегенә шулай ук рапс һәм горчица мае, арпа, шоколад, шикәр, кукуруз, майлы культуралар орлыгы, джем һәм мармеладлар да керә. Экспортлана торган продукциянең якынча 60–80%ы Татарстанның үзендә үстерелгән һәм җитештерелгән. «Агроэкспорт» экспертлары 2020–2021 елларда он-кондитер әйберләре (шул ук «Акульчев») экспорты аеруча актив үсеш алды, әмма, тулаем алганда, Татарстан тышкы сәүдә өлкәсендә май продукциясе сатуда махсуслашкан, дип билгеләп үтә.

Татарстан авыл хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2021 елга республика үз җитештерүе хисабына үзен кош-корт ите белән 195%ка, шикәр комы белән – 176%ка, тавык йомыркасы белән – 149%ка, сөт белән – 154%, он белән – 111%ка, бәрәңге белән 109%ка тәэмин итә. Артык җитештерелгәнен экспортларга да мөмкин. Әмма биредә кайбер нечкәлекләр бар.

ЛОГИСТИКА ГАМБИТЫ

– Безгә мөрәҗәгать иткән барлык эшмәкәрләргә без тугандаш республика базары үзенчәлекләрен аңлатабыз. Зур логистик хәрәкәтләр фонында безнең предприятиеләр продукциясе дөньядагы башка җитештерүчеләрнең актив көндәшлеге белән дә очраша, – дип аңлата Денис Вәлиев.

Безнең җитештерүчеләр өчен арта бара торган логистик чыгымнар, шулай ук халыкара көндәшлек авыл хуҗалыгы продукциясе, азык-төлек продуктлары экспорты үсешен тоткарлый. Июнь аенда республика Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы хәбәр иткәнчә, 5 млн тоннадан артык уңыш җыеп алып, шуның 3,5 млн тоннасын эчке куллануга калдырганда, 1 млн тонна чамасы ашлыкны экспортка озатырга мөмкин.

Әйтергә кирәк, Татарстанга ашлык экспорты буенча чит ил җитештерүчеләре белән генә түгел, ә үзебезнекеләр, мәсәлән, соңгы елларда сезонына 10 млн тоннага якын ашлыкны читкә чыгарган Ростов өлкәсе белән дә көндәшлек итәргә туры килә. Ростов өлкәсендә чәчүлек мәйданнары Татарстан белән чагыштырганда бер ярым тапкырга зуррак. Өстәвенә көньяктарак урнашу сәбәпле, уңдырышлылык һәм игеннең үзкыйммәте буенча ул ике тапкырга диярлек ота, чөнки һава торышының тотрыксызлыгы нәтиҗәсендә авыл хуҗалыгында югалтуларга дучар булу куркынычы зуррак булган Татарстанга караганда, андагы чәчүлекләрнең ашлама һәм өстәмә тукландыру чараларына мохтаҗлыгы азрак.

Шулай да соңгы елларда тышкы ашлык базары сыйдырышлыгы 30–40 млн тоннага җитүен исәпкә алганда, сату-алу урыннары җитәрлек дип фаразларга кирәк. Әмма, Татарстан Авыл хуҗалыгы министрлыгында билгеләп үтелгәнчә, сатып алучы илләрдә тариф квоталарын кертү һәм логистик чылбырның катлаулануы республикада җитештерелгән ашлыкны читкә озатуда каршылыклар китереп чыгарырга мөмкин.

* Мәгълүматлар 2021 елның ноябренә

– Элек Чистайдан Польшага ашлык илтүче машина 1,5 мең евро тора иде, хәзер – 4,5 мең евро. Транспорт чыгымнары артты, чөнки Россия һәм Белоруссия машиналары хәзер Европа территориясенә керә алмый, һәм чиктә товар Европа машиналарына күчерелә. Гамәлдәге евро курсы аркасында экспорт бәяләренең артуы да әлеге вазгыятьне артык үзгәртә алмый, – ди «КАМА АГРО +» ҖЧҖ директоры Якуп Дәүләтшин. Компания ашлык, майлы культура орлыклары экспорты белән шөгыльләнә. Соңгы 12 айда компания 3 мең тоннага якын продукция төяп-озаткан, иң зур күләмнәр – Польшага.

– Соңгы ике-өч елда ашлык җитештерүчеләр экспорт юнәлешендә яхшы эшләде, чәчүлекләр киңәйде, яңа техника сатып алынды. Тик бүгенге вазгыятьне һәм ашлык экспортына карата Россиядә гамәлдә булган пошлиналарны исәпкә алганда, аларга табышсыз калу куркынычы яный. Системалы ярдәм таләп ителә, югыйсә аграрийлар табыш китерүче башка культуралар үстерүгә күчәргә мөмкин.

АЛЬТЕРНАТИВАЛАР ВАКЫТЫ

Европада популяр булган Россия үсемлек майлары һәм майлы культуралар белән тәэмин итүчеләр дә катлаулы хәлдә калган.

– Без горчица, алтын һәм көрән җитен орлыгы, майлы торма һәм башка культураларны Польша, Германия, Голландия, Италия, Венгрия, Белоруссия, Казахстан, Монголиягә чыгарабыз, күп очракта автотранспорт җәлеп ителә. Продукциянең якынча 50%ы Татарстанда җитештерелгән. 2020 елда 5 мең тонна төяп-озаттык, 2021 елда – 6 мең тонна, керем 6 млн еврога җитте. Якын киләчәктә 10 мең тоннага чыгарга планлаштырган идек, әмма хәзер безнең товар чыгару күләме 5–6 тапкыр кимеде, – дип сөйли «АГРО-РОСТ ЭКСПОРТ» ҖЧҖ директоры Илдар Сәлахов.

– Европада сату-алулар яхшы барды, әмма хәзерге вакытта башкалар кебек үк проблемалар белән очраштык, – ди «ПАРТНЕР ЭКСПОРТ» директоры Евгений Вернев. Аның компаниясе 2020 елда гына экспорт бизнесына кушылган. 2021 елда 1 мең тонна майлы һәм башка культуралар орлыгын төяп-озатканнар.

– Башка мөмкинлекләрне өйрәнәбез. Кытайга рапс мае һәм майлы җитен экспортлау өчен җирле электрон сертификация системасында теркәлү шарт булып тора. Хәзер Россельхознадзор белән әлеге мәсьәләне хәл итәбез. Төркиядә киндер орлыгы зур кызыксыну уятты, әмма хәзер анда таләп ителгән күләмдәге йөкне бары тик диңгез юлы белән генә җибәрергә мөмкин. Тик контейнерларга кытлык һаман да дәвам итә. Нәтиҗәдә, калган проблемалар фонында ашлыкның бәясе бик нык арта. Әлегә бу мәсьәлә ачык кала бирә.

– Бер яктан безнең эшчәнлекне Россиядә май продукциясенә кертелгән экспорт квоталары чикли, икенче яктан – тариф экспорт квоталары. Июль аенда алар бер тонна көнбагыш мае өчен якынча 600 долларны тәшкил итәчәк. Нәтиҗәдә безнең тышкы базар бик нык үзгәрде. Хәзер без аерым таможня шартларына ия Евразия икътисадый берлеге илләре, атап әйткәндә, Белоруссия, Әрмәнстан, Казахстан белән генә сәүдә итә алабыз, – ди «Вивид» ҖЧҖнең тышкы икътисадый эшчәнлек буенча директоры Павел Корчагин. – Әмма без бүгенге вазгыятьтә дә бик күп мөмкинлекләр күрәбез. Безнең экспортка чыгарыла торган төп продукт – беренче салкын ысул белән сыгылган көнбагыш мае (экстра вирджин). Мәсәлән, Европада аңа ихтыяҗ зур, шуңа күрә үз вакытында без халыкара сыйфат сертификаты алган идек, бу хәзер бик булыша. Башка тәэминатчылар (әйтик, дөньяда иң күп пальма мае җитештереп, барлык үсемлек мае базарының 35%ка якынын алып торган Индонезия әлеге майны сатуын туктатты) бушаткан урыннарга таба хәрәкәт итеп, без актив эшлибез.

Шул ук вакытта экспертлар, Татарстан агросәнәгать комплексы продукциясенә ихтыяҗ сакланачак, дип билдерә.

– Республиканың күптәннән бергә эшли торган партнерлары бар, һәм аларның ике-өч ел эчендә әлеге хезмәттәшлекне алыштырырдай алмаш таба алуы икеле. Чөнки бу бик зур көч, вакыт таләп итә торган хезмәт. Моннан тыш, төрле факторларны исәпкә алырга кирәк. Мәсәлән, корылык аркасында Һиндстан быел экспортка ашлык чыгара алмый. Африка, Азия, гарәп илләре – алар барысы да ашлык сатып алуга мохтаҗ, – дип билгеләп үтә Якуп Дәүләтшин.

– Чыннан да, продукциягә карата кызыксыну саклана, мәсәлән, Германиядә, әмма бу хезмәттәшлек мөмкин түгел, чөнки Европа банклары Россиягә түләүләрне җибәрми. Польшада кайбер партнерлар сумнарда түләүгә күчте, әмма төп өлеше китте, – ди

«АГРО-РОСТ ЭКСПОРТ» ҖЧҖ директоры Илдар Сәлахов. – Хәзер без Төркия, Мисыр, Кытай кебек илләр белән экспортны җайга салу юнәлешендә эшлибез. Әмма бу процесс тиз була алмый. Башта безнең үрнәкләр экспертиза узарга тиеш, аннары гына сөйләшүләр башлана. Әмма экспорт безгә кирәк, чөнки продукциягә эчке ихтыяҗ һәм эшкәртү мөмкинлекләре дә алай ук күп түгел.

Павел Корчагин сүзләренә караганда, потенциаль экспорт товарын канәгатьләндерергә тиешле төп критерийлар – тотрыклы сыйфат һәм күпләп сату мөмкинлеге. Күп кенә сатып алучылар бүген элегрәк әзер булмаган шартларга риза, мәсәлән, 100% алдан түләп куюга. Тик шул ук вакытта финанс куркынычы да арта.

– Минемчә, төбәк экспортын үстерүгә бу җәһәттән иң актив компанияләргә дотацияләр бирү, ташламалы салым һәм кредит шартлары тәкъдим итү булышыр иде. Ул чакта республиканың яңа базарларны яулау һәм анда калу мөмкинлекләре күбрәк булачак. Өстәвенә, безнең авыл хуҗалыгы продукциясенә ихтыяҗ бар. Мәсәлән, бездән генә дә ашлама җитештерүчеләр белән элемтә урнаштырырга булышуны берничә мәртәбә сорадылар, – ди Корчагин.

КЫТАЙГА АЧКЫЧ

Экспортерлар проблемаларын Татарстанның чит, шул исәптән ислам илләрендәге потенциаль партнерлары белән җайланган бәйләнешләр хәл итәргә булыша ала. Республиканың чит илләрдә 13 тулы вәкаләтле һәм сәүдә-икътисадый вәкиллеге бар.

Хәләл виноград эчемлеге җитештерүче «Эмиз» ҖЧҖ директоры Раил Фазылҗанов билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта компания эчке базарда сатуны арттыру белән шөгыльләнсә дә, Үзбәкстан, Казахстан, Кыргызстанга товар озату да җайга салынган, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә, Согуд Гарәбстанында, Катарда потенциаль партнерлары бар. Кытай белән сөйләшүләр алып барыла.

– Продукцияне экспортка чыгару юнәлешендә аерым проблемалар юк. Федераль проектлар бар. Мәсәлән, Россия экспорт үзәге логистика чыгымнарын 80% ка кадәр компенсацияли. Өстәмә кыйммәткә салымны кире кайтару бар. Татарстанның үзендә беркайда да гамәлдә булмаган программалар эшли. Татарстан Эшкуарлыкка ярдәм итү фонды беренче мәртәбә экспорт контрактын төзегәндә түләүсез ярдәм күрсәтә. Без Россиядә һәм халыкара дәрәҗәдә оештырылган күргәзмәләрдә даими катнашабыз. Фонд, Инвестицияле үсеш агентлыгы һәм Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы күргәзмәләрдә стендларны оештыру, челтәр компанияләр белән сөйләшүләр алып бару чыгымнарын үз өстенә ала. Бу безгә һәр чарада берничә йөз мең сум акчаны янга калдырырга булыша, – ди Фазылҗанов.

– Берләшкән Гарәп Әмирлекләре базары зур, экспорт өчен максатчан аудитория бар. Әмма аның белән эшләргә кирәк. Бу илдә эшләргә теләгән компания маркетинг тикшеренүләре үткәрергә, ихтимал, биредә үз филиалын яки вәкиллеген ачарга әзер булырга, коммуникацияләрне җентекләп үстерергә тиеш. Мин бу юнәлештә теләсә нинди консультатив ярдәм күрсәтергә әзер, – ди Татарстан Республикасының Дубайдагы сәүдә-икътисадый вәкиле Тимур Хәйретдинов.

Татарстан Республикасының Казахстан Республикасындагы Тулы вәкаләтле вәкиллеге хезмәткәрләре шулай ук экспортерларга сәүдә стратегиясен формалаштыруда ярдәм итәргә әзер. Сорау буенча алар Казахстан кибетләре киштәләрендә Татарстан товар җитештерүчеләре өчен шундый ук продукцияләрне фотога төшерә һәм җибәрә.

– Зур логистик һәм склад чыгымнарын истә тоткан хәлдә, Татарстан компанияләренә үз продукцияләрен Казахстан базарына көндәшлеккә сәләтле бәяне саклап илтеп җиткерергә кирәк. Эре сәүдә-логистика үзәкләре белән хезмәттәшлекне көздә тотып, без Казахстандагы партнерлар белән эшлибез, – ди Денис Вәлиев. – Шул ук вакытта без Казахстан белән хезмәттәшлек иткәндә үзара сәүдәне генә түгел, ә бәлки Азия һәм Европага чыгу өчен уртак продукция булдыру вариантларын да карарга тиеш. Чөнки Казахстан – Кытай Халык Республикасы чигендә махсус икътисадый зоналарда җитештерүләр урнаштыру өчен уңайлы мәйданчык.

ӘТИ ҺӨНӘРЕНӘ ТУГРЫ КАЛЫП…

Руфия Фазылова

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр… Кырлайга баргач, Тукайга ияреп, иң әүвәл аның табигатенә сокланасың. Аннан инде халыкның яшәү рәвеше, көнкүреше белән кызыксынасың. Бүген соңгысы бигрәк тә актуаль, чөнки авылларда эш урыннары бармак белән генә санарлык. Биредә исә бу проблеманы хәл итү юлын тапканнар.

Арча районындагы «Кырлай» агрофирмасын республикада да яхшы беләләр. Гаҗәп тә түгел: Татарстанда җитештерелә торган бәрәңгенең алтмыш процентын монда үстерәләр. Бәрәңге уңышын җыярга алар беренчеләрдән булып чыга, чөнки бик иртә өлгерә торган сортлар да бар. Мең гектар җирдән узган ел 251 центнер икенче икмәк җыеп алганнар. Былтыр бәрәңгене вакуумлап төреп сатуга чыгарганнар. Моннан тыш, чөгендер, кишер, кәбестә һәм бөртекле культуралар да үстерәләр.

«Кырлай» агрофирмасы карамагында бүген 10732 гектар җир бар. Нигездә алар халыкның пай җирләре. Агрофирма Арча районының ун авылында эшли. Димәк, бу авылларда буш җирләр юк дигән сүз, ә халкы эш белән тәэмин ителгән. Хуҗалыкта әлегә 94 кеше көч куя, аларның 37се үсемлекчелек өлкәсендә, 21 – терлекчелек тармагында.

«Кырлай» агрофирмасы авыл хуҗалыгы өлкәсендә күптәннән эшли. 2003 елда аны РФнең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, ул чакта «Сервис-Агро» ҖЧҖ директоры Габделхәй Кәримов оештыра. Ни кызганыч, Голландия, Германиягә барып, авыл хуҗалыгы тармагын өйрәнгән, алтынчы чакырылыш ТР Дәүләт Советы депутаты булган тынгысыз җитәкче Габделхәй Йосыф улы кинәт вафат була. Бүген аның эшен балалары дәвам итә.

– Әти исән чагында ук Арчага күченеп кайттык, гаиләм дә хәзер биредә яши, - диде Марат Кәримов. – Мин шәһәрдә туып-үскән егет булсам да, кечкенәдән әти-әни белән Арча районына кайтып йөрдек. Әти гаҗәп дәрәҗәдә кешелекле иде, без аның тәрбиясен алган балалар. Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтында укыганда ук Арча районының Наласа авылында урнашкан «Натуральный продукт» сөт комбинатында эшли башладым. Сөт сату нокталарын төзедек, кыскасы, авыл хуҗалыгы тармагын өйрәндем.

«Кырлай» агрофирмасына Марат Габделхәй улы 2018 елда килә. Аңлашыла, депутат буларак этисенең вакыты тыгыз, ә авыл хуҗалыгы белән читтән торып кына идарә итеп булмый. Шуның өчен дә тәҗрибә туплаган егет агрофирманың эшен дәвам итү, үстерүне үз кулына ала.

– Август ае, урып-җыю эшләре башланган иде, – дип дәвам итте җитәкче. – Иң беренче кырлар белән танышып чыктым. Менә шунда җир эшенә карата тагын бер кат ихтирам, мәхәббәт уянды...

«Кырлай» хуҗалыгы нигездә бәрәңге, яшелчә үстерү белән шөгыльләнә. Соңгы елларда терлекчелек һәм үсемлекчелек тармагын да колачларга уйлаганнар.

– 2017–2020 елларга каралган капиталь төзекләндерү программасы буенча Иске Иябаш, Бирәзә авылларында 200 башка исәпләнгән сыер фермаларын яңарттык, – диде Марат Габделхәй улы. – Ә Яңа Кырлайда бәрәңге саклау базасын төзекләндердек. Әле менә Иске Иябаш авылында 1800 башка исәпләнгән мегаферма төзеп ятабыз. Ул заманча ферма булачак. Кыскасы, бер урында гына тормыйбыз, гел үсәргә, авыл хуҗалыгы өлкәсендәге яңа технологияләрдән артта калмаска тырышабыз.

...Шәһәр балалары авыл тормышын кайдан белсен?! Гадәттә, без шулай дип фикер йөртәбез. Әтиләре һөнәрен дәвам итүче Кәримовлар исә моның киресен раслый. Белү генә түгел, алар аны күңел күзе белән дә күрә.

Фото «Кырлай» агрофирмасыннан алынды. РЕКЛАМА

Акыллы гамәлләр
игелекле эшләр
мәңгелек кыйммәтләр /

Бу санда тәкъдим итәбез:

НИ ӨЧЕН сарманлылар матуррак җырлый

КАЙСЫ районда иң сөйкемле җирлек башлыклары яши

103 яшьтә дә **НИЧЕК** модадан калышмаска

Подкогольо белән **КАЙДА** сыйлыйлар

Хыяллар **КАЙДА** чынга аша



ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН

САРМАН РАЙОНЫ



ман муниципаль районы циясе архивыннан алынды

Сарман районы быел җәй бертавыштан җирдәге иң шәп урын дип табылды. Биредә бөтен нәрсә гөрләп чәчәк ата, үсә. Район Татарстанның алты районы (Тукай, Минзәлә, Мөслим, Азнакай, Әлмәт һәм Зәй) белән чиктәш, һәм шуның нәтиҗәсендә биредә һәр күршедән ниндидер үзенчәлек кушылу сизелеп тора. Бу Сарман җиренә кабатланмас төсмерләр өсти.

ФӘРИТ ХӨСНУЛЛИН, САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ:

– Сарман җиренә килгән һәркем биредәге гүзәллекне күреп таң кала. Өстәвенә, бездә әле уникаль, бик кызыклы кешеләр яши. Алар тыныч авыл тормышы һәм сәламәт эшкуарлык, гаҗәеп тырышлык арасындагы балансны саклый. Ә безнең Сарман сандугачлары ничек матур җырлый! Илһам Шакиров, Зөһрә Сәхәбиева, Зөһрә Шәрифуллина, Гөлдания Хәйруллина... Кайсын гына алма – легенда! Мин үземнең якташларым белән горурланам! Нәкъ менә аларның иҗаты татар теленә һәм халык гореф-гадәтләренә иң шәп реклама булып тора.

АКЫЛЛЫ ДА, ЧИБӘР ДӘ

Районның төньяк-көнчыгышына юл тотабыз. Иң хезмәт сөючән халык һәм иң алдынгы авыллар шунда, диләр. Бу исә анда иң гүзәл кызларның җитәкчелек итүеннәндер. Мондый чибәрләр Сарман җирендә генә туа ала.

Саклаубаш авыл җирлегендә безне аның **башлыгы** – акыллы, чибәр, соңрак ачыкланганча, әле спортчы да булган **Лилия Габидуллина** каршы алды. Аның авыл урамнарында биек үкчәле туфлидән йөгереп йөрүе күп нәрсә турында сөйли – әйтик, бирседәге юлларның нинди яхшы булуын күрсәтә.

– Безнең җирлеккә дүрт авыл керә: Алга, Саклаубаш, Яңа Саклау, Өчәйле Саклау. Биредә 900 дән артыграк кеше яши, – дип сөйли Лилия Мансур кызы һәм административ үзәк буйлап экскурсиягә чакыра. – Урта мәктәп тә, балалар бакчасы да, участок хастаханәсе дә, Алга һәм Өчәйле Саклау авылларында исә ФАПлар да бар. Клублар – һәр авылда, ә биредә исә, үзегез күрәсез, безнең горурлыгыбыз булган Мәдәният йорты эшли, аңа 2019 елда президент программасы буенча капиталь ремонт ясадык.

– Шундый нәфис кенә ханым шулкадәр зур хуҗалык белән җитәкчелек итәргә ничек өлгерә соң?

– Мин спортчы бит, – дип елмая җирлек башлыгы. – Тиз йөгерәм. Өйдә әле минем 12 сыерым һәм тагын 100 гектар җирем бар. Ягъни әле мин фермер да. Берьюлы ике урында эшлим. Гәрчә үзем педагогик белемле белгеч булсам да. Минем бөтен гаиләм – укытучылар, династия безнең. Әмма педагогика – менә минеке түгел инде! Менә минем күңелгә яткан эшем, – дип башлык Саклаубаш киңлекләренә ишарәли, – җирлек белән җитәкчелек итү. Өйдә исә ирем һәм өч кызым булыша!

– Алар өчесе дә сезнең кебек үк акыллы-чибәр-спортчымы?

– Үзегез карагыз менә, – дип елмая Лилия һәм телефоннан гаиләсен күрсәтә. Шуннан соң барысы да сүзсез дә аңлашыла.

– Мин бу вазыйфада биш ел эшләү дәверендә барлык казанышларыма җирле халык, Президентыбыз һәм районыбыз башлыгы Фәрит Мөнәвир улы Хөснуллин ярдәме белән ирештем. Без барлык республика программаларында актив катнашабыз. Авыл хуҗалыгы министрлыгы ярдәмендә һәм үзсалым программасы акчасына парк төзедек, Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларыбызга куелган һәйкәлне ремонтладык, быел менә паркта утыртыр өчен агачлар сатып алдык... Һәрвакыт хәрәкәттә. Безнең җирлектә алты крестьян-фермер хуҗалыгы бар! Алты гаилә мини-ферма тота, ит терлеге асрый, сөт тапшыра. Без үзебез сөтне Мөслимгә илтәбез, аны сатып, аена 50–70 мең сум акча эшлибез.

Биредә эшләү һәм яшәү өчен бөтен шартлар тудырылган. Дискотекалар үткәрәбез, бәйрәмнәр оештырабыз. Күп кеше шәһәрдән туган авылына кире кайта. Чөнки бездә бик рәхәт, матур, кызык, мул.

– Сез дә бирегә укудан соң ук кире кайттыгызмы?

– Мин әбигә кунакка кайткан идем – кияүгә чыктым да монда калдым.

– Ә педагогтан ничек итеп башлыкка әйләндегез?

– Халык эшләгән кешене сайлый ул.

Фото: Александр Ефремов

1

Лилия Габидуллинаның авыл урамнарында биек үкчәле туфлидән йөгереп йөрүе күп нәрсә турында сөйли – әйтик, биредәге юлларның нинди яхшы булуын күрсәтә.

2

– Өйдә исә ирем һәм өч кызым булыша! – ди Лилия.

3

Тагын бер гүзәл ханым – Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы Вероника Хөсниева.

4

Авыл музеенда экскурсияне Рафис Әүбәкеров алып бара.

Саклаубаштан Чурашка юнәләбез. Биредә безне тагын бер сөйкемле ханым – **Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы Вероника Хөсниева** каршы ала. Чураш та бу җирлеккә керә. Соңгы арада андагы хосусый музей авылның иң истәлекле урыннарыннан берсенә әйләнгән. Аны теләгән һәркем бушлай кереп карый ала.

5

– Барысы да менә шушы кайчыдан башланды, – дип Рафис безгә әлеге раритетны күрсәтә.

6

Музейны булдыруда РСФСРның атказанган укытучысы Вәсимә Лотфулла кызы Хәйруллина булыша.

АВЫЛ МАСШТАБЫНДАГЫ МУЗЕЙ

Музей хуҗасы – **машина йөртүче Рафис Әүбәкеров**. Ул гомере буе ташландык авыллардан, кеше яшәми торган иске йортлардан борынгы предметларны җыя, чистарта, үзенең остаханәсендә яңарта һәм гаражының диварына элеп куя, пөхтәләп киштәләренә урнаштыра... Шулай үз күңелен генә юатып йөргән булыр иде әле һаман, әмма **укытучысы Вәсимә Лотфулла кызы Хәйруллина** (хәзер ул абыстай, балаларга ислам нигезләрен өйрәтә), авылдашлары да раритетлар белән хозурлансын өчен, аны гаражыннан музей ясарга күндерә. Хәзер РСФСРның атказанган укытучысы Вәсимә Лотфулла кызы үзен «ярдәм төркеме» дип атый һәм үзенең элекке укучысы Рафис Әүбәкеров белән безне гараж артына чакыра, анда исә музейның булачак экспонатлары – узган гасыр башыннан калган кыскычлар, үлчәүләр, үтүкләр, ышкылар, СССР дәверендәге сукайнаткычлар яшел чирәмдә үз сәгатен көтеп ята.

– Барысы да менә шушы кайчыдан башланды, – дип Рафис безгә әлеге раритетны күрсәтә – Бу тәүге экспонат. Галәветдин лампасы бар бит, менә Габдулла кайчысы да бар – минем псевдоним ул «Габдулла», – дип аңлата Рафис. – Башта барысын да гаражда җыя идем, аннары бу әйберләр миңа машинамнан кадерлерәккә әйләнде дә, аны урамга чыгарырга туры килде.

– Аның әле реставрация үлмәсе дә бар, – ди Вәсимә Лотфулла кызы. – Музейга әйберләр шул кабинет аша үткәннән соң гына керә. Рафис – чын оста, ул теләсә нинди әйберне яңарта, төзәтә ала.

– Музей ук түгелдер инде, – дип бераз каушый Рафис. – Тәгәлрәге – тарихи почмак. Әгәр без үткәннәрне белмибез икән – киләчәгебез дә булмаячак, дигән гыйбарә мәктәптә укыганда ук хәтеремә сеңгән иде. Әби-бабаларыбызга көндәлек хезмәтләрендә кирәк булган эш кораллары, көнкүреш кирәк-ярагын нәкъ менә шуңа күрә җыям да.

– Мәктәп балалары бу экспонатларны карарга килә, – дип өсти Вәсимә Лотфулла кызы. – Мин Вероника Вячеславовнага әйтәм инде, бездә шундый кеше булгач, барлык кунакларны да аның янына алып килергә кирәк, дим. Ул – авылыбызның йөзе, игелекле эш белән шөгыльләнә, инде дистә елга якын әлеге әйберләрне җыя – бер генә иске йортны да карамый калмый, һаман яңа экспонатлар таба.

– 2023 елда гына ун ел була әле, – дип төгәллек кертә музей хуҗасы. – Мин үземнең бу эшемне әниемә багышлыйм, ул яшәгән заманны, ул вакыттагы көнкүреш шартларын хәтеремдә сакларга телим...

ӘНИНЕ ТЫҢЛАРГА КИРӘК!

Җирлек башлыгы безне Карашай-Саклаудагы июньдә 103 яшен тутырган **Зәкия Насыйбулла кызы Шәйдуллина** янына алып бара.

Әбекәй кунакларны яңа кызыл күлмәктән каршылый.

– Әни һәр вакыйгага үзенә яңа күлмәк тегүебезне үтенә, – дип сөйли аның **кызы Розалия.** – Менә бу ал төстәгесен туган көненә тектердек. Бу кызылын – махсус «Татарстан» журналы белән очрашу өчен. «Мине фотога төшерәчәкләр бит! Бер тапкыр фотога төшкән күлмәкне икенчегә кия алмыйм бит инде мин», – ди әни.

– Ул безне һәрвакыт тонуста тота, ялкауланырга ирек бирми, – дип сөйли кызы Лилия. – Нәрсә эшләргә кирәген һәрвакыт хәтерендә тота һәм иртән һәркемгә эш бүлә: бу җирне казырга, бу түтәлне утарга, тәрәзәләрне юарга, ашарга пешерергә... Без ул кушканны үтибез. Әнине һичшиксез тыңларга кирәк.

СЫЕРЛАР ҺӘМ ГӨЛЛӘР

– Карлыгач, Йолдыз, Акбаш, Шомырт, Чәчкә, Алмачуар, Дочка, Бәләкәч, Миләш, – дип, үзенең сыерлары белән таныштыра **Гөлфия Фәхразиева.** Ул үзенең игезәге Әлфия белән шәхси фермерлык хуҗалыгында эшли, анда тугыз сыер һәм 300ләп баш кош-корт асрала.

– Безнең белән тагын абыебыз Нәҗип Габделмәнов һәм бертуганымның кызы Алия эшли, – дип таныштыра бергә эшләүче туганнары белән Гөлфия.

– Гөлфия бөтенесенә дә өлгерә ул, – ди Вероника Вячеславовна. – Гөлләрен генә күрегез сез аның, искиткеч матур бит! Сөтлегән, яран... Үсентеләрен Мәскәүдән яздырып кайтарта, аннары үрчетә.

Матур йорт каршында, чүлмәктәге хуш исле гөлләр янында фермерларның барысын бергә истәлеккә фотога төшерәбез.

– Идеяләребезне хуплаган өчен район башлыгына рәхмәт. Авыл хуҗалыгына ярдәм итүче программалары өчен, тырыш гаиләләргә булышлык күрсәтүе өчен Президентыбыз Рөстәм Нургали улына рәхмәт! Безнең җирлектә 7 мини-ферма бар, 5 гаилә һәркайсы ун баштан артыграк сыер асрый! Без районда гына түгел, республикада да алдынгылар сафында – барысы да халкыбызның тырыш булуы хисабына. Алар терлекләрнең баш санын киметмәс өчен бирелгән субсидияләр сыйфатындагы республика ярдәменә бик рәхмәтле булып яши.

7 – Карлыгач, Йолдыз, Акбаш, Шомырт, Чәчкә, Алмачуар, Дочка, Бәләкәч, Миләш, – дип, үзенең сыерлары белән таныштыра Гөлфия Фәхразиева.

8 Матур йорт каршында фермерларның барысын бергә истәлеккә фотога төшерәбез.

9

11

– АЗЫК-ТӨЛЕК КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫН 100% КА ГАРАНТИЯЛИБЕЗ!

«Татарстан» кунакка барганда апрель азагы гына иде, ул вакытта чәчелгән бөтен нәрсә: арпа, бодай, солы, борчак, карабодай, кукуруз, шикәр чөгендере, рапс, горчица бүген инде бу кырларда матур гына өлгереп килә... Сарман районының «Агросила» АҖ «Нөркәй» агрофирмасына караган иксез-чиксез кырлары ул чакта кап-кара иде. Язгы чәчү көннәрендә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең матбугат белән аралашуы бик кыска, озаклап сөйләшеп торырга вакытлары юк:

– Безгә бөтен шартлар тудырыла, чәчкечләребезнең нинди икәнен күрәсезме! – ди **авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Альберт Шәрипов**.

– Проблемаларсыз, туктап торуларсыз эшлибез – бу бит үзе бер ләззәт! – дип өсти **авыл хуҗалыгы идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге башлыгы Илнур Салихов**.

– Гомумән алганда, азык-төлек куркынычсызлыгын 100%ка гарантиялибез! – дип вәгъдә бирә **«Уңыш» җитештерү комплексы идарәчесе Рөстәм Разумбетов**.

9, 10

Чәчүгә кадәр һәм чәчүдән соң.

11

Альберт Шәрипов, Илнур Салихов, Рөстәм Розумбетов Татарстанда азык-төлек куркынычсызлыгын 100 процентка гарантияли.



ҖӘЛИЛ ҺӘМ ҖӘЛИЛЛЕЛӘР

Җәлил шәһәр тибындагы бистәсе күптән инде Сарман районының гына түгел, бөтен республиканың визит карточкасы булып тора. Биредә 19 милләт вәкиле булган 13 меңнән артык кеше яши.

Бүген бу Татарстандагы социаль юнәлештәге объектлар белән тәэмин ителгән иң яхшы торак пунктлардан берсе санала.

– Безнең бистә тарих үлчәмнәре буенча бик яшь әле – быелтыр аңа 60 кына тулды, – дип сөйли **«Җәлил штб» МБ башлыгы Рәфыйк Кәримов.** – Географиясенә килгәндә, өч район – Сарман, Әлмәт һәм Азнакай чигендә урнашкан.

Бистә төзекләндерелгән, җыйнак, уңайлы инфраструктурага ия: мәктәпләр, түгәрәкләр, спорт секцияләре, парклар һәм стадионнар барысы да янәшәдә генә, балалар үзләре генә дә йөри алырлык ераклыкта урнашкан. Балалар исә биредә бик күп!

МУЗЫКАЛЬ ҖӘЛИЛ

М.Г.Йөзлебаев исемендәге музыка мәктәбендә безне җыр-бию белән каршы алдылар. Җәлилдә яки якын-тирәдәге авылда яшәүче баланың күңеле музыкага тарта икән, биредә ул һичшиксез җаны тарткан юнәлешне һәм коллективны сайлый алачак:

йә «Экспромт» балалар тынлы оркестрында;

йә «Шатлык» татар инструменталь ансамблендә;

йә «Кәеф», «Ихлас», «Елмай» вокаль ансамбльләрендә;

йә «Өмет» гармунчылар ансамблендә;

йә булмаса «Җәлил тальянчылары» ансамблендә. Сүз уңаенда, бервакыт Республика көнөнә багышланган «Уйнагыз, гармуннар!» фестивалендә Җәлил балалар музыка мәктәбенә оста Халитов ясаган тальянны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов үзе тапшырган!

– Биредә 120 бала фортепиано, скрипка, баян, гитара, труба, кларнет, саксофон, флейта, курай, гармунда уйнарга, хорда җырларга, вокалга өйрәнә, – дип нәтиҗә ясый **мәктәп директоры Лилия Дәүләтшина.**

СӘНГАТЬЛЕ ҖӘЛИЛ

Җәлил сәнгать мәктәбендә – бөтен җир сәнгать әсәрләре белән тулы. **Директор Гөлзирә Гыйльметдинова** әлеге мәктәптә укучыларның хезмәтләре эленгән диварларны горурланып күрсәтеп йөри. Алар шулкадәр матур ки, үзеңнең дә рәсем ясыйсың, картиналар язасың, киез, батик, агач, ташлардан, җеп-бау-корамалардан сәнгать әсәрләре тудырасың килә башлый... Җәлил сәнгать мәктәбендә укучы яшь рәссамнарны сораштырып карагыз әле – теләсә нинди әйбердән дә гүзәл әсәр иҗат итә алабыз, дигән җавапны ишетерсез!

СПОРТКА ГАШЫЙК ҖӘЛИЛ

Ә менә «Батыр» спорт-сәламәтләндерү комплексында шөгыльләнүче яшь спортчылар рекордлар куюга хирыс. Кубок һәм дипломнар белән бөтен дивар тулган! Волейболчылар, баскетболчылар, боксчылар, йөзүчеләр... Спорт белән шөгыльләнергә, уйнарга, йөзәргә бирегә өлкәннәр дә йөри. Узыш автомобильләрендә җилдерүче спортчылар исә осталыкларын Сарман аэропорты территориясендәге картинг-клубта чарлый.

Гомумән алганда, Җәлил – спорт бистәсе дә. Музыка-сәнгать юнәлеше белән...

ЯШЬ ЖУРНАЛИСТЛАР

Бу кызыклы тормыш турында исә, башкала матбугаты язып өлгергәнче үк, «ДеТVора»

мәктәп интернет-телевидениесенең яшь журналистлары сөйләп тора. Кунаклар бусагадан атлап керүгә үк, микрофон-камера-телефон тоткан Җәлил балалары аларны камап та ала – һәм һәр кунак эфир йолдызына әйләнә. Без дә йолдызга әйләнми калмадык әлбәттә.

– Сезгә Җәлилдә иң ошаганы нәрсә булды? Бала чагыгызда Җәлилдә яшәсәгез, укудан буш вакытта нәрсә белән шөгыльләнер идегез?

– Сезнең бистәдә иҗади сәләтләрне үстерү өчен искиткеч шартлар тудырылган, – диде «Татарстан» журналының баш мөхәррире Татьяна Вафина. – Мин, мөгаен, сәнгать мәктәбеннән башлар идем: бистәгез бик матур, аны сурәткә төшерәсе килә!

Сәфәребездән кунакчыл Сарманга сокланып кайттык. Биредә бер мәртәбә булган кеше һичшиксез яңадан бу якларга әйләнеп кайтачак.

МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘР ТӘМЕ

Җәй фасылы үзенә бик күп бәйрәмнәрне, йола-гадәтләрне сыйдыра.

Татарстанда яшәүче һәр халык җәйге матур көннәрдә, гадәттәгечә, дус-туганны, күрше-күләнне Каравон, Семык, Сабантуй, Акатуй, Питрау, Валда шинясь кебек милли бәйрәмнәргә чакыра...



КАРАВОН – РУС ХАЛЫК БӘЙРӘМЕ

ТР Лаеш районының Никольское авылы

2022 елның 28 мае.

Фото: Александр Ефремов

НӘРСӘ БӘЙРӘМ ИТӘЛӘР:

Николай Чудотворецка багышланган Каравон рус халык бәйрәме. «Каравон» – аерым ысул белән башкарыла торган үзенчәлекле әйлән-бәйлән ул: бер-берсенең чәнти бармагына тотынышып, катнашучылар «каравон» адымы белән әйлән-бәйләнне бер зурайтып, бер кечерәйтеп, акрын гына түгәрәк буенча әйләнә. Бәйрәм халык уеннары, кул сугышы, яшьләр күңел ачулары белән тәмамлана.

Каравон Татарстан халыкларының традицион бәйрәмнәрен башлап җибәрә. Аның артыннан мари, чуваш, татар халык бәйрәмнәре вакыты җитә.

НӘРСӘ БЕЛӘН СЫЙЛЫЙЛАР:

«Менә шундый киңлектә, менә шундый зурлыкта» дип җырланган балалар җырындагы традицион күмәч белән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановны да сыйлыйлар.

СЕМЫК – МАРИ ХАЛЫК БӘЙРӘМЕ

ТР Әгерҗе районының Кадрәк авылы.

2022 елның 4 июне.

Фото: Динара Гобәйдуллина

НӘРСӘ БӘЙРӘМ ИТӘЛӘР:

Семык – мари халкының традицион бәйрәме. Ул җәйге бәйрәмнәр циклы башлануын аңлата. Төп идея: вафат булган туганнарны искә төшерү, алардан хуҗалык һәм көнкүреш эшләренә фатиха алу. Бу көнне яңгыр яуса, моны яхшыга юрыйлар.

НӘРСӘ БЕЛӘН СЫЙЛЫЙЛАР:

«Татарстан Республикасы мариларының милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Олег Третьяков кунакларны **подкогольо** (эчлеге эремчектән ясалган вареник) һәм **күгече когольо** (ярма һәм ит бөккәне) белән сыйлый.

ТАТАР ФЕДЕРАЛЬ САБАН ТУЕ

Ульяновск шәһәре.

2022 елның
17–18 июнь көннәре

Фото: Александр Ефремов

НӘРСӘ БӘЙРӘМ ИТӘЛӘР:

Сабантуй язгы кыр эшләре тәмамлануны аңлаткан халык бәйрәме. Бәйрәмгә, һичшиксез, ярыш рухы хас: ат чабышы, көрәш, баганага үрмәләү, катыктан акча эзләү, капчык сугышы һәм башка күңелле ярышларда һәркем беренчелеккә омтыла.

Сабан туе инде күптәннән Татарстан Республикасы чикләреннән чыкты. Быел федераль Сабантуйны уздыру урыны итеп Ульяновск каласы сайланды.

НӘРСӘ БЕЛӘН СЫЙЛЫЙЛАР:

Әлбәттә, татар халкының милли татлы ризыгы чәкчәк белән! Аны һәрвакыт туйларга ясыйлар, сабан туе да искәрмә түгел. Сыйлаганда «чәкчәк кебек бер-берегезгә ябышып тату яшәгез, балаларыгыз чәкчәк санындай күп, тормышыгыз чәкчәк кебек татлы булсын, өеп, беркетеп ясалган бу тәмле ризыктай гаиләгез, халкыгыз белән бергә яшәгез» дип, матур теләкләр дә телиләр.

PRESSA

РӘГАТЬ ХӨСӘЕНОВНЫҢ ХЫЯЛЫНДАГЫ ШӘҺӘР

Татьяна Вафина

Хикмәтле коучлар һәм данлыклы блогерлар безне һаман дөрес хыялланырга өйрәтә: галәмгә үтенечләрне төгәл юллау, күз алдына китерү, медитацияләү, азаккы нәтиҗәне бөтен нечкәлекләре белән күзаллау... Әмма барлык бу кагыйдәләрне үтәгәндә дә хыяллар тормышка ашарга бер дә ашыкмый шул. Ә менә Лениногорск районы башлыгы Рәгать Хөсәенов теләк үтәлүнең төп принцибын тапкан бугай – ул үзең өчен генә түгел, башка кешеләр өчен дә файдалы булырга тиеш. Шул вакытта инде хыял һичшиксез чынбарлыкка әйләнәчәк.

Фото: Александр Ефремов

1 НЧЕ ХЫЯЛ. ШӘҺӘР БАКЧАСЫ

– Һәрвакыт бу скверны зурайту турында хыялландым. Биредә бераз уңайсызрак, кысанрак иде, – дип сөйли Рәгать Галиәгъзам улы «Татарстан»ны туган Лениногорск каласы буйлап экскурсиягә алып чыгарга җыенганда. – Җәмәгать мәйданнарын үстерү программасы буенча былтыр без скверны ниһаять яңарттык бит, велосипед юллары ясадык, әмма аларны нигәдер җәяүлеләр дә аеруча үз итте – барысы да сыя, бәрелешкәннәре юк әле, – дип елмая башлык. – Бакчаны яңа форматта үзгәрттек, һәм ул бөтенләй яңача балкып китте. Бигрәк тә кичләрен, утлар кабынгач, шулкадәр матурая – биредән кайтып китәсе килми... Менә бу фонтан янындагы сәхнәдә һәр шимбә «Мәдәни мохит» программасы кысаларында төрле чаралар үткәрәбез: Пушкинның туган көне, Рус теле көне, Туган тел көне... Беркайчан да бәдрәф юк иде – төзеп куйдык, чөнки сәйран кылып йөрүчеләр күп, күбесе балачага белән, шунлыктан бәдрәфсез берничек тә булмый, әле анда бәбиләрнең биләвен алыштыру бүлмәләре дә ясарга ниятлибез.

Менә бу мисалда бик ачык күренә: сквер нинди булган һәм хәзер ниндигә әйләнгән. Сул якта – төзекләндерелгән бакча, уңда – искесе. Ни өчен бөтен җирен дә берьюлы яңартмадыкмы? Менә нәрсәләрнедер үзгәрттек тә, моны халыкның ничек кабул итүен күзәтәбез. Кешеләргә ошаса: «Ә хәзер нишлисез?» – дип сорыйлар. Димәк, ихтыяҗ бар – төзекләндерүне дәвам иттерәбез. Скверны соңгы тапкыр яңартудан соң 20 елдан артык вакыт үткән бит инде, шуңа аның ямьсезләнүе бер дә гаҗәп түгел. Сукмакларга түшәлгән ташны, яктырту җиһазларын алыштырырга кирәк.

– Нәрсә, матурым, салкын, туңдырманы беркем дә алмыймы? Үзеңә ашарга туры килә инде. Ярар, тиздән җылытачак – берсе дә калмас әле.

2 НЧЕ ХЫЯЛ. САЗЛЫК УРЫНЫНДА – КҮЛ

– Мин әнә теге тугыз катлы йортта яшәдем, – дип күрсәтә Рәгать Галиәгъзам улы. – Бу күл урынында ташландык сазлык иде. Иртән балконга чыгам – тирә-юньдә чүп-чар аунный. Йә кемне дә булса талыйлар – 1990 нчы елларда бусы да гадәти хәл иде. Әйләнә-тирәдәге йортларның барысында да черки үзәккә үтә, сазлыктан сасы ис тарала...

2009 елда башлык итеп билгеләнгәч, ул чакта республиканың Премьер-министры булган Рөстәм Нургали улы Миңнехановка шул зонаны төзекләндерергә ниятләвемне әйттем. Һәм бер елдан соң сазлыкны чистарттык та. Хәзер биредә су чиста, үрдәкләр йөзә. Су җылы булганга, алар кышын да китми, шәһәр халкы ашата үзләрен. Кайчандыр каланы ямьсезләп торган урын хәзер менә дигән ял зонасына әйләнде.

3 НЧЕ ХЫЯЛ. ХӘРБИ ДАН АЛЛЕЯСЫ

– Сезне Хәрби дан аллеясына чакырам. Ул Геройлар аллеясының дәвамы булып тора. Биредә, шәһәр үзәгендә, кайчандыр кешедән дә биек булып чүп үләне үскәнен хәзер инде күз алдына китерүе дә кыен. Агачлар утыртып карадык – үсмәделәр. Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгына без парад һәм хәрби бәйрәмнәр – мәсәлән, Чик сакчылары көнен үткәрү өчен урын булдырырга ниятләдек. Бирегәрәк килсәгез, бу урынны нигә Хәрби дан аллеясы дип атавыбызны аңларсыз. Чөнки ул 1812 елгы Ватан сугышы геройларына да, 1941–1945 еллардагы Ватан сугышы каһарманнарына да, Әфган һәм Чечен сугышында катнашучыларга да багышланган. Бизәү идеясе – ветераннарыбызныкы. Каһарманнар аллеясында 12 Бөек Ватан сугышы Герое һәм 3 Дан орденының тулы кавалерының бюсты куелган. Россия Герое Дамир Исламовка һәйкәл исә якын арада урнаштырылачак.

Җиңүнең 70 еллыгына без бирегә чын бронетехника китерттек. Безнең буын кебек үк, балаларыбыз-оныкларыбызның да патриот булып үсүләрен телим. Армиягә хезмәт итәргә теләп барсыннар, Ватанны саклау һәр ир-атның изге бурычы булуын аңласыннар иде.

Мин хәзер рәхәтләнеп армиягә китәр идем. Бүгенге техника, бүгенге мөмкинлекләр белән армиядә хезмәт итүе кызык. Хәер, мин яшь чакта да кызык иде үзе. Мин десант гаскәрләрендә хезмәт иттем. Казахстандагы Балхаш күленә парашют белән сикердем... Мин экстремал үзем. Әтием кебек. Ул 17 яшендә сугышка чыгып качкан. Дөрес, тотканнар, кире кайтарганнар, әмма 1942 елда ул барыбер киткән. 1943 елда үлеме турында кәгазь килгән, 1944 елда исә исән-сау үзе кайтып кергән. Менә шундый тарих.

– Җиңүнең 70 еллыгына без бирегә чын бронетехника китереп куйдык.

4 НЧЕ ХЫЯЛ. «МӘХӘББӘТ» ПАРКЫ

– Элек бирәдә – шәһәрнең күп катлы өлеше һәм хосусый сектор арасында – сазлык, ташландык сәнәгать зонасы иде... Башта барысын да чистарттык, парк ясадык. Хәзер, республиканың парклар һәм скверлар программасына кереп, аны тагын да күркәмләндерәбез. Елга үзәнен чистарттык, су җибәрәчәкбез... Проект әле тәгәлләнмәгән, әмма кешеләр хәзер үк ял итәргә килә инде. Быел ясап бетерәчәкбез. Һәм «Мәхәббәт» паркы Лениногорскиның иң матур урыннарыннан берсенә әйләнәчәк.

Янәшәдә мәчет – Кол Шәриф мәчетен хәтерләтә, бераз кечерәк кенә. Аның янында балалар өчен бәйрәмнәр, уеннар оештыралар. Җәен балалар мәчеткә лагерьга йөри, анда уйныйлар, спорт белән шөгыльләнәләр.

Чиркәү янында да балалар мәйданчыгы бар. Хәзер шунда барабыз. Алайса, минем православие динендәге хатыным аңламас: кунакларга мәчетне күрсәткәнсең, ә чиркәүне күрсәтмәгәнсең, дияр, – дип көлә Рәгать Галиәгъзам улы. – Безнең Лениногорскида 25 милләт вәкиле яши: татар, рус, чуваш, мордва һ.б.лар... Менә Дуслык паркы төзеп маташабыз – әлегә үз көчебез белән генә, аннары идеябезгә грант алырга һәм бөтен әйләнә-тирәне төзекләндерергә ниятлибез.



Гомумән, Лениногорск халкы тату яши. Православие динендәгеләрнең бәйрәме икән – аларга, мөселман бәйрәме булса – мөселманнарга кунакка барабыз. Нәүрүзгә дә бөтен кешене чакыралар. Барлык бу бәйрәмнәргә бергәләп әзерләнәбез.

Малайлар белән фотога төшкәч, Рәгать Галиәгъзам улы әйтә:
– Аларның телефонга текәлеп утырмыйча, паркта скейтта шуууы сөендерә. Минем Ерак Көнчыгыштан каникулга кайткан оныгым да бирегә килә, аңа бик ошый. Аларның шәһәрендә мондый парк юк.

5 НЧЕ ХЫЯЛ. «ЮБИЛЕЙ» ПАРКЫ

– Без бу паркны төзекләндерә башлагач, мине ничек кенә ачуланмадылар. Бирәдә бик җилле, кеше йөрмәячәк, диделәр. Күңелем төшсә дә, барыбер туктатмадым, чөнки бу да минем балачагым хатирәсе. Бер якта яшелчә бакчалары, шул исәптән минем бабамның да бакчасы, икенче ягында исә сазлык иде. 1990 нчы елларда район башлыгы бирәдә парк төзеткән. Анда шәһәрнең Чыршы бәйрәме үткәрелгән. Еллар авыр булганга, җиренә җиткереп эшләп бетермәгәннәр – чыршы, койма, таш түшәлгән юл һәм башка бернәрсә дә юк. Парклар һәм скверлар программасы ярдәмендә без сәхнә, скейт-парк өстәдек, иганәче футбол кыры ясап бирде, бәдрәфләр төзеттек... Һәм паркка халык теләп йөри башлады. Бирәдә Яңа елны каршылыйбыз, милли бәйрәмнәрне уздырабыз, артистлар рәхәтләнеп чыгыш ясый. Паркта һәрвакыт кеше бик күп була. Мин иртәнге сәгать 5–6да эшкә барганда, бирәдә инде тренажерларда шөгыльләнәләр.

– Район башлыгы ни өчен парк һәм бакчаларны шулай ярата икән?

– Мин парк зонасы төзү турында гел хыялландым. Балачакта без үзебез футбол, баскетбол мәйданчыклары төзи, велосипедта трюклар ясар өчен юллар сала, чаңгы шуарга таулар өя идек... Әтием партия заманында урам комитеты рәисе булып, без, балаларга, һәрвакыт булыша иде: дискотека өчен мәйданчык ясарга да, аңа ут кертергә дә, ирекле халык дружинасы кизүен оештырырга да. Без ул чакта бистәдә яшәдек, әмма дискотекабыз шундый яхшы була иде ки, яшьләр, киресенчә, шәһәрдән безгә килделәр. Шәһәрдә исә урман-парк зонасы һәм мәйданнан башка барыр урын юк иде.

6 НЧЫ ХЫЯЛ. УРМАН-ПАРК

– Урман-парк минем өчен бик мөһим объект. Аны торгызу намус эшем булды. Чөнки бу урман-паркка мин балачагымнан йөрим: башта әти-әнием, дусларым белән, аннары инде балалар һәм оныклар белән. СССР таркалган 90 нчы елларда, башта финанслау кайгысы калмагач, урман-парк ял итү өчен яраксызга әйләнде. Аны торгызу, әлеге проектны уңышлы башкарып чыгу минем өчен бик әһәмиятле иде. Барысы да барып чыкты! Карагыз әле, керү юлы нинди заманча, нинди матур! Безнең данлыклы ротонданы моннан дүрт ел элек яңарттык. Былтыр исә, «Татнефть» ярдәме белән, диаметры 35 метрлы бик кәттә күзәтү тәгәрмәче урнаштырдык! Урынбасарым Гөлфирә Мәҗит кызы белән иң беренче үзем сынап карадым: кондиционерлы ябык кабинкалар, искиткеч манзара – менә диган булып чыкты.

Ротондага исә җәяү генә менеп була. Мин машинада да менә алам әлбәттә, тик халыктан уңайсызланам, шуңа беркайчан да оятсызланмыйм.

7 НЧЕ ХЫЯЛ. ИҢ МӨҺИМЕ

Бүген бу бина проектын сорап башка шәһәрләрдән киләләр. Урта диңгез буеннан күчеп утыргандай бигрәк тә күркәм шул ул. Ә бит кайчандыр Лениногорскиның ЗАГС бинасы да Рәгать Хөсәеновның чираттагы хыялы булган. Сурәттәге хыял. Әлеге картина бүген дә аның кабинетында эленеп тора, ул – тормышка ашкан хыялга дәлил. Биредә җирле яшьләр генә түгел, башка шәһәрләрдән дә килеп язылышалар – ап-ак күркәм бина фонында фотосессия искиткеч матур булып чыга шул.

– Бу минем төп хыялым иде, – дип соклана үз фантазиясенең нәтиҗәсенә Рәгать Галиәгъзам улы. – Нигә нәкъ менә ЗАГСмы? Яшьләр элек кечкенә генә бер бинада язылыша иде. Яшь гаилә тормышындагы иң мөһим вакыйганың шундый урында башлануына хафаландым. Шунлыктан никахлашулары бөтен гомерләре буена хәтерләренә уелырлык затлы ЗАГС бинасы салу хакында хыялландым.

Башта, хакимияттә эшләгәндә, ЗАГСны буш кафе бинасына күчереп карадым. Әмма урыны бик уңышлы түгел иде – каршыда мәктәп, кысан. Элек ул бер генә автомобильдә килеп язылышканнар да, өйгә кайтып бәйрәм иткәннәр. Хәзер исә автомобильләр кортежы, һәр парның кунаклары, иске бинага күп кешене сыйдырып булмый. Киләчәк буыннарга да мирас булып калырлык затлы бина төзергә ниятләдек. Бу картина бинаның тышкы кыяфәтенә илһамландырды, проектка исә үз кулларым белән төзәтмәләр керттем...

– Сез рәссам җанлы кеше алайса?

– Һич юк. Бөтенләй рәсем ясый белмим. Әмма безнең Лениногорскидагы сәнгать мәктәбе бик шәп. Анда балаларны укырга керү өчен, чират торырга туры килә. Бу көннәрдә нефтьчеләр ярдәме белән мәктәпнең филиалын ачтык. Хәзер Лениногорскида рәссамнар ике тапкыр күбрәк булачак.

– Мондый гүзәллекнең сәбәбе аңлашыла алайса. Сез рәссамнар шәһәреме?

– Спортчыларныкы да. Көрәш мәктәбе бар. Нефтьчеләр бүләк иткән теннис кортында елына алты турнир буенча бөтенроссия чемпионатлары үткәрелә. Һәр атна саен һәвәскәрләр өчен өчәр турнир уза. Республика көненә Боз сараен ачачакбыз. Стадионыбыз яңа, заманча. Ә менә бусы – Олимпиадада көмеш медаль яулаган Данил Садриев сикерергә өйрәнгән трамплин. Ике трамплин ел буе эшли, өченчесен әлегә ремонтлыйбыз.

8 НЧЕ ХЫЯЛ. БОРАУЛАУЧЫЛАР СКВЕРЫ

– Лениногорскида чишмәләр күп. Краннан да чишмә суы акса да, халык суны барыбер кизләүдән алып кайта. Әле безнең күлләр каскады да бар. Менә бусы – беренчесе. Кайчандыр биредә, Камышлы бистәсендә, нефть эзләүче беренче бораулаучылар яшәгән. Әйләнә-тирәдә гел урман булган. Минем хыялым – бу урынны да җиренә җиткереп эшләп бетерү, Бораулаучылар скверы ясау. Велосипед юллары төзисе, балык тоту урыннарын җайлыйсы, суга керү юлын саласы килә...

9, 10, 11 НЧЕ ХЫЯЛЛАР... ТАШЛАНДЫК УРЫННАРНЫ РӘТКӘ КИТЕРҮ

Шәһәр буйлап сәяхәт иткәндә башлык безгә кайчандыр чүп үлән үскән ташландык урыннарның хәзер гөлбакчага әйләнүен күрсәтеп узды.

– Мондый ямьсез урыннар барыбер күп әле, – ди ул. – Әкренләп, закон буенча, мондый җирләрне гүзәллеккә әйләндерәбез. Әйе, моңа еллар кирәк булачак. Әмма бездән соң эшләүчеләр дә территорияләрне шулай төзекләндерү ысулын кулланачак – беркемгә дә комачауламыйча, салмак кына, матур итеп үзгәртәчәкләр.

– Сез ташландык урыннарны матурайту белгечеме?

– Мин генә дә түгел. Менә биредә, мәсәлән, Ипеевның фермерлык кибете. Ул ташландык ферманы аякка бастырды. Һәм хәзер шундый тәмле сыйфатлы продукция җитештерә ки, шундук сатып алып бетерәләр!

БАЛАЧАК ХЫЯЛЫ. ТОРМЫШКА АШМАГАНЫ

– Ә сез бала чакта кем булырга хыялландыгыз? Барлык совет балалары кебек космонавтмы?

– Юк. Ерак араларга йөзүче диңгезче яки еракка машина йөртүче булырга теләдем. Мине һәрвакыт ерак җирләр кызыктырды, мин гомерем буе юлда. Мин кабинет кешесе түгел.

– Димәк, балачак хыялыгыз тормышка ашмады?

– Бер генә түгел, берничә хыялым гамәлгә ашмый калды. Минем бала чагымда Самарада яшисем килә иде. Анда минем туганнарым, дусларым. Армиядән кайткач, шунда киттем. Әмма абыйларым миңа төп нигездә калырга кушты. Мин калдым инде, һәр атна саен аларга кунакка барып йөрдем. Аннары исә инде алар үзләре миңа кайта һәм минем биредә булуыма сөенә башлады. Дөньяда Лениногорскидан да шәбрәк шәһәр юк ул минем өчен!

P.S.
Лениногорскида үз башлыкларын яраталар. Урамда аны күргәч, сәламләргә, сорау бирергә, проблемалары белән уртаклашырга яки ярдәме өчен рәхмәт әйтергә ашыгалар.

Мәдинә Мингәрәй кызы Сафиуллина, Лениногорск татар халык драма театры җитәкчесе һәм режиссёры, район башлыгы эшли генә башлаган чорда аның янына килүен искә ала:

– Мин Тукай һәйкәле янында сырахәнә торуына игътибар иттем, – дип сөйли Мәдинә Мингәрәй кызы. – Һәм анда гел пычрак, чүпчар, исерекләр, һәйкәл артын бәдрәфкә әйләндергәннәр... Нинди хурлык бит! Мин аның кабинетына бәреп дигәндәй кердем һәм барысын да сөйләп бирдем. Һәм шактый тиз арада сырахәнәне аннан алдылыр, һәйкәлне тәртипкә китерделәр. Лениногорск халкы аны нәкъ менә шуның өчен хөрмәт итә дә – сүз бирдеме, һәрвакыт үти!

Ренат Мәһдиев, «Модуль» җиһаз компаниясе» ҖЧҖ генераль директоры, Лениногорск базарында 12 ел эшләү дәверендә һәрвакыт башлыкның ярдәмен тоюы хакында сөйли:

– Рәгать Галиәгъзам улы сыйфатлы продукция җитештерүче җирле эшкуарларга һәрвакыт хәерхаһ, моның өчен аңа зур рәхмәт! – ди Ренат. – Аны якынлашып килгән юбилее белән тәбрик итәсем, бәхет һәм сәламәтлек телисем килә. Иң кыю һәм гүзәл хыяллары киләчәктә дә тормышка ашсын, туган шәһәребез тагын да күркәмләнсен!

ТОРМЫШ УҢАЙЛЫ ҺӘМ РӘХӘТ БУЛСЫН ӨЧЕН

«Территорияләрне үстерү» өстенлекле юнәлеше буенча «Татнефть» грантларының беренче конкурсында Лениногорск муниципаль районының Яңа Чыршылы, Туктар Урдаласы, Мичурин авыл җирлекләре җиңү яулады. Әлеге грантлар буенча подряд эшләрен башкаруны «ТриАл» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә ышанып тапшыралар. Ул 12 елдан артык бу районның авыл җирлекләрен су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системалары белән шөгыльләнә.

Кулланучылар су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системасына һәрвакыт аерым таләпләр куя. Без суның өйләргә һәм фатирларыбызга ничек килүе турында, нигездә, уйлап та карамыйбыз – моны шулай тиеш дип кабул итәбез. Тик кранны ачкач, су акмаса, дөнья беткәндәй тоела! Шуңа күрә халыкны эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итүне күздә тоткан милли проектларны, федераль һәм республика программаларын тормышка ашыруның әһәмияте бәяләп бетергесез.

Нәкъ менә авыл җирлекләрендә социаль мөһим объектлар, торак йортлар өчен су, канализация челтәрләрен салу һәм ремонтлау «ТриАл» ширкәтенең төп эше булып тора. Ул Лениногорск шәһәрендә һәм Лениногорск районында ремонт-төзелеш һәм монтаж эшләренең тулы комплексын үзкөйләнешле оешма (СРО) рөхсәте нигезендә гарантия белән уңышлы башкара.

Күпьеллык эшчәнлек дәверендә компаниядә бай тәҗрибә тупланган. Бүген ул – яхшы механикалаштырылган заманча предприятие. Биредә үзләренең төзелеш техникасы паркыннан, җиһазлар һәм транспорт чараларыннан торган куәтле матди-техник база булдырылган. Квалификацияле коллектив белән саллы тәҗрибәсе булган профессионаллар идарә итә, алар компаниянең тотрыклы үсешен тәэмин итә.

Гамәлдәге норматив һәм техник документация таләпләренә туры килерлек итеп башкарыла торган эшләрнең сыйфаты, тупланган тәҗрибәне киң куллану предприятиегә төзелеш эшләрен һәрчак вакытында башкарырга мөмкинлек бирә. Шуңа күрә нәкъ менә «ТриАл» ширкәтенә бүген катлаулы объектларны ышанып тапшыралар да.

Лениногорскида һәм Лениногорск районында уникаль Ромашкино ятмасын үзләштерү белән бергә торак йортлар, балалар бакчалары, мәктәп һәм хастаханәләр – кешегә тормыш-көнкүрешендә кирәкле һәрнәрсә актив төзелгән. Дистәләрчә ел файдаланганнан соң алар, әлбәттә, ремонт һәм реконструкция таләп итә башлаган. Бу районның торак пунктларындагы су үткәрү челтәрләренә, су җыю резервуарларына, су кертү станцияләренә дә кагыла.

Әйтик, «ТриАл» ҖЧҖ бүген Лениногорск районының Мичурин, Туктар Урдаласы, Яңа Чыршылы кебек берничә авыл җирлегендә эшләр башкара. Предприятие эшләрне берничә объектта параллель рәвештә башкару өчен кирәкле техник мөмкинлекләргә һәм кадрлар потенциалына ия.

– Безнең бурыч Лениногорск районында яшәүче һәр кешегә тормыш итү өчен уңайлы шартлар тудыру, ә атап әйткәндә, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу буенча сыйфатлы хезмәтләр күрсәтүдән гыйбарәт, – ди предприятие директоры Альберт Кашапов. – Һәм халык нәкъ менә биредә яшәве белән горурлана алсын иде. Шуңа күрә без һәрвакыт хакимият органнары, халык, хезмәттәшләребез белән тыгыз элемтәдә эшлибез.

«ТриАл» ҖЧҖ коллективы үзенә күрсәтелгән ышаныч өчен рәхмәт белдерә һәм, форсаттан файдаланып, Лениногорск муниципаль районы башлыгы һәм Лениногорск шәһәре мэры Рәгать Галиәгъзам улы Хөсәеновны юбилее белән котлый:

– Сезнең җитәкчелектә шәһәребез һәм районыбыз нефть сәнәгате төбәге генә түгел, ә тормыш өчен уңайлы, заманча һәм матур урын буларак та актив үсә. Шуңа күрә сез аның халкында зур хөрмәт һәм абруй казандыгыз.

Лениногорскилылар мәнфәгатенә кагылышлы бар мәсьәләдә дә предприятиебез Сезнең тарафтан һәрвакыт аңлау һәм ярдәм таба.

Сезгә нык сәламәтлек, күңел күтәренкелеге, кызыклы проектлар, шәһәребез һәм районыбызны гөрләтеп үстерүдә иксез-чиксез энергия, дәрт-дәрман телибез. Т

Фото «ТриАл» компаниясе тарафыннан бирелде. РЕКЛАМА

«ФЕНИКС»: ӨЛГЕРЛЕК, ЫШАНЫЧЛЫЛЫК, СЫЙФАТ

Нефть чыгару – республикабыз бюджетының нигезен тәшкил итә торган төп тармак. Кара алтынны уңышлы чыгару өчен исә махсуслаштырылган техника кирәк. Тармакның туктаусыз эшләвен тәэмин итүчеләр арасында Лениногорскиның «Феникс» компаниясе дә бар.

– Без инде ун елга якын нефть чыгару җиһазларын җитештерү һәм ремонтлау белән шөгыльләнәбез, нефть сервисы тармагында югары технологияле техника тәкъдим итәбез, – дип сөйли предприятие директоры Юрий Соловьев. – Тиз, төгәл эшлибез, белгечләребез проблеманы тиз арада ачыклау һәм аны хәл итү юлларын табуга сәләтле. Нәкъ менә шуңа күрә «Феникс» көндәшлеккә сәләтле һәм уңышлы, дип уйлыйм, нәкъ шуңа заказлардан өзелгәнебез юк. Безнең хезмәт күрсәтү базары шактый зур. Билгеле инде, иң әүвәл Татарстан («Татнефть», кече нефть компанияләре), шулай ук Башкортостан, Самара һәм башка төбәкләр. Чит илләрдән дә заказлар алганыбыз бар.

ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮНЕҢ ТУЛЫ ЦИКЛЫ

Компаниянең металл эшкәртү өчен үз җиһаз паркы бар: кыру-фрезер, электроэрозион кисү станоклары. Сафтан чыккан бораулау һәм нефть чыгару җиһазларын үзләренең ремонт базасында тиз арада аякка бастыралар. Барлык цехларда да – сынау, кыру, слесарьлык – тулы тәртип, «Феникс» бөтен техник һәм аудиторлык тикшерүләрен уңышлы үтә, нәкъ менә шуңа да аңа мөһим заказларны ышанып тапшыралар.

Компания заказчы сызымнары буенча да җиһазлар җитештерә, үзенең конструкторлык-технологик базасы да бар, ягъни җиһазларны үз эшкәртмәләре, үз сызымнары буенча да ясый. Аннары үз техникасын нефть чыгару объектларында, скважиналарда үзе урнаштыра да. Барысы да квалификацияле белгечләр контролендә эшләнә.

ЗАКАЗЧЫ БЕЛӘН ТЫГЫЗ ЭЛЕМТӘДӘ

Компаниянең төп принциплары: өлгерлек, хәрәкәтчәнлек, кулай бәяләр, заказны югары сыйфатлы башкару. Һәм «Феникс» шулардан һич тайпылмый. Басым ясап әйтәсе килә: теге яки бу мәсьәләне хәл иткәндә җитезлек – нефть җиһазларына хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлауда махсуслашкан компания өчен бик кирәкле сыйфат ул.

«Феникс» командасы заказчы белән тыгыз элемтәдә эшли, бурычны тиз арада үти ала. Сүз дә юк, биредә компания хезмәткәрләренең казанышы зур – аларның һәркайсы үз урынында. Цехларда, станокларда зур тәҗрибәле осталар хезмәт куя, инженер-техник персонал нигездә яшь – аларның фикерләве заманча, иҗат итү теләге исә гаять зур.

«Феникс» бер урында таптанмый – хезмәт күрсәтү сыйфатын тагын да яхшыртырга тырыша, технологияләрне үстерә һәм камилләштерә. Компания заказчы белән тыгыз аралашуга һәрвакыт әзер, аның өстенлеге дә шунда.

Лениногорскиның «Феникс» компаниясе үз шәһәрләренең мэры Рәгать Хөсәеновны юбилее белән ихластан тәбрик итә.

Хөрмәтле Рәгать Галиәгъзамович!

Лениногорск районы һәм аның халкының тормышын яхшырту буенча көндәлек хезмәтегез өчен Сезгә рәхмәтебезне җиткерәбез.

Белем, искиткеч оештыру сәләте, лаеклы нәтиҗәгә ирешү өчен тырыш хезмәт – Сездә талантлы җитәкчегә хас бөтен сыйфатлар да бар. Сез көчле, ышанычлы, үз-үзегезгә таләпчән кеше – төбәкне нәкъ менә шундый шәхес җитәкләргә тиеш тә инде!

Сезгә ихлас күңелдән нык сәламәтлек, иксез-чиксез бәхет, яхшы кәеф һәм кызыклы эшләр телибез! Билгеләнгән бурычларны хәл итү өчен энергиягез беркайчан да сүнмәсен-сүрелмәсен, гел ташып торсын!

Фото «Феникс» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

УҖЫМНАН КЕРКӘ БАЛЫГЫНА КАДӘР– БӨТЕН НӘРСӘ ҮСӘ!

Авыл хуҗалыгы – Лениногорск районында аеруча игътибар бирелә торган тармак. Район халкы терлекчелек фермалары, яшелчә, гөмбә, балык җитештерү һәм башкалар буенча уңышлы эшли торган предприятиеләр белән рәхәтләнеп горурлана ала!

— Аграр сектор ит-сөт терлекчелеге, дуңгызчылык, кошчылык һәм сарыкчылыкка юнәлтелгән, – дип сөйли **районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Илнур Шәмәрдәнов.** – Лениногорск кырларында сабан бодае, уҗым арышы, арпа, солы, карабодай, борчак, рапс, көнбагыш игелә. Өстәвенә, бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культураларның үз районыбыз өчен махсуслаштырылган орлыклары файдаланыла, чөнки 2020–2021 елларда биредә югары технологияле заманча ике завод – орлык чистарту һәм ашлык киптерү заводлары төзелде. Алар орлыкны тулысынча чистарту, калибровкалау, чәчү алдыннан саклагыч препаратлар белән эшкәртү комплексы белән җиһазландырылган. Машиналарның җитештерүчәнлеге – уртача сәгатенә 15 тонна.

Гомумән, район аграрийлары һәрнәрсәдә лидер булуга омтыла – мәсәлән, 2017 елда фермер Валерий Ипеев Зәй-Каратай авылында республикада беренче булып мөгезле эре терлек өчен модульле сугым цехын эшләтеп җибәргән, ул зур хуҗалыкларга да, хосусый секторга да хезмәт күрсәтә.

Нефтьчеләрдән калган элеккеге теплица хуҗалыгы базасында заманча яшелчә үстерү комплексы пәйда булган. 2021 елда барлыгы 41 миллион сумлык 3915 центнер кыяр һәм томат җитештереп сатылган. Бүген хуҗалык районның яңа өлгергән яшелчә һәм яшел тәмләткеч үләннәргә булган ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерә.

2020 елдан районда «Август-Агро» ИК» ҖЧҖ төп инвестор булып тора. Җитештерү куәтен арттыруга ул 1,6 миллиард сум акча керткән: Кәркәле икмәк кабул итү предприятиесендә куәте сәгатенә 50 тонна булган яңа ашлык киптерү комплексы эшләтеп җибәрелгән, комбиазык җитештерү заводы техник яктан тулысынча модернизацияләнгән, машина-трактор паркы

Фотолар Лениногорск районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсеннән алынды

САННАР ҺӘМ ФАКТЛАР

– БЫЕЛ ЧӘЧҮЛЕК МӘЙДАННАР **62 МЕҢ ГЕКТАР** ТӘШКИЛ ИТӘ.
– СӨТНЕ ТУЛАЕМ ҖИТЕШТЕРҮ **5312 ТОННАГА,** АНЫҢ ТОВАРЛЫЛЫГЫ **91%КА** ТӘҢГӘЛ; **1815 ТОННА** ТЕРЛЕК ҺӘМ КОШ ИТЕ, **26,7 МИЛЛИОН ДАНӘ** ЙОМЫРКА ҖИТЕШТЕРЕЛГӘН.
– ГЫЙНВАРДАН МАЙГА КАДӘР **480 МИЛЛИОН СУМЛЫК** ТЕРЛЕКЧЕЛЕК ПРОДУКЦИЯСЕ ҖИТЕШТЕРЕЛГӘН.

Илнур Шәмәрдәнов, Лениногорск районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы.

яңартылган, ике эремә пункты төзелгән. Хәзер сөт комплексы төзү тәгәлләнгән һәм 73 миллион сумга күп сөт бирә торган 400 баш нәселле тана сатып алынган. Объект июльдә тулысынча эшләнеп бетәчәк. Шулай ук 5 мең тонна ашлык сыйдырышлы ике амбар төзелеп ята.

Татпотребсоюз ярдәмендә районда «Шөгер райпосы» кулланучылар җәмгыяте оештырылган, ул бүген уңышлы үсештә. Кооперативның ит эшкәртү цехы бар, иттән ярымфабрикатлар җитештерәләр. Районның халык аз яши торган урыннарына барып күчмә сәүдә итү оештырыла.

АШЛЫК КЫНА ТҮГЕЛ

Районда фермер хуҗалыклары да бар. Ике фермер – Самат Нәбиуллин һәм Радик Маметов – атчылык белән шөгыльләнә, татар токымлы атлар үрчетә. Әлеге токым 2019 елда «Алтын көз» Бөтенроссия күргәзмәсендә (Мәскәү шәһәре) I дәрәҗәле дипломга һәм алтын медальгә лаек булган. Руслан Ефремов керкә балыклары үрчетә. Павел Макаров һәм Юрий Илюхин гөмбә үстерү белән шөгыльләнә.

Зәй-Каратай авылында Алексей Камашевның бакча хуҗалыгында 3 гектарда кура җиләге, 1 гектарда җир җиләге үстерелә. Бакчачы киләчәктә мәйданны 12 гектарга җиткерергә һәм җиләк эшкәртү цехы ачарга ниятли.

ҖИҢЕЛҮЧЕЛӘРСЕЗ ЯРЫШ

Һичшиксез, авыл хуҗалыгы инфраструктурасы үсешенә район башлыгы Рәгать Хөсәенов зур өлеш кертә. Һәм эш аның административ ресурсларында гына түгел, бәлки кешеләргә мөнәсәбәтендә дә. Рәгать Галиәгъзам улы үз якташларын бик шәп белә, авыл халкы белән гражданнар җыеннарында гына түгел, хуҗалык кырларында да очраша, «Урак өсте» комбайнчылар ярышының төп илһамчысы һәм оештыручысы булып тора. Әлеге ярыш ел саен урак өстендә үткәрелә. Атна саен иң яхшы күрсәткечләргә ирешүчегә район башлыгы кырда шәхсән үзе акчалата премия һәм «Урак өсте»нең иң яхшы комбайнчысы» күчмә әләмен тапшыра.

Ел саен Сабан туе, авыл хуҗалыгы алдынгылары җыены да районның финанс ярдәме белән үткәрелә, анда кыр һәм ферма хезмәтчәннәре рәхәтләнеп ял итә, бүләкләнә. Җирле бюджеттан бүленгән акча хисабына районда ел саен сыерларны машина белән саву операторлары һәм көтү яңарту технологларының ярышлары да уздырыла.

СҮЗДӘ ТҮГЕЛ, ЭШТӘ ЯРДӘМ КҮРСӘТЕЛӘ

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дә зур игътибар бирелә. Шәхси хуҗалыклар 2 мең башка якын терлек, 600 берәмлек авыл хуҗалыгы техникасы сатып алган, 230 терлекчелек бинасы төзелгән һәм реконструкцияләнгән. Яшьләр авыл җирлегендә торак төзү һәм яхшырту дәүләт программасыннан актив файдалана. Программа гамәлгә кертелгәннән бирле 137 яшь гаилә барлыгы 115 миллион сумга торак шартларын яхшырткан.

Авыл халкының матди хәлен яхшы белгән Рәгать Галиәгъзам улы практик ярдәм күрсәтергә омтыла. Ярдәмче хуҗалыгында дүрт һәм аннан да артыграк мөгезле эре терлек булган 70 кешегә саву аппаратлары алуга 1,2 миллион сум акча бүленгән, авыл халкына тагын 700 мең сумлык 29 саву аппараты алып бирелгән.

«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» президент программасы кысаларында авыллар актив төзекләндерелә. Лениногорск районында мәдәният йортлары капиталь ремонтлана, фельдшер-акушерлык пунктлары, балалар мәйданчыклары һәм авыл халкына кирәкле башка объектлар төзелә.

Лениногорск муниципаль районы агросәнәгать комплексы коллективы Рәгать Хөсәеновны 60 яшьлек юбилее белән тәбрик итә!

Хөрмәтле Рәгать Галиәгъзамович!

Сез озак еллар буе районыбыз белән уңышлы җитәкчелек итәсез, авылда кумәк һәм шәхси эшкуарлыкны максатчан үстерәсез. Гади хезмәтчәннәргә сүз белән түгел, эш белән ярдәм итәсез. Хезмәтегез өчен безнең аграрийлардан зур рәхмәт Сезгә!

Юбилеегыз уңаеннан Сезгә сәламәтлек, бәхет, муллык, уңышлар телибез! Барлык уй-хыялларыгыз тормышка ашсын! Үзегезгә һәм якыннарыгызга иминлек һәм җан тынычлыгы телибез!

СЕЗНЕҢ ИМИНЛЕКНЕ «СТРАЖ» КАЙГЫРТА

Лениногорск шәхси сак предприятиеләренең берсе булган «Страж» күптәннән татарстанлыларның хөрмәтен казанды. «Безнең турында бүләкләребез сөйли», – дип билгеләп үтте аның директоры Мансур Гыйльморадов. Һәм, чыннан да, компания офисында диплом, грамоталар һәм рәхмәт хатлары белән тулы дивар сүзсез дә бик күпне әйтеп бирә.

Мансур Гыйльморадов, «Страж» шәхси сак предприятиесе директоры, Лениногорск сак этләрен үрчетү клубы җитәкчесе

30 ЕЛ САК ЭШЕНДӘ

«Страж» – төрле объектларны каравылда торып һәм хәвеф пульты системасы аша ышанычлы саклау, видеокүзәтү системалары, хәвеф сигналы төймәләре, шлагбаумнар кебек сак чараларын монтажлау һәм аларга профессиональ техник хезмәт күрсәтү; куркынычсызлык мәсьәләләре буенча киңәшләр бирү һәм кешеләрнең иминлеген, мал-мөлкәтен сакларга ярдәм итә торган башка хезмәтләр күрсәтү дигән сүз ул. Һәм бу эш өч дистә ел дәвамында башкарыла!

Сүз уңаеннан, хәзер бу өлкәдә заманча техник чаралар бик киң кулланылуга карамастан, «Страж» ышанычлы ярдәмче – сак этләреннән баш тартмаган. Шәхси сак предприятиесе 1991 елдан бирле сак эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган эт үрчетү клубының эшен дәвам итә. Мансур Гыйльморадов хәзер дә Лениногорск клубының җитәкчесе булып тора. Яхшы өйрәтелгән сак этләре – «Страж»ның көндәшләрдән тагын бер өстенлеге. «Страж»га ышанып тапшырылган объектка, халык теле белән әйткәндә, чебен дә үтеп керә алмаячак, кагыйдә бозучылар турында әйтсәң дә юк, аларны шундук сизеп алып зарарсызландырачаклар.

ЫШАНЫЧЛЫ САКЧЫ

Республикада, һичшиксез, предприятиенең җәмәгать тәртибен саклауга керткән өлешен лаеклы бәялиләр. «Закон территориясе» конкурсында призлы урыннар, «Татарстанның иң яхшы шәхси сак предприятиесе» номинациясендә бүләкләр һәм башкалар моны ачык дәлилли.

«Страж»га иң җаваплы, мәсәлән, нефть чыгару белән бәйле объектларны саклауны ышанып тапшыралар, хәзерге көндә берничә мәктәп, балалар бакчасы һәм башка социаль учреждениеләр бу предприятиенең ышанычлы сагында тора. Үз вакытында нәкъ менә «Страж» шәһәрне полиция пультына тоташтырылган видеокүзәтү системасы белән тәэмин итә.

Предприятие төрле бәйрәм чаралары вакытында җәмәгать тәртибен саклауда Лениногорскига һәр ел түләүсез ярдәм күрсәтә. Шәхси сак оешмасы хезмәткәрләре Яңа ел бәйрәмнәрендә, Шәһәр көне, Белем көне, Җиңү көнендә һәм башка бәйрәмнәр вакытында кизүдә тора. «Страж» балалар савыктыру лагерьларын саклауга да җәлеп ителә, сайлауларның тәртипле узуын тәэмин итүдә дә булыша.

Әлбәттә, предприятие эчке эшләр органнары һәм Лениногорск хакимияте белән тыгыз элемтәдә тора.

ЧЫН ПРОФЕССИОНАЛЛАР

Теләсә кайсы компаниянең уңышы күп очракта кадрларга бәйле. Бу җәһәттән «Страж»да бар да тәртиптә – барлык хезмәткәрләр дә тиешле лицензиягә ия, теләсә нинди катлаулы бурычны үтәргә сәләтле, тәҗрибәле ышанычлы. Эше көйле бара торган, сыналган коллектив – сак предприятиесенең горурлыгы!

«Страж» шәхси сак предприятиесе, үзенең гаять катлаулы хезмәтен тормышка ашырганда, Лениногорск мэры Рәгать Хөсәеновның ярдәмен һәрдаим тоя. Форсаттан файдаланып, сак предприятиесе коллективы район башлыгын якынлашып килүче 60 яшьлек юбилее белән котлый!

Хөрмәтле Рәгать Галиәгъзамович!

Сезгә чын күңелдән саламәтлек, уңышлар һәм бетмәс-төкәнмәс энергия телибез! Сез максатчанлыгы һәм һөнәри осталыгы тирән ихтирам уята торган җитәкчеләрдән берсе. Сез – һичбер кыенлыкка карамыйча, эшкә алына һәм аны башкарып чыга торган көчле ихтыярлы кешеләрдән. Сезнең кул астында Лениногорск шәһәре һәм районы яхшы якка үзгәрде, үз эшегез өчен чын күңелдән тырышасыз, аңа бөтен көчегезне саласыз. Бүген Сез гомер юлының иң уңышлы этабында торасыз, бу чорда тормышны белү-аңлау бай тәҗрибә белән кушыла, күп нәрсә эшләнгән була, тик алда әле яңа планнар көтә. Үзегезгә һәм якыннарыгызга бәхет һәм саламәтлек телибез!

Фото «Страж» шәхси сак предприятиесе тарафыннан бирелде. РЕКЛАМА

«ТЕХСПЕЦСЕРВИС»: БЕЗГӘ ЫШАНАЛАР

Куркыныч җитештерү объектлары һәрвакыт күз-колак булып торуны таләп итә – һәрнәрсәнең сәгать кебек эшләве мөһим. Әгәр кайсы да булса җиһаз сафтан чыкса, аны мөмкин кадәр тизрәк төзәтергә кирәк. Бу вакытта Лениногорскиның «ТехСпецСервис» ширкәте ярдәмгә килә.

Ралиф Ибраһимов,
«ТехСпецСервис» ЖЧҖ директоры

Компания Клинцы һәм Галич автокран заводларының, Чиләбе механика заводының, «Автокран» АҖ, «ИНМАН» ЯАҖ һәм PALFINGER ширкәтенең рәсми сервис үзәге булып тора. Машина төзелеше тармагындагы алдынгы предприятиеләр буларак, алар Лениногорск белгечләренә үз җиһазларын тулысынча ышанып тапшыра.

– Инде күп еллар безнең компания Ростехнадзор күзәтчелегендәге куркыныч җитештерү объектларын: йөк күтәрү механизмнарын, бораулау җиһазларын һәм нефть чыгару өчен махсус техниканы, башка шундыйларны тикшерү һәм төзәтү белән шөгыльләнә, – дип сөйли «ТехСпецСервис» директоры Ралиф Ибраһимов. – Без Татарстанның көньяк-көнчыгышында торба салу краннары, суырткыч станоклар, эксплуатацияләү һәм басым арттыру скважиналарының авыз өлешендәге арматура, каротаж күтәрткечләр һәм станцияләр кебек техник җайланмаларга экспертиза уздыру эшенә беренчеләрдән булып керешкән эксперт оешмалары исемлегендә.

Компаниянең 2017 елда оештырылган инженерлык үзәге Ростехнадзор лицензиясенә ия, аның шулай ук нефть һәм газ сәнәгате, пар казаннары һәм аларга бәйле җиһазларга, күтәртү корылмаларына күзәтчелек итү һ.б өлкәләрдә аттестацияләнгән белгечләре бар.

ЭШ ҺӘРВАКЫТ БАР!

Компания участокларында: ремонт һәм куркынычсызлык приборларына сервис хезмәте күрсәтү лабораториясендә, ремонт цехында, җимерүсез тикшерү алымнары лабораториясендә, тикшерүчеләр төркемендә, документлар әзерләү төркемендә 40 кеше эшли. Алар барысы да – ышанычлы, эштә сыналган, тәҗрибәле, һөнәри сизгерлеккә ия хезмәткәрләр. Ышанычлы коллектив – предприятие уңышларының нигезе ул.

Гидравликаны, нефть-газ чыгару җиһазларын (төрле савытлар, мичләр һ.б.) ремонтлау булсынмы, җибәрү-көйләү эшләре яки экспертиза булсынмы – Лениногорск белгечләре кайсына гына тотынмасын, барысын да оператив һәм сыйфатлы итеп эшләячәк. Нәкъ менә шуңа күрә «ТехСпецСервис» заказсыз тормый. Эш һәрвакыт бар, ә хәзерге шартларда бу – бик яхшы күрсәткеч!

БАРЫСЫ ДА БИК ҖИТДИ

Компания техник яктан яхшы җиһазландырылган, чөнки ул җитди заказ бирүчеләрнең саллы заказларын үти. Ширкәтнең үз җитештерү базасы бар: ул капиталь административ бинадан, гараж һәм склад мәйданнарыннан, станоклар белән җиһазланган ремонт остаханәсе, ремонт-җитештерү бокслары һәм башкалардан гыйбарәт. Предприятиенең барлык төр хезмәтләргә дә Ростехнадзордан алынган тиешле рөхсәт документлары бар.

«ТехСпецСервис» компаниясе Лениногорск районы башлыгы Рәгать Хөсәеновны якынлашып килгән юбилее белән котлый!

Хөрмәтле Рәгать Галиәгъзамович!

Принципиальлек, максатчанлык, профессиональлек, кешеләр белән эшли белү бәрабәренә Сез район халкының хөрмәтен яуладыгыз. Сез һәрвакыт җиңүгә омтыласыз, һәр тарафы үлчәнгән һәм зирәк карарлар кабул итәсез, лениногорскилыларның гозерләренә колак саласыз – җитәкче таланты әнә шунда инде ул.

Эшкә сәләтлелегегез һәм эшлекле сыйфатларыгыз алга таба да Сезгә уй-ниятләрегезне тормышка ашыруда ярдәм итсен.

Сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, бәхет, бетмәс-төкәнмәс оптимизм, уңышлар телибез! Һәр көнегез якыннарыгызның җылысына һәм мәхәббәтенә төренсен!

Фото «ТехСпецСервис» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

MODUL STYLE

8 (800) 70-14-07
sales@modul16.ru modul16.ru

«МОДУЛЬ» ЙОРТ ҖИҺАЗЛАРЫ КОМПАНИЯСЕ»
ЛЕНИНОГОРСК Ш.



«Modul style» – Татарстан Республикасындагы җитештерү компаниясе, ул 12 елдан артык металл каркаста сыйфатлы йорт җиһазлары ясый.

- **УРЫНДЫКЛАР, ӨСТӘЛЛӘР, ЯРЫМКӘНӘФИЛӘР ҺӘМ ЛОФТ СТИЛЕНДӘГЕ ҖИҺАЗЛАР**
- **АШ-СУ БҮЛМӘСЕ ӨЧЕН ҖИҺАЗЛАР**

Без йорт җиһазларының күптөрле юнәлешләрен, шул исәптән **CHESTER*O ДИЗАЙНЕР УРЫНДЫКЛАРЫН ҺӘМ КӘНӘФИЛӘРЕН** тәкъдим итәбез

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР /

Бу санда тәкъдим итәбез:

Иске Таш мәчете **КЕМНӘРНЕ** хәтерли

Болгар ханы **НӘРСӘГӘ** Багдад хәлифәсеннән акча сораган

Иске Ибрайда халык **НИЧЕК ЯШИ**

«Татарстан» журналы **НИЧЕК** Истанбулны яулады

ИСЛАМ ЯДКӘРЛӘРЕ

КАЗАНДАГЫ «ИСКЕ ТАШ» МӘЧЕТЕ

«Иске Таш» манарасыннан беренче азан 1802 елда яңгырый. Беренче гильдия сәүдәгәр Габдулла Үтәмешевнең иганә акчаларына салынган мәчет тарихи урында пәйда була.

Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы
922
2022

Риваятьләр буенча, бу урында 1552 елда Казанны яклап шәһит киткән яугирләр күмелгән. Туганнар каберлеге урынында зур иске таш куелган була, мәчет үз исемен әнә шуннан ала. Өлкәннәр сүзенә караганда, әлеге таш мәчетнең көнчыгыш фасады каршында әле бик озак вакытлар торган. Башка версия дә бар: «Иске Таш» гыйбадәтханәсен төзегәндә җимерелгән мәчетләрнең ташлары кулланылган. Мәчет үзе төрле елларда төрлечә – «Иске Таш», «Зур Таш», «Тугызынчы Җәмигъ мәчете» дип аталып йөри.

БУ ДИВАРЛАР КУРСАВИ ҺӘМ ӘМИРХАННЫ ХӘТЕРЛИ

«Иске Таш» мәчете белән шактый күп күренекле шәхесләрнең исемнәре бәйләнгән. Төзелеш вакытында Мәккәгә юнәлеш – кыйбланы татар дини ислахчылыгына нигез салучы Габденнасыйр Курсави билгели. 1853–1921 елларда язучы Фатих Әмирханның этисе педагог-новатор һәм мәгърифәтче Мөхәммәтзариф Әмирхан мәчеттә имам булып тора.

Сүз уңаеннан, Әмирханнар династиясе вәкилләре биредә мәчеткә нигез салынганнан бирле диярлек эшли. Алар арасында күренекле дин белгече һәм тарихчы Хөсәен Әмирхан бар, ул 1847–1889 елларда мәчеттә мулла була. Ә 1893–1932 елларда шагыйрь, тарихчы һәм дин белгече Мөхәммәтсадыйк Иманколый (1932 елда репрессияләнә) мулла булып эшли.

БОЛГАР ҺӘМ КАСЫЙМ МАНАРАЛАРЫ ӨСЛҮБЕНДӘ

«Иске Таш» мәчетенең төз манарасы түбә уртасыннан калкып чыккан кебек тоела. Гыйбадәтханәнең фасадлары кебек үк барлык

Фото: islam-today.ru, Александр Ефремов

элементлары да классицизм өслүбенә ярашлы рәвештә ясалган. Ләкин дүрт катлы манара формалары белән Болгар һәм Касыйм шәһәрләрендәге мәчет манараларын – әлеге эстетик юнәлеш оешканчы салынган корылмаларны хәтерләтә. Бинаның конструкциясе дә кызыклы. Ике намаз залы бер-берсеннән ике метрга якын калынлыктагы дивар белән аерылып тора. Асылда бу дивар манараның нигезе. Монда ук, диварда, манарага алып менә торган тар баскыч ясалган.

Намаз заллары икенче катта урнашкан. Калын, авыр әвернәсыман гөмбәз белән капланган беренче кат хуҗалык эшләре өчен кулланылган. Гөмбәзләрнең берсе уртада зур шакмак баганага таяна – безнең көннәргә кадәр беренчел халәтендә сакланып калган мондый түбә конструкциясе XVIII гасырга хас. Манара, күрәсең, 1830 нчы елларда – мәчетнең архитекторы Александр Шмидт проекты буенча реконструкцияләнгән вакытында салынгандыр.

БЕР ГАСЫР ОНЫТЫЛЫП ТОРГАННАН СОҢ

«Иске Таш» мәхәлләсе шәһәрдә иң зурлардан була, аның мәдрәсәсендә 80 шәкерт сабак ала. Мәчет Яңа Татар бистәсенең җәмәгать үзәге санала. Барысы да 1939 елның 22 апрелендә Татреспублика хакимияте карары белән мәчет ябылгач бетә. Советлар чорында ул – мәктәп, соңрак склад итеп кулланыла...

1994 елда мәчет дин тотучыларга кайтарыла. Корылма федераль әһәмияттәге тарихи һәйкәл булып тора. Бер ел элек мәчеттә реставрация эшләре башланган. Әлеге эшләргә 200 млн сум акча партия проекты буенча бүленгән. Яңарту эшләре нәтиҗәсендә мәчетнең иң беренче – XIX гасыр башындагы кыяфәте торгызылачак. Бөтен «артык» элементлар – купчелеге совет чорында пәйда булган бүлем, түбә, ишекләр булмаячак.

Үз чиратында ике гасыр эчендә җуелган детальләр, элементлар яңадан кайтарылачак. Барысы да тарихи яктан дөрес булсын өчен реставраторлар архив материалларын өйрәнгән. Мәсәлән, «Иске Таш» мәчете төзелгән чорында ике гөмбәзле булган – реконструкциядән соң да шундый булырга тиеш.

Яңарту-төзекләндерү эшләре киләсе елда тәмамланыр, дип көтелә.

P.S. Кайбер тикшеренүчеләр «Иске Таш» мәчете Яңа Татар бистәсендәге икенче агач мәчетне (Мехчылар урамында, 7 йорт урынында булган) алыштырган дип тә саный. Ул Казанның архитектор Василий Кафтырев тарафыннан 1782 елгы (Пугачев күтәрелешеннән соң ясалган) планында бар. «Иске Таш» мәчетен таштан салганнан соң, агачтан төзелгәне күпмедер вакыт әле кулланышта була, ләкин 1830 нчы еллардан башлап, ул инде шәһәр картасында күренми башлый.

Адрес: Казан, Мәҗит Гафури ур., 34А.

1994 елда мәчет дин тотучыларга кайтарыла. Корылма федераль әһәмияттәге тарихи һәйкәл булып тора.



БАГДАД ОСТАЛАРЫ – БИЛӘРДӘ

922
2022
Идел буе Болгар дәүләтендә
Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы

Фаяз Хуҗин

922 елның 21 маенда Болгар илендә ислам динен рәсмиләштергәннән соң Болгар патшасы Җәгъфәр ибне Абдаллаһның (Алмышның) Багдад хәлифәсенә язылган һәм хәлифә тарафыннан ярдәм итәргә вәгъдә бирелгән тагын бер бик мөһим мәсьәләне хәл итәсе кала. Ул да булса, Болгар илен яһүдиләрдән, ягъни Хәзәр патшасыннан саклау өчен хәрби ныгытма – крепость һәм мәчет төзү белән бәйле эшләр.

Билгеле булганча, бу вакытта болгарлар Хәзәр каһанлыгының вассалы булып тора. Җәгъфәр ибне Абдаллаһның улы Итилдә тоткынлыкта газап чигә, сөекле кызын җария итеп хәрәмдәге хатыннар янына алып китмәкчеләр. Шуңа күрә Болгар патшасының хәзәрләрдән бәйсезлеккә омтылуын аңларга була.

Крепость төзү мәсьәләсен Багдад илчеләре белән очрашуда Болгар ханы үзе күтәрә. Эш шунда ки, Багдад хәлифәсе үзенең хатында Болгар илендә ныгытылган кала төзү өчен дүрт мең динар акча вәгъдә иткән була. Илчелек әгъзаларына кагылмаган төрле сәбәпләр аркасында бу акча Болгарга килеп җитми. Җәгъфәр хан Ибне Фадланның аклануларын тыңларга да теләми. Ахыр чиктә Багдад илчесе Болгар патшасыннан: «Синең дәүләтең бик зур, акчаларың күп, керемең күпсанлы, ә син ни өчен хәлифәдән киләчәк аз гына акчага ныгытма төзеп бирсен дип үтендең?» – дип сорый. Җәгъфәр ибне Абдаллаһның җавабы бик төпле: «Ул акча дини кануннар тарафыннан рөхсәт ителгән чыганаклардан алына дип санадым. Һәм чыннан да, әгәр дә мин үземнең акчага, көмеш яки алтынга ныгытма төзергә теләгән булсам, минем өчен бернинди авырлык булмас иде».

Һәм Болгар ханы Җәгъфәр ибне Абдаллаһ, үзенә буйсынган кабилә башлыклары һәм төзү

Ф. Халиков рәсеме

эшенә яраклы ир-атлар белән Җаушыр (хәзерге – Кече Чирмешән елгасы) дип аталган елга янына кузгалып китә. Бирелә ул ике ай чамасы була. 922 елның җәендә әлеге елга янында нинди вакыйга булган соң? Бу турыда Ибне Фадлан язмаларында бер сүз дә әйтелмәгән (хәер, ул язмалар безгә тулысы белән килеп тә җитмәгән). Галимнәр фикеренчә, Җаушыр елгасы буенда Җәгъфәр ибне Абдаллаһ белән килгән болгар төзүчеләре Биләр каласына нигез сала. Багдад илчелеге составында, дин белгечләреннән кала, хәрби ныгытмалар, шәһәр-крепостьлар төзү буенча тәҗрибәле осталар була. Эшне хәрби ныгытмалар һәм булачак шәһәр үзәгендә мәчет төзүдән башлыйлар.

Биләрнең планына күз салыйк. Ул берберсенә кереп утырган ике өлештән – берүк вакыт аралыгында барлыкка килгән эчке һәм тышкы шәһәрләрдән тора. Урыны-урыны белән икешәр рәтле калын диварлар – туфрак өеп ясалган биек үрләр, шул үрләргә куелган агач буралар һәм башнялар белән ныгытылган эчке шәһәрнең мәйданы 130 гектар чамасы. Өч рәт дивар белән уратып алынган тышкы шәһәр исә 490 гектар җирне биләп тора. Крепость диварларының гомуми озынлыгы 40 километр чамасы. Шунысы кызык: Биләр үзенең планировкасы белән урта гасырлар Багдадына охшаган. Багдад та хәлифә резиденциясе урнашкан эчке һәм сәүдә-һөнәрчелек бистәләрен берләштергән тышкы шәһәрдән гыйбарәт булган. Күрәсең, Биләргә нигез салуда катнашкан Багдад белгечләре, интуитив рәвештә булса да, үзләренең шәһәр образын күз алдында тоткан.

1970 нче елларда Казан археологлары Биләрнең эчке шәһәре үзәгендә зур гына мәчет хәрабәләрен казып чыгарды һәм аның салыну вакытын билгеләде. Бик ачык күренеп тора: X гасырның беренче яртысында ул ике өлештән торган. Борынгысы, 1400 квадрат метр мәйданда агач бүрәнәләрдән салынган өлеше, IX гасырда ук корылган. 922 елда аның ак таштан салынган өлешен торгызганнар булса кирәк. Ул 1076 квадрат метр мәйдан били. Таш мәчетнең эчендә алты рәт колонна төзелгән (һәр рәттә дүртәр колонна). Көньяк-көнчыгыш дивары ярымколонналар – пилястрлар белән ныгытылган.

Безнең уйлавыбызча, мәчетнең агач бүрәнәләрдән салынган өлеше чыннан да борынгырактыр – аның төньяк-көнбатыш стенасы мәчетнең таш бинасын салганда берәз җимертелгән. Аннан соң, Багдад осталары агач бина салу белән мәшәкатьләнеп тә тормас иде. IX гасыр ахырларында төзелгән мәчет 922 елдан соң мәдрәсә ролен үтәмәгән микән? Әлеге мәчет турында Мәскәү археологы Э. Зиливинскаяның фикерләрен дә искә алып үтәргә кирәк. Ул, таш мәчет төзелгәннән соң аның искесен (агач мәчетне) бөтенләй җимереп ташлаганнар, ә аның урынында зур гына шәһәр мәйданы барлыкка килгән, дип раслый. Хәзерге дин әһелләренең фикеренчә, агач мәчет – кыш көне (ягып җылыту җиңелрәк), таш мәчет исә җәй көне файдаланылган булырга мөмкин.

Шушы мәчет янында ук кирпечтән салынган зур гына бина хәрабәләре тикшерелде. Соңгы елларга кадәр бу бинада үзенең гаиләсе белән югары дәрәҗәле берәр дин әһеле яшәгәндер, дип фаразлана иде. Бүген исә аның функциясен мунча яисә тәһарәтханә белән бәйләп аңлаталар. Бу фикер идән астында урнашкан җылыту системасы каналлары, сууткәргеч торба ватыклары кебек табылдыклар белән раслана. Белгечләр исә Биләр биналары төзелешендә Якын Көнчыгыш һәм Урта Азиянең IX–XI гасырларга караган архитектура элементларын таба.

Җамигъ мәчетенең көньяк-көнбатыш ягында мәйданы ягыннан артык зур булмаган зират урнашкан. Бирелә 50ләп кабер тикшерелде. Үлгән кешеләрнең кайберләре кирпеч төрбә эчендә ята иде. Барысы да саф мөселман йоласы буенча җирләнгән. Бу – болгар ханнарының, аларның якыннарының, гомумән, югары катлау кешеләренең каберләре. Шәһәр уртасында, Җамигъ мәчете янында, махсус төрбәләрдә гади кешеләрне җирләмәгәннәр билгеле.

Тагын бер кызыклы факт: мәчет тирәсендә гади кешеләр яши торган агач йортлар, хуҗалык корылмалары, ашлык саклау амбарлары урнашкан. Арада безнең якларга бөтенләй дә хас булмаган торак йортлар да бар. Тал чыбыгыннан үрелгән читән, ике яктан калын итеп кызыл балчык белән сыланган. Өй эчендә, ишегалдында тандыр тибындагы мичләр тора. Бу йортлар безнең як халыкларыныкына охшамаган, бирелә, һичшиксез, Урта Азия якларыннан, Шәрык илләреннән килгән төзүчеләр яшәгән.

Җамигъ мәчете хәрабәләре.



Фотолар автордан алынды

Әлеге мәчет комплексы – Идел буе Болгарстаны дәүләтендә археологлар тарафыннан өйрәнелгән иң борынгы архитектура корылмасы һәм ул, турыдан-туры булмаса да, Биләрнең беркайчан да гади шәһәрләр рәтендә йөрмәвенә ишарәли. Белгечләр раславынча, ул заманнарда Җәмигъ мәчете – вәгазь сөйләү һәм ил хакиме (хан/әмир) исемен кушып хөтбә уку өчен имам-хатибка дип махсус ясалган мөнбәре белән – бары тик дәүләтнең административ-сәяси үзәгендә генә булган. Кыскасы, кылган гамәлләре белән Алмыш хан Биләрне дәүләтнең төп башкаласы роленә хәстәрли.

Биләр мәчете белән бәйле тикшеренүләргә киңрәк тукталуыбызның сәбәбе – Болгар илендә шәһәрләр барлыкка килү процессының ислам дине белән тыгыз бәйләнгән булуын күрсәтүдә. Иң борынгы шәһәрләр рәтендә йөрүче Болгар, кызганычка, Ибне Фадлан язмаларында (һәм шулай ук X–XII йөзләргә караган рус елъязмаларында) бер тапкыр да телгә алынмаган. Сиксән елга якын системалы рәвештә археологик казу эшләре алып барылуга карамастан, биредә монгол яуларына кадәрге чорда салынган мәчет эзләре табылмаган, торак йорт урыннарының саны дистәдән артмый, юрта эзләре дә юк, башка матди калдыклар да бик аз. Дөрес, хәзерге шәһәрлек территориясендә, Кече Иерусалим чокыры итәгендә, X гасырның беренче чирегенә караган бер урын бар, әмма аны Болгарның чишмә башы дип тану бик кыен – Багдад илчелеген чокырда каршы алмаганнардыр ич инде.

Археологлар Болгар шәһәрлегенең X–XI гасырлардагы мәйданын 9–12 га чамасы дип күрсәтә. Ни генә булмасын, X гасырга караган гарәп-фарсы язма чыганакларында Болгар һәм аның белән беррәттән Сувар да телгә алына. «Бу шәһәрләрнең икесендә Җәмигъ мәчете бар, халык саны исә 10 меңгә җитә», – дип яза әл-Балхи. Әмма хикмәт шунда ки, X гасырда Болгар илендә халык саны 10 меңгә җитә торган шәһәрләр булуы бик шикле. Урта гасырларда гигант шәһәрләр рәтендә йөргән Биләрдә дә ул кадәр халык булмаган. Ә менә Бөек Идел сәүдә юлында урнашкан Болгарның X гасырда (тагын да элегрәк булмаса әле) эре сәүдә үзәге, җәен халыкара ярминкәләр үткәрелә торган урын булуын инкяр итеп булмый. Шул ук әл-Балхи һәм әл-Истаһри язмаларында күрсәтелгәнчә, «тышкы Болгар – кечкенә шәһәр, киң мәйдан биләп тормый; ул дәүләтнең иң эре сәүдә ноктасы буларак кына танылу алган». Ә ул сәүдә ноктасы – Ага-Базар, чит илләрдән килгән сәүдә корабларын каршы алуны җиңеләйтү өчен Идел ярында урнашкан булгандыр, мөгаен.

Ислам дине кабул ителгәннән соң Болгар иле гарәп-фарсы географлары, тарихчылары, сәяхәтчеләре тарафыннан урта гасырлар цивилизациясенең иң атаклы һәм бай бер өлеше сыйфатында тасвирлана. Эреле-ваклы шәһәрләре булу һәр цивилизациянең төп билгеләреннән санала. Урта Идел һәм Кама буйларында археологлар тарафыннан ачыкланган болгар калаларының саны 170кә җитә. Аларның өч дистәдән артыгы – чын шәһәр калдыклары. Болгар шәһәрләре ерактан ук балкып торучы мәчет манаралары, кызыл кирпечтән салынган җәмагать биналары – мунчалары, төрбәләре белән Шәрык дөньясының мөселман шәһәрләренә охшап торган.

X гасырның беренче яртысында барлыкка килгән болгар шәһәрләре Болгар, Биләр һәм Сувар белән генә чикләнмәгән, әлбәттә. Рус елъязмаларында телгә алынган Җүкәтау, Кашан, Ашлы (Ошель) шәһәрләрен дә шул исемлеккә кертергә мөмкин. Болгар дәүләтенең көньяк чикләрен саклау максаты белән Самара Дугасында калкып чыккан Мөрән каласы да (Муромский городок) иң борынгы шәһәрләр исәбендә.

Билгеле булганча, ислам дине гарәп сәүдәгәрләре даирәсендә барлыкка килә. Коръән сәүдәгәрләрнең эшчәнлеген һәрьяклап хуплый, канун кысаларына туры китереп регламентлаштыра. Икътисад ягыннан караганда, урта гасыр шәһәре беренче чиратта – һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге. Гарәп-фарсы географлары хезмәтләрендә Идел буе Болгарстаны, Хәзәр

дәүләте һәм мөселман Хәрәзме кебек, инде IX гасырда ук Хәлифәт өлкәләре белән тыгыз сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырган ил буларак тасвирлана. Академик В.Янин, нумизматика материалларына нигезләнеп, «VIII гасырдан алып XI гасыр башларына кадәр Идел буе Болгарстаны сәүдә өлкәсендә Русьны Шәрык илләре белән бәйләүче бердәнбер капка ролен уйнап килде», – дип язган иде. Болгар дәүләтенең Шәрык, Көнбатыш Европа, Балтыйк буе һәм Скандинавия илләре белән багланышлары археологиядә дә чагылыш таба. Болгар, Биләр, Мөрән ише эре шәһәрләрне казыганда чыккан табылдыклар арасында VIII–X гасырларда сугылган көмеш дирһәм хәзинәләре, Урта Азиядән (Үргәнеч, Сәмәрканд, Мерв), Ираннан (Кашан, Рей), Һиндстаннан, Сүриядән, Византиядән китерелгән кыйммәтле савыт-саба, муенса төймәләре, бизәнү әйберләре ясаганда кулланыла торган лазурит, сердолик, гранат, тау бәллүре кебек асылташлар һәм башка әйберләр бар. Төсле витраж пыялалары, лампалар, савыт-саба Грузия, Әрмәнстан, Азәрбайҗанда эшләнгән. Казылмаларда Херсон һәм Таврия остаханәләрендә ясалган амфоралар, Лотарингиядә, Аквитаниядә эшләнгән бакыр-көмеш савытлар очрый. Сирәгрәк булса да, Алмания, Дания, Чехиядә сугылган акчалар табыла. X–XI гасырларда ясалган франк кылычлары болгарларга варяглар аша килеп кергән. Швеция, Норвегия, Финляндия, Дания, Польша, Венгриядә һәм Балтыйк буе дәүләтләрендә X гасырда сугылган болгар акчалары табылган. Әлбәттә, Ислам динен кабул итү чорында формалаша башлаган халыкара сәүдә багланышлары болгарларда икътисадның һәм мәдәниятнең үсешенә уңай тәэсир ясаган.

Икътисадның кызу темплар белән үсеше яңа шәһәрләр барлыкка килү процессын тагын да җанландырып җибәрә. Бу бигрәк тә X гасыр ахырында һәм XI гасыр башларында, дәүләт белән Ибраһим әмир идарә иткән чорда ачык күренә. Бу вакытта инде Идел буе Болгарстаны – ислам идеологиясе астында берләшкән, гомуми болгар исеме алган элеккеге кабиләләрнең бердәм һәм көчле дәүләте. Нәкъ менә шул вакыт аралыгында Казан һәм Алабуга шәһәрләренә нигез салына. Әлбәттә, рус елъязмаларында Бряхимов исеме белән телгә алынган Ибраһим шәһәре дә XI гасыр башыннан да соңга калмыйча нигезләнгән булырга тиеш. 1236 елгы монгол-татар яуларына кадәр яшәгән шәһәр-калаларның шактый өлеше X–XI гасырларда Бөек Идел юлы һәм аның бер тармагы булган Чулман сәүдә юлы өстендә барлыкка килә. Кызганыч, бу шәһәрләрнең күбесе, хәтта язма чыганакларда телгә алынганнары да, археологик яктан бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән, аларда мәчетләр булу-булмавы да билгеле түгел. Ә бит Шәрык илләрендә Җәмигъ мәчете – торак пунктларга шәһәр статусы бирә торган иң мөһим билгеләрнең берсе.

Югарыда китерелгән фактлар Идел буе Болгарстанында шәһәрләр барлыкка килү, фән теле белән әйтсәк, урбанизация процессының илдә ислам дине таралу һәм сәүдә үсеше белән параллель рәвештә барганлыгын күрсәтеп тора.

КИТАП К

ФАЯЗ ХУҖИННЫҢ КИТАП КИШТӘСЕ

«Ислам – ул дин генә түгел. Ул әле фәлсәфә дә, әхлак кодексы, тулы бер фикер сөреше рәвеше дә», – дип каршы алды безне Идел буе Болгарстанын ныклап өйрәнүче күренекле тарихчы, археолог Фаяз Хуҗин һәм үзенең китапханәсенә чакырды. Сүз уңаеннан, биредә 10 мең томга якын китап тупланган, һәм бу китапханә иясен, галим булу белән беррәттән, китап сөюче буларак та характерлый.





БАЛА ҺӘМ ҮСМЕР ЧАКТА ЙОГЫНТЫ ЯСАГАННАРЫ

Миңа алты яшьләр тирәсе булгандыр... Әти Габдулла Тукайның нәзек кенә ике китабын алып кайтты. Матур итеп бизәлгән, рәсемнәр төшерелгән «Шүрәле» белән «Су анасы» китаплары иде ул. Әни эштән кайтуга, мин гел шул әкиятләрне укырга сорыйм. Көн саен шулай аптыратуым әнине туйдырган, күрәсең. «Үзең укырга өйрән», – диде ул миңа. Укырга шактый тиз өйрәндем, әти-әни ярдәме белән, әлбәттә.

Минем бала вакытым, мәктәп елларым гади татар авылында узды. Китапханә бар иде, әмма сайлау мөмкинлеге чикле. Бервакыт ташларга дип җыеп куелган китаплар арасында Вениамин Каверинның «Два капитана» китабын таптым – таушалмаган, өр-яңа диярлек, рус телендә булганга, беркем дә укымаган, күрәсең. Китапханәче Гөлчирә ападан шул китапны сорап алдым, әмма романны берничә мәртәбә укырга омтылып карасам да, булмады – ул чагында рус телен белүем дә бик чикле иде. Аның каравы нәкъ менә әлеге басма шәхси китапханәмдә беренче номерлы китапка әйләнде һәм озак еллар дәвамында яраткан китабым булды. Узган елда аның соңгы басмасын Мәскәүдән кайтарттым.

Үсмер чагымда мәгариф турындагы китапларны кызыксынып укыдым, бигрәк тә унтугызынчы гасырда ук дин белеме белән беррәттән, математика, геометрия, астрономия кебек дөньяви предметлар укытылган мәдрәсә тарихы турындагыларны. Бүген әлеге тема белән кызыксынучыларга Альта Мәхмүтованың «Становление светского образования у татар», «Лишь тебе, народ, служенье!» һәм башка монографияләрен укырга тәкъдим итәр идем.



ЯРАТКАН КИТАПЛАР

Мәрҗанигә бик еш күз салам. Элегрәк тулысынча аңлап та бетермәгәнмен, хәзер һәр җөмләсе хәйран калдыра – аларга уйланырга мәҗбүр итүче күпме фәлсәфә салынган! Беренче чиратта Мәрҗанине мөселман дөньясында дин белгече буларак беләләр, ә бит ул әле тарихчы да – милли тарих фәненә нигез салучы! «От Волжской Булгарии к Золотой Орде и Казанскому ханству» – әлеге китап һәрвакыт эш өстәлемдә ята.

Минем өйдәге китапханәмдә 10 меңгә якын китап исәпләнә. Бу нигездә, әлбәттә, махсус әдәбият – археология, тарих буенча, ләкин матур әдәбиятка караганнары да күп. Мемуар жанрындагы әдәбиятны укырга яратам – бигрәк тә галим һәм сәяси эшлеклеләрнең хатирәләрен. Соңгы вакытта китапханәмне баеткан китаплар арасында Ли Куан Ю, Жорес Алфёров, Валентин Янин, Феликс Чуевның «140 бесед с Молотовым» китаплары бар. Күптән түгел генә бөек рәссам Илья Репинның мемуарларын укыдым һәм аның язучылык сәләтенә таң калдым.

Иң яраткан авторларыммы? Юк, санап чыгу мөмкин түгел, әсәрләре минем шәхси китапханәмдә булганнарын гына атап үтәм. Рус классиклары һәм хәзерге заманныкылар – Пушкин, Достоевский, Лесков, Чехов, Бунин, Бродский,

Фото: elitat.ru

ИШТӘСЕ

Астафьев, Гранин. Чит ил әдәбиятыннан – Байрон, Гюго, Кафка, Хемингуэй, Уайльд. Хәзерге заман татар язучылары һәм шагыйрьләреннән – Еники, Гыйләҗев, Мәһдиев, Имамов, Фаиль Сафин, Әгъләмов, Фәйзуллин, Галиев, Аймәт.

СОҢГЫЛАРДАН ХӘТЕРГӘ УЕЛЫП КАЛГАН КИТАПЛАР

Ольга Ивановaның Казан ханлыгының атаклы ханбикәләре турындагы трилогиясе («Нурсолтан», «Гәүһәршат», «Сөембикә») һәм аның Алтын Урда турындагы соңгы романы. Мин авторның үзе сурәтләгән чорларга шулкадәр тирән төшә алуына хәйран калдым. Минем күзлектән караганда, дөрес һәм ышандырырлык итеп сурәтли белә. Профессиональ тарихчыларга, бигрәк тә кайвакыт тулы бер чорны бик өстән генә күз алдына китергән яшьләргә аңардан өйрәнергә кирәк.

УКЫРГА КИҢӘШ ИТӘМ!

Китапханәмдә ислам турында китаплар күп. Шуларның берсе – Игнатий Юлианович Крачковский рус теленә тәрҗемә иткән Коръән китабы. Академик Крачковский – тулы бер дөнья ул! Крачковский гарәп телен (хәзергесен дә, урта гасырларныкын да) шулкадәр яхшы белгән ки, Гарәбстан базарында гарәп кешесе белән аралашканда аның кайсы авылдан икәнлеген сөйләшүе буенча дөрес әйтеп бирә алган. Аның тәрҗемәсендәге Коръән – иң төгәле.

Берничә ел элек бөтен ислам дөньясы тарихы буенча бик эчтәлекле китап басылды. «Исламская цивилизация» дип аталган хезмәт авторлар коллективы тарафыннан эшләнгән. Кызыклы факт, тарих, анализдан тыш, анда бик матур рәсемнәр дә урнаштырылган.

Форсаттан файдаланып, тиздән үземнең китабымның чыгуын да әйтеп үтәм. Без аны ТР ФАнең Халиков исемендәге Археология институты җитәкчесе Айрат Ситдыйков белән бергә эшләдек. Татар, рус һәм инглиз телләрендәге «Болгар. Мусульманская цивилизация на Волге» дип аталган матур басма нәкъ менә Идел буе Болгарстанында исламны кабул итүгә 1100 ел тулуны билгеләп үтәсе көннәрдә типографиядән чыкты.

Тагын бер теләгем – атаклы шәхесләрнең мемуарларын, алар турындагы биографик әдәбиятны күбрәк укыгыз. Татар телендә укучыларга, бигрәк тә яшьләргә, «Җыен» нәшриятында басылып килүче «Шәхесләребез» сериясе белән танышырга киңәш итәм.

КӘГАЗЬ ЯИСӘ ЭЛЕКТРОН КИТАПМЫ?

Минем электрон китабым бар. Юлда йөртергә уңайлы. Әмма ни генә дисәң дә, мин башка чорда тәрбияләнгән кеше, шуңа күрә миңа кәгазь вариант күбрәк туры килә. Китапханәмдә урын алган һәр китапны кайдан сатып алганымны, аның исен, укыганнан соң алган беренче тәэсирләремне хәтерлим, дип әйтә алам. Бу электрон китап бирә алмаган, тулы бер дөнья!

МИНЕМ ӨЧЕН КИТАП НӘРСӘ УЛ

Минем өчен китап – бөтен нәрсә. Ул уйланыр өчен азык, тормышны тирәнрәк аңларга ярдәм итүче. Үзеңне үзең кая куярга белмәгән авыр мизгелләрдә ул әле җанга дәва да.

ХӘЗЕР УКЫЙ ТОРГАННАРЫ...

Джордж Оруэлл. Аның «1984» дип аталган романында китапка бирелгән аннотациядәге сорауларга җавап табасым килгән иде. Тапмадым. Бәлки мин шактый оригиналь фикер сөрешенә ия авторны тулысынча аңлап та бетермәгәнмендер.

Ольга Ивановaның «Великая Орда» романын икенче кат укыйм. Аны тарихчы, шәп язучы буларак бик хөрмәт итәм.

ӘЛЕДӘН-ӘЛЕ КИРЕ КАЙТЫП УКЫЙМ...

«Коръән серләре»ндә совет язучысы Гариф Гобәй аять, сүрә, изге китапның бүлекләренә, өзекләренә анализ ясый. Һәм, әлбәттә, атеистик нәтиҗәләргә килә. Беренче тапкыр мин аның хезмәтен әле мәктәптә укыганда ук өйрәнә башладым, үзгәртеп кору башланган елларда тагын бер мәртәбә укыдым, бүген кабат аңа мөрәҗәгать иттем. Хәтта СССР заманында да мин үземне атеистларга кертми идем, әмма шулай да фән кешесе буларак мин һәр нәрсәгә тәнкыйди күзлектән карарга тиеш. Уйланырга мәҗбүр итә торган китапларны яратам, Гобәйнең «Коръән серләре» – шундыйлардан.

Антик авторларның (Софокл, Овидий, Еврипид, Вергилий, Гораций), көнчыгыш фикер ияләренең (Омар Хәйям, Алишер Навои, Мәхтүмкули) әсәрләрен кабат-кабат укыйм – бүгенге көн проблемалары турында язалар кебек тоела миңа. Эш өстәлем янындагы киштәдә һәрвакыт Равил Фәйзуллин шигырь җыентыклары. Аның ике юллыкларын яратам, элегрәк аларның бөтен тирәнлеген аңлап бетермәгәнмен. Аларда тирән фәлсәфә, халыкның һәм шагыйрьнең зирәклеге чагылыш тапкан икән.

ӨМЕТНЕ АКЛАМАГАННАРЫ...

«Зулейха открывает глаза», «Дети мои», «Эшелон на Самарканд» – Гүзәл Яхинаның бөтен романнарын игътибар белән укыйп чыктым. Шәп яза. Бигрәк тә «Дети мои» ошады. Әмма мин бу романнарда татарларга карата бераз аңлашылмый торган мөнәсәбәт сизәм. Яратмаумы бу? Халыкның тарихи тамырларын, исән калу өчен көрәштә чыныккан холкын аңламау, белмәүме? «Зөләйха»ны укыганда, мәсәлән, анда сурәтләнгән татарлар өчен ничектер уңайсыз, хәтта ки оят булды миңа. Юк, без андый түгел, дип кычкырасым килде.

НИЧЕК ЯХШЫ КЕШЕ БУЛЫРГА?

Луиза Янсуар

Җәйге яллар – вакытны үзеңә күбрәк билгеләр өчен кулай чак. Ел дәвамында «карармын» дип тамгалап куйган фильм, сериалларны карап, «укырмын» дигән китапларны укырга мөмкинлек табып, мәсәлән. Ә яңаларына килгәндә, алар арасында да кинәнеп карарлык, йә укырлыклары җитәрлек.



ДЖОНАТАН ФРАНЗЕН. ПЕРЕКРЁСТКИ
Елы: 2022
Иле: АКШ
Жанры: зур роман
Нәшрияты: Corpus
Тәрҗемәчесе: Юлия Полещук

Джонатан Франзен – хәзерге Америка язучылары арасыннан лаеклы рәвештә иң күренекле һәм продуктив иҗат итүчеләрдән берсе буларак исәпләнә. Һәм – иң күп укыла торганы да. Аңа карата инде соңгы дистә ел эчендә әдәбият тәнкыйтьчеләре «эре калибрлы язучы» дигән билгеләмәне куллана. Моның белән килешми мөмкин түгел. Чөнки Франзен чын мәгънәсендә эре масштаблар белән эш итә: әсәрләренең күләме ягыннан да, Фолкнер, Вулф, Ирвинг традицияләрен дәвам итеп, чын мәгънәсендә «зур америка романын» үстерү, яңарту җәһәтеннән дә.

Шул ук вакытта Франзен классик традицияләрне постмодернистик эзләнүләр белән кушып, экспериментлар ясаудан да курыкмый. «Поправки» романыннан (2001) соң, без аның экспериментлары белән «Свобода» (2010) һәм «Безгрешность» (2015) мисалларында инде очраштык. Һәм менә «Перекрёстки»да автор үзенә яңа сынау һәм максат билгеләгән – тулы бер зур романнар циклы тудыру. Бу, чыннан да, зур амбицияләр мәйданы: 600әр битле романнан торган трилогия, өстәвенә аталышы

Фотолар litres.ru сайтыннан алынды

да шактый җәлеп итүчән – «Барлык мифологияләргә дә ачкыч».

Әсәрнең үзәгендә – артык бәхетле булмаган гади генә провинциаль гаилә. Пастор белән аның хатыны. Алар урта яшьләр кризисы кичерә, бер-берсенә карата моңарчы җыелып һәм мөмкин булганча яшереп килгән үпкә-ачуларын сәер ысуллар белән дөньяга бушата. Без китапны укый башлаган мәлдә икесе дә критик халәттә, зур бер сорау алдында тора – саклап калыргамы гаиләләрен, әллә юкмы?

Әсәрнең үзәгендә – кешеләр һәм аларның язмышлары, ләкин монда тагын бер персонаж дәрәҗәсенә диярлек үстерелә торган «үзәк» бар, ул да булса – чиркәү каршындагы христианнар клубы. Исеме – «Перекрёстки». Бу клуб нәкъ менә барысын да берләштерүче, персонажларның язмышларын бер төенгә төенләүче сәбәп тә, нәтиҗә дә.

XIX–XX гасыр социаль романнары традициясен Франзен моңарчы да дәвам итә иде, әмма бу романда ул аеруча кискен гәүдәләнеш ала. Мин романны укыганда әледән-әле үземне Томас Вулфның «Взгляни на дом свой, ангел» һәм «Домой возврата нет» кебек «кирпеч»ләрендә яшәгәндәй хис иттем. Әйе, гасыр белән гасыр арасы гына аерма, әмма проблемалар барыбер дә шул ук булып кала бирә, без, кешеләр дә, Вакыт агымы аша узганда, һаман шул ук булып кала бирәбез, әллә ни үзгәрмибез. «Перекрёстки» каһарманнары берөзлексез талаша, әрләшә, өйләрен ташлап чыгып китә, кире әйләнеп кайта, кайткач, барысы да өр-яңадан башлана һәм дәвам итә, дәвам итә, дәвам итә... Романның соңгы битләренә кадәр тормышның бу даулы шаукымында бәргәләнәбез, чишелеш югын да бик яхшы аңлыйбыз.

Секталар һәм руханилек мавыгуына күмелгән 70 нче еллар Америкасы белән безнең үз заманыбыз бөтенләй дә аерылмый диярлек. Һәм, аннан да бигрәк, бу әлеге дә баягы Голсуорси, Манн, Достоевский, Толстой, Бальзак, Гюго, Маркесларга да килеп тоташа торган җеп, дисбе.

Зур Американың кечкенә генә бер кисемтәсен тәшкил иткән «Перекрёстки» клубының прототибы, әлбәттә, өстә үк ята – бу хәзерге көнбатыш җәмгыяте. Франзенның аңа чыгарган бәясе һәм карары үтә кискен: аның фикеренчә, бу җәмгыять – «XX йөзнең нә шул азакка елларында үз-үзен саткан, йөзен югалткан кешеләр һәм өметләр өере». Аның каһарманнары – искиткеч талантлы һәм әчке перспективалы кешеләр. Бу – харап ителгән өметләр һәм баштан ук чынга аша алмаган хыяллар, утопияләр турындагы роман да.

Франзен каһарманнары христиан кануннарыннан китеп, бәхет тапмый, алар барып сыеныр урын һәм кочак эзләвен дәвам итә. Әмма сүз клуб хакында барганда, дин генә күздә тотылмый. Ә, иң беренче чиратта, кешеләрдә яшәгән эчке әхлак белән иман. Автор биредә без кайчандыр йөз чөергән патриархаль канунннарның шул дәрәҗәдә үк кире кагып, өзеп ташларлык зынҗырлар булмавына да ишарә итә. Аның төп соравы – нинди ирек хакына алмаштык без элеккеге яшәешебезне? Нәрсә бирде безгә ул ирек һәм без чыннан да бәхетлерәкме хәзер?

> «**ТӨРКЕМГӘ ХРИСТИАН ҖӘМГЫЯТЕ БУЛАРАК НИГЕЗ САЛЫНГАН ИДЕ, ӘММА УЛ АННАРЫ ҮЗ ТОРМЫШЫ БЕЛӘН ЯШӘП КИТТЕ.** ҺӘМ БЕЗНЕҢ НӘРСӘГӘ ЮЛ КУЙГАНЫБЫЗНЫ АҢЛАУ ГАҖӘПЛӘНДЕРӘ. МИНЕМ – НӘРСӘГӘ ЮЛ КУЙГАНЫМНЫ ВАЕМЛАУ. ӘГӘР БОЛАРНЫҢ БАРЫСЫ ДА БЕЗНЕ ЯҢАДАН ХОДАЙГА КИТЕРМИ ИКӘН, БУ, АСЫЛДА, БАРЫ ТИК ИНТЕНСИВ ПСИХОЛОГИК ЭСПЕРИМЕНТ КЫНА, БАШКАЧА АТАП БУЛМЫЙ. ҺӘМ БУ ЭКСПЕРИМЕНТ БЕЗНЕ ИСКИТКЕЧ ДӘРӘҖӘДӘ ИРЕКЛЕ ДӘ ИТӘ АЛА, ДӘВАСЫ ЮК ГАЗАПКА ДА ДУЧАР ИТӘРГӘ МӨМКИН».

Сүз уңаеннан, Франзен – инанулы, дини кеше түгел, ул үзен «яшерен инанусыз христиан» дип атый. Һәм аның фикеренчә, традицион җәмгыять канунннарына кире әйләнеп кайту – җүләрлек булыр иде. Әмма ул, шуның белән беррәттән, менә нәрсәне дә ассызыклый: безгә барыбызга да сыеныр ышык кирәк. Ә бу ышык – ата-бабалардан килгән дөреслек белән иман (ул дин белән тәңгәл дә булырга мөмкин, булмаска да!). Юкка гына «Перекрёстки» каһарманнары әсәрнең башыннан азагына кадәр «Ничек яхшы кеше булырга?» дигән сорауга җавап эзләмидер. Һәм моңа әсәр геройларының җаваплары да бик гади. Яхшы кеше булу ул: якыннарыңны кайгырту, алар өчен җавап тоту; Вьетнамда барган вакыйгаларны үз шәхси газабың итеп кичерү, гаеп тою; яраткан кешеңне рәнҗетмәү һәм аның хакына корбанга барырга әзер булу... Франзенның әхлак канунннары шулкадәр гади, гадәти, һәм ул аларны фәлсәфи категорияләр яссылыгына күчерүне бөтенләй кирәк тапмый. Гамәл кыл – менә шул синең иң зур көчең һәм җаваплылыгың. Тәвәккәлегең һәм дөреслегең. Ялгышасың икән, төзәт ул гамәлеңне!

«Перекрёстки» – бик массив һәм бер урында таптанып тора торган әсәр. Анда декорацияләр дә, локацияләр дә алышынмый диярлек. Әмма бу – гаҗәеп кызыклы һәм нечкә диалоглар, борылышлар, сурәтләүләр белән тулы киң бер полотно.

PRESSA

ИСКЕ ИБРАЙ: ЗУР АВЫЛНЫҢ ОЛЫ ДАНЫ САКЛАНЫРМЫ?

ИСКЕ ИБРАЙ



Фото: Александр Ефремов

Бөтен республикага атаклы зур авыллар бар. Аксубай районының Иске Ибрай авылы әнә шундыйлардан. Быелгысы уку елында урта мәктәптә 157 укучы белем алган, бу бер Иске Ибрай авылы балалары гына. Ләкин җирле халык өчен әлеге сан зур түгел: 1970 нче елларда белем йортында 1 мең 200 бала укыган.

Данлыклы авылның бүгенгесе ничек? Нинди проблемалар белән яши? Иске Ибрайга баргач, әнә шуларны ачыкларга тырыштык.

Руфия Фазылова

БАЛАЛАР САНЫ КИМИ...

Авыл зур дидем. 1935 елгы халык санын алу буенча Иске Ибрайда 3 мең 500 тирәсе кеше яшәгән. Әле 2005 елларда да 2 меңнән артык кеше исәпләнгән. Бүген исә 1700 кеше гомер итә. Барлыгы 634 йорт бар, шуның 575 есендә даими рәвештә яшиләр, калганнарына кайтып-китеп кенә йөриләр. Нигездә алар – әби-бабайлар мәрхүм булгач ябылган йортлар.

Шулай да Иске Ибрайда без ишелгән йортлар күрмәдек дияргә була. Монда бердәнбер проблема – юллар начар. Авылның барлык урамнарын кушсаң, 20 чакрымга җыела икән. Аларның барысына да таш түшәлгән. Ләкин мондый зур авылда матур, тигез асфальт булмавы азрак гаҗәпләндерде. Берничә еллар элек үзәк урамнарга таш плитәләр түшәлгән булган. Нәтиҗәдә машинада да үзеңне ат арбасында барган кебек хис итәсең...

Юлны санамаганда, авылда яшәр өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Дүрт мәчеттән көн саен азан тавышы яңгырый, алты кибет, амбулатория үзәге, ветеринария пункты, мәктәп, балалар бакчасы, мәдәният йорты, китапханә, балалар өчен ике зур уен мәйданчыгы... Мондый

1
Авылда балалар өчен ике зур уен мәйданчыгы бар.

2
Амбулатория үзәгендә, ике югары белемле табибны кертеп, ун кеше эшли.

3
Авылның хәзерге белем үзәге 1984 елда ишекләрен ача.

4
– Быел унберенчене тугыз бала тәмамлады, – диде мәктәпнең уку, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Руфия Ярмөхәммәтова.

социаль объектлар белән бик сирәк авыллар мактана ала.

Мәктәп дигән идем. Авылның хәзерге белем үзәге 1984 елда ишекләрен ача. Ике катлы, бик зур бина ул. Берничә ел элек аңа капиталь төзекләндерү булган.

– Белем йорты ачылган елны дүрт йөзгә якын бала иде, – диде Иске Ибрай мәктәбенең уку, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Руфия Ярмөхәммәтова. – Кызганыч, балалар саны кимүгә бара. Быел унберенчене тугыз бала тәмамлады. Тугызынчы сыйныфлар ундүрт укучы. Гадәттәгечә, кайберләре китәчәк инде.

– БДИ нәтиҗәләре ничек? – дим.

– Төрле елны төрлечә. Химия, биология фәннәрен югары балларга биреп, бүгенге көндә КДМУның бюджет төркемендә белем алучы укучыларыбыз да бар. Быел да төрле нәтиҗәләр булды. Тугыз баланың барысы да аттестат ала, БДИны бирә алмаучылар юк.

Мәктәпнең гектарга якын җире бар. Анда ни генә үсми. Рәт-рәт тезелгән кәбестә, кишер, суган түтәлләрендә ник бер чүп булсын. Бакчаны укучылар үзләре карый икән – җәйге практикаларын монда уздыралар. Аның каравы, мәктәп ашханәсендә ел буе үзләре үстергән яшелчә, җиләк-җимеш ашыйлар.

Иске Ибрайда мәктәпкәчә яшьтәге йөздән артык бала бар. Ләкин авылда теркәлеп тә, шәһәрдә яшәүче яшь гаиләләр шактый икән. Шулай да мәктәптә якын киләчәктә бала саны йөздән кимемәскә тиеш. Һәрхәлдә, укытучылар шулай дип өметләнә.

– Димәк, сездә дә яшьләр читкә китү ягын карый? – дим Иске Ибрай авыл җирлеге башлыгы Мансур Миңнегуловка.

– Әйе, шул бер дәүләттә яшибез бит. Аның сәбәпләре мәгълүм инде: яшьләрне шәһәр кызыктыра. Безнең җирләр «Аксу Агро»га карый. Анда эшләүчеләр дә шактый. Тик бүген җир эшенең кадере юк бит...

Авыл җирлеге башлыгы белән амбулатория үзәген карап килдек. Монда лабораториядән башлап теш табибына кадәр бар. Ике югары белемле табибны кертеп, ун кеше эшли икән.

– Амбулатория үзәгеннән бик канәгатьбез. Табиб, шәфкать туташлары бик яхшы бездә.

Район хастаханәсенә барганда әзер анализлар белән барабыз, – диде авыл апалары.

Авылның бүгенгесе әнә шундый. Элек ул тагын да гөрләп торган. 1970 елда биредә электр энергиясе белән эшли торган ак он тегермәне төзелгән. Бер сәгатькә 8 центнер он тарттырганнар. 1985 елда икмәк пешерү заводы салынган. Тәүлегенә 5000 буханка икмәк пешереп, Иске Ибрай халкын гына түгел, тирә-юнь авылларны да ипи белән тәэмин иткәннәр. Алдынгы «Татарстан» колхозы исә йөзләрчә кешене эшле иткән.

ФЕРМЕР БУЛУ АВЫРМЫ?

Авылларда еш йөргәч күреп торабыз: мал асрамый халык. Районы-районы белән бигрәк тә. Көтү чыкмаган салалар фәлән кадәр бит. Иске Ибрайда исә хәл бүтәнчә: өч көтү чыга. Шәхси хуҗалыкларда дүрт йөзгә якын сыер бар. Авылда мал асраучылар күп булса да, Сафиннар кебекләр берәү генә. Ирле-хатынлы Марат белән Лилия район буенча иң күп сөт савучы фермерларның берсе. 2011 елдан бирле күпләп мөгезле эре терлек асрыйлар.

Сафиннар авыл башына ике ферма бинасы төзегән. Иген саклау өчен амбар, сенаж сала торган ике баз, хайваннар өчен киртә белән тотып алынган утарлар корып куйганнар. Кыскасы, тулы комплекс монда.

Ферма янында безне хуҗабикә Лилия каршы алды. Ире Марат башка эшчеләр белән бергә кырда – печәндә иде.

– Без гел эзләнүдә булдык, – дип сүзен башлады Лилия. – Башта пилорама да тоттык, электр чыбыклары өчен шүреләр дә ясап саттык. Тире дә җыйдык инде. Кыскасы, эшләмәгән эш калмады. 2011 елда «Башлангыч фермер» программасына кереп, миллион ярым сум акча алдык. Ферма бинасын үз көчебез белән салдык, ә дәүләт биргән грант акчасына нәселле таналар алып кайттык.

Беренче коймак төерле була шул. Сафиннар башта буазланмаган таналар алып кайта. Нәтиҗәдә, алар бозаулап сөт биргәнче ике ел көтәләр. Ә бу фермер өчен дә бер дә отышлы түгел – алтмыш башны ашатып торырга кирәк бит!

– Бүген без сөт белән генә шөгыльләнәбез, – диде Лилия. – Тугач та бозауларны сатып җибәрәбез. Аның бәясе кыйммәт түгел инде – унике-ундүрт мең сум тирәсе. Санап карадык та, үстереп сату кыйммәткә чыга. Монда әле сыерларга да азык җиткереп булмый – үзебез үстергән икмәк язга кадәр генә җитә, аннары сатып алабыз. Хәер, аның кадәр мал асрарга фермада урын да юк. Шуның өчен бозауларны сатабыз.

Сөт саву механизмы көйләнгән. Савылган сөт торбалар буенча цистернага килә. Анда сөт суытылып тора. Кыскасы, элеккеге кебек чиләккә савып, аннан бидонга салып утырмыйлар. Чисталык ягыннан да болай әйбәтрәк.

Сыерлардан тыш, Сафиннар атлар да үрчетә. Алтмышлап бахбайлары бар. Монысы инде табыш алу өчен түгел, ә күбрәк җан кушканга. Гаилә башлыгы Марат атларга мөкиббән икән. Фермерлык эшенә алынгач, ул берьюлы өч ат алып кайта. Шуннан китә инде.

– Атларның колыннарын сатабыз, – диде Лилия. – Күбрәк бияләр генә асрыйбыз. Ат асрауның шунысы яхшы – сыерлардан калган бөтен коелган печән-саламны ашап баралар. Шуңа күрә минуска чыкмыйбыз. Тик яшермим – ат тоту әллә ни табыш китерми.

Һөнәре буенча Лилия югары белемле укытучы. Университетны кызыл дипломга тәмамлаган. Берничә ел мәктәптә тә эшләгән. Соңгы унбиш елда гел ире белән эшли. Бүген ул үзләрендә эшләүче сыер савучыларны да ял иттерә, малларга уколлар да кадый һ.б.

Бу һөнәрләргә җәйгә тагын берсе өстәлә – пешекче. Кыр эшләре вакытында, Лилия үзләрендә эшләүче биш ир-атны кырга барып ашата.

– Ике тапкыр кайнар ризык илтәм, – диде Лилия. – Марат та шунда тракторда эшли бит.

5
Ирле-хатынлы Лилия белән Марат Сафиннар район буенча иң күп сөт савучы фермерларның берсе.

Колхозлар заманында да кырда эшләүчеләрне ашатканнар. Бу аларга кадер-хөрмәт күрсәтү дә.

Хуҗабикәгә ияреп, без дә эшчеләрне ашатырга кырга бардык. Техника йөртүче ир-атлар барысы да Иске Ибрай авылы кешеләре икән. Сенаж салабыз, диделәр.

Марат Аксубай һөнәр училищесын тәмамлаган. Зур крестьян-фермер хуҗалыгы ачкан, махсус белеме булмаса да, алдынгылыкны бирми.

– Эш рәтен белсәң, югары белем кирәк түгел, – дип елмайды Марат. – Барысына да өйрәндем. Теләсә кайсы техникага утырып эшлим.

– Марат үткен, шуның белән бергә кешелекле, – дип сүзгә кушылды Иске Ибрай авыл җирлеге башлыгы Мансур Миңнегулов. – Лилия белән бик матур яшиләр. Без аларны үрнәк итеп куябыз.

Бергә дигәннән, Сафиннар чынлап та бөтен эшне бергә башкара. Кыш көне төне буе бозаулый торган сыерларны саклыйлар. Аларны кул белән саву, бозауларны аякка бастыру... Читтән караганда гына җиңел кебек күренә.

ӘБИ-БАБАЙЛЫ НИГЕЗ...

Иске Ибрайда гомергә берничә буын бергә яшәгән. Өлкәнрәк кешеләр әле дә: «Безне әбибабай үстерде», – дип сөйләшә. Кызганыч ки, авылда бүген шул традиция бетеп бара. Яшьләр аерым тору ягын карый. Шулай да бер түбә астында берничә буын яшәүче матур гаиләләр дә бар әле. Шуларның берсе – Мостафиннар. Йортта иң өлкән кеше – Зәйнәп апа, туксан ике яшен тутырган ул. Гаиләнең урта буын вәкилләре – Әхәт абый белән аның җәмәгате Мингайшә апа да лаеклы ялда инде. Һәм яшь гаилә – Марат белән Рузилә, аларның мәктәп яшендәге улы Самат белән кызлары Алинә.

Мостафиннар чын җир кешеләре, күп итеп мал-туар асрыйлар. Марат әйткәнчә, мөгезле эре терлек 16–18 баштан да ким булмый. Малларга ашату өчен азыкны үзләре әзерли – алты-җиде гектар пай җирләренә печән, иген чәчәләр. Тракторлары да бар, аңа чәчкеч, печәнне рулонга төрә торган барлык кирәк-яракны да сатып алганнар. Печән алып кайту, бакча сукалау кебек эшләрдә авылдашларына да булышалар.

Мостафиннар хуҗалыгында тагын зур булмаган пилорама да бар. Ун ел элек – йорт җиткергән чакта сатып алганнар. Кирәк-яракларына кулланалар. Аллаһ ризалыгы өчен дип, мәчеткә дә такта ярдырып биргәннәр. Зиратка, ләхет такталары ясатырга да сорап килә икән халык.

Хуҗабикә Рузилә безне бәлешләр белән каршы алды. Әлеге нигезгә килгәненә унсигез ел була икән. Үзе дә Иске Ибрайдан, ире Марат белән бер сыйныфта укыганнар. Булган килен: аш-суга да оста, йорттагы ике каенанасына да кадер-хөрмәт күрсәтә. Мингайшә апага инсульт булган, шуңа күрә аны бик караган.

– Әни өчен барыбыз да бик борчылдык, инде болай йөргәнгә Аллаһка шөкер итәбез. Йортыбызга янә ямь керде, – диде.

Рузилә табын янына йортның иң өлкән кешесе – Зәйнәп апаны да алып чыкты. Аяклары авыртa икән, авырлык белән йөри.

– Мин күбрәк үз бүлмәмдә дога укып утырам, авылдашлар да сәдака биреп китә, аларның якыннары рухына да дога кылам, – диде әбекәй. – Хәзер миннән эш юк инде. Рәхмәт

6 Хуҗабикәгә ияреп, без дә эшчеләрне ашатырга кырга бардык.

балаларга. Бүлмәдә кыштырдый башласам да, йөгерешеп киләләр. Бик итагатьле балалар, күз генә тия күрмәсен.

Зәйнәп апа турында «өйнең хуҗасы» диделәр. Һәм аның шулай икәнлеге күренә дә. Аннан узып берәү дә сөйләми.

– Әни ризалыгыннан башка эшләмибез дә, – диде Әхәт абый. – Аның хәер-фатихасын алмыйча, күрше авылга да чыгып китмибез.

Китү дигәннән, берәрсе юлда булса, Зәйнәп апа намазлыгыннан төшми – балаларына Аллаһтан хәерле юл сорап, дога кылып утыра икән.

Сөйләшә торгач, бер хәл ачыкланды: берничә ел элек Мостафиннар күрше әбиләре – Нурия апаны да үзләренә алганнар. Сиксән яшендәге әлеге ялгыз әби элек-электән Мостафиннарның гаилә дусты саналган.

– Нурия әбиебез Зәйнәп дәү әни белән бик дус булган, – дип сөйләде Рузилә. – Якын күршеләр, бер-берсенә ярдәм итеп яшәгәннәр. Аяклары авыр йөри башлагач, без аны үзебезгә яшәргә чакырдык. Йорты иске, идәннәре салкын иде, бәдрәф тә урамда гына. Карт кешегә мондый шартларда яшәү бик авыр бит. Шуңа да безгә күченергә каршы килмәде ул.

Үткен Рузилә «Ветераннарга торак» программасы буенча Нурия әбигә үз нигезендә өй салдыруга ирешә. Әнә шул бөтен уңайлыклары булган яңа йортта ялгыз әби биш ел яшәп калган.

– Нурия әбиебез вафат инде, сиксән сигез яшенә кадәр яшәде, – диде Рузилә. – Соңгы көненә кадәр аягында йөрде. Көн саен кайнар ризык алып керә идем. Үлгәндә дә янында булдык, бәхиллеген алып калдык. Урыны оҗмахта булсын...

Ул да түгел Марат та табынга кереп утырды: печән өсте. Авыл кешесенең бер минут тик утырмый торган чагы. Тик ул зарлану түгел, кыенсынып та бер сүз әйтмәде. Авыл тормышын үзе сайлаган бит. Һәм шуннан тәм табып яши дә.

– Без гаиләдә ике малай үстек, – диде Марат. – Абый да авылда калды. Гаиләсе белән икенче урамда яши. Иске Ибрайдан башка тормышны күз алдыма да китерә алмыйм. Җир кешеләре инде без. Әби-бабай белән үстек. Менә хәзер үз балаларыбыз да шулай өлкәннәр тәрбиясендә үсә. Моңа сөенеп бетә алмыйм. Безгә дә шулай картлык көндә оныклар белән бергә яшәргә язсын...

...Иске Ибрайдан ике төрле уй белән кайттык. Әлбәттә, авылда урта мәктәп булу сөендерә. Социаль объектлар да гөрләп эшләп тора. Әмма соңгы ун ел эчендә ике йөздән артык кеше кимегән. Тагын ун, егерме елдан ни булыр? Атаклы, зур авылларыбыз да шулай кечерәя баргач, башкаларыннан ни көтәсең...

7 Дүрт буын бергә яшәүче Мостафиннар гаиләсе.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Рамил Сөләймановның «Туган авылым – Иске Ибрай» китабыннан:

– Иске Ибрай авылының башлангычы Болгар дәүләте чорына килеп тоташа. Моңа дәлил булып халык телендә йөргән легенда, иске авыл, шәһәрлек урыннары, авыл янәшәсендәге болгар чоры кабер ташлары сөйли. Шуңа күрә авыл тарихын икегә бүлеп карау дөресрәк булыр: иске авыл чоры (Каенсар борынында урнашкан җир) һәм яңасы (бүген Иске Ибрай урнашкан җир).

Авылның исемен беренче килеп утыручы хөрмәтенә Ибрай дип атаганнар, дигән фикер яши: берәүләр шәһре Болгардан Ибря-Ибраһим килеп утырган, икенчеләр Иске авылдан хәзерге урынга Ибраһим атлы кеше күчеп килгән, ди.

ЮГАРЫ ҮРЛӘРГӘ ОМТЫЛГАНДА

Тәҗрибә һәм бу тармакны тирән белү белән ныгытылган һөнәри осталык. «Газпром межрегионгаз Казан» АҖ директоры, республика өчен стратегик әһәмияткә ия предприятие җитәкчесе **Ринат Сабировны** бу сүзләр бик төгәл бәяли.

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ генераль директоры

«Без кулланучы тарафыннан күрсәтелгән ышанычның кадерен беләбез», – дип әйтергә ярата Ринат Сабиров. Бигрәк тә бүгенге, дөньяда тынычлык тотрыксыз һәм болгавыр заманда бик кыйммәтле караш бу. Бүген компания, үзенең төп үсеш юнәлешендә ышанычлы рәвештә алга барып, газ белән тәэмин итү һәм газлаштыру өлкәсендә мөһим проектларны тормышка ашыра, шул исәптән республика өчен зур социаль әһәмияткә ия булган проектларны да.

1990 нчы еллар азагы искә төшә. Шактый авыр еллар, газ өчен түләргә акча юк. Икътисадта бартер мөнәсәбәтләре хөкем сөрә. Әлеге вазгыятьтә республиканың ул чактагы премьер-министры булган Рөстәм Миңнеханов дилбегәне үз кулына алды. Рөстәм Нургали улы ярдәме белән бу тармак сакланып калды, әмма шул чорда мәңгегә сабак алды, һәм газ өчен түләүләр бүген дә предприятиенең өстенлекле бурычларыннан берсе булып тора. Хәзер аны тормышка ашыруга «Газпром межрегионгаз Казан» АҖ югары технологияләрне дә җәлеп итә. Инде менә Сабиров вакытында абонентлар өчен уңайлы биллинг платформасы эшләтеп җибәрелде, интернетта директорның шәхси кабул итү сәхифәсе барлыкка килде. Безне, компания партнерларын исә, элемтәләребезнең яңа югарылыкка күтәрелүе куандыра. Килешүләр төзү процедурасын гадиләштерү булсынмы яки электрон документ әйләнешенең яңа уңайлы системасымы – болар барысы да, чыннан да, эшлекле мөнәсәбәтләргә ачыклык һәм төгәллек кертә, аларның нәтиҗәлелеген арттыра.

Ринат Касыйм улы гомеренең берничә дистә елын нефть-газ химиясе тармагына багышлады. Ун елдан артык ул Татарстан өчен мөһим, алдынгы шушы юнәлеш буенча республика башлыгының киңәшчесе булды. Эре предприятиеләрнең директорлар советларында дәүләт мәнфәгатьләрен яклады. Сабировка хәл итәргә туры килгән проблемаларның әһәмияте һәм мәсьәләләрнең катлаулыгы хакында ул катнашкан проектларга карап фикер йөртергә була. Әйтик, «ТАНЕКО» нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексын һәм «Аммоний» химик ашламалар җитештерү заводын төзү кебек зур проектларга.

«Газпром межрегионгаз Казан» АҖ җитәкчесе вазыйфасына Ринат Сабиров ике ел элек керешә. «Сез – «Межрегионгаз» составында иң яхшы компанияләрнең берсе, әле иң яхшысы булмаса», – дип ачыктан-ачык белдерде «Газпром»ның генераль директоры урынбасары Юрий Пахомовский коллективка яңа директорны тәкъдим иткәндә. Сабиров алдында шактый катлаулы бурыч тора иде: уңышка ирешү кыен, әмма иң яхшы компаниягә килеп, шул уңышны саклап калу – тагын да читенрәк. «Тупланган-җыелганны сакларбыз һәм арттырырбыз», – дип сәламләде ул вакытта Сабиров коллективны. Максат-ниятләр дәрәҗәсе бүген дә бик югары. Һәм без, энергетиклар, моңа бик шат, чөнки безнең эштә газсыз һич булмый.

Хөрмәтле Ринат Касыймович! Сезне ихлас күңелдән туган көнегез белән тәбрик итәм һәм тормыш юлыгызда үзегезгә рухи яктан якын кешеләр, ышанычлы дуслар, чын фикердәшләр – иң масштаблы проектларны бергәләп гамәлгә ашырырлык хезмәттәшләр очравын телим!

Фото: tatar-inform.ru

МАКСАТ – БАЗАР ИХТЫЯҖЫН АЛДАН БЕЛЕП ЭШ ИТҮ

«Алга бару өчен, базар ихтыяҗларын алдан белеп, тиз һәм сыйфатлы итеп эшләргә, дөрес һәм төгәл төзелгән стратегиягә ия булырга кирәк», – дип кыска һәм анык шәкелдә әйтеп бирде бер әңгәмәдә үз предприятиесенең шигарен Казан моторлар төзү берләшмәсе генераль директоры **Дамир Кәримуллин**.

Илнур Сәгъдиев,
«Казанкомпрессор-маш» АҖ идарәче директоры

Фото «Казанкомпрессормаш» АҖ тарафыннан бирелде

Төгәл билгеләнгән стратегия, мөгаен, Казан моторлар төзү берләшмәсенең көндәшлектә төп өстенлекләреннән-дер. Мондый стратегиягә ия булу исә тулысы белән диярлек предприятиене ике дистә елга якын җитәкләгән Дамир Җәүдәт улы казанышы икәне әйтмичә дә аңлашыла.

Хәзерге заман шартларында технологияләрне даими камилләштереп тормыйча, җитештерү эшен оештыруның алдынгы алымнарын кертмичә, нәтиҗәгә ирешеп булмый. Дамир Кәримуллин – әлеге хакыйкатьне чынбарлыкта һәрдаимраслый торган җитәкчеләрдән.

Дамир әфәнденең алдан күреп эшли белүе, мөһим бурычларны хәл итүгә коллективны туплый алу сәләте икътисад өчен катлаулы вакытта аеруча нык күренә. Мотор төзүчеләрнең импортны алыштыру программасында катнашуы моның анык дәлиле булып тора, ә әлеге программа бүгенге шартларда илебез өчен стратегик әһәмияткә ия. Без, компрессор ясаучылар, әлеге программаны тормышка ашыруда уңышка ирешүнең никадәр авыр булуын, җитәкчеләр, конструкторлар, технологлар, барлык коллективка аның нинди җитди таләпләр куюын үз тәҗрибәбездә беләбез. Аның каравы, кыенлыклар аша ирешкән нәтиҗәләребез дә саллы, бу сүзләр мотор төзүче хезмәттәшләребезгә дә кагыла, алардан башка алга барып булмас иде.

Уңышлы җитәкче – кагыйдә буларак, идарә итү таланты, белем багажы һәм новаторларча фикерләү осталыгы гына түгел ул, производствоны энәсеннән җебенә кадәр белү дә. Россиянең атказанган машина төзүчесе, хезмәт юлын КАМАЗда гади слесарь-ремонтчы булып башлаган һәм һөнәри үсеш баскычлары буйлап республикадагы иң эре предприятиеләрнең берсендә генераль директор вазыйфасына кадәр күтәрелгән Дамир Җәүдәт улы Кәримуллин – нәкъ менә шундый җитәкчеләрдән. Дәүләт бүләкләре һәм «Ел җитәкчесе-2021» республика конкурсының «Инновацияле эшчәнлектәге казанышлары өчен» номинациясендә лауреат исеме моны ачык дәлилли.

Хөрмәтле Дамир Җәүдәтович!

«Казанкомпрессормаш» АҖ коллективы исеменнән чын күңелдән юбилеегыз белән котлыйм!

Сезнең җитәкчелек талантыгыз, аналитик фикерләү сәләтегез һәм бетмәстөкәнмәс энергиягез Татарстаныбызны үстерү өчен куелган максатларга ирешүдә һәрвакыт ярдәм итсен. Сезнең барлык планнарыгыз да тормышка ашсын. Сәламәтлек һәм уңышлар Сезгә!

Акциянең срогы 2022 елның 16 маеннан 2022 елның 20 сентябренә кадәр. Заявкалар 2022 елның 15 августына кадәр кабул ителә. Оештыручы «ТАТМЕДИА» АҖ. Реклама 16+.
Товарлар рәсемдә тәкъдим ителгәннән аерылырга мөмкин.

[redacted]

КИҢ КОЛАЧЛЫ КАМЫЛГА ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ

[redacted]

ДИСКЛЫ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ

[redacted]

БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ

[redacted]

БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ

[redacted]

Фотолар «Агромастер» җитештеру компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ: ИСТАНБУЛДАН СӘЛАМ!

– Истанбулда ел саен уздырыла торган 11 нче халыкара журналлар күргәзмәсендә иң популяр басма «Татарстан» журналы булды, – ди «Татмедиа» АҖ PR-директоры Ләйсән Сафина. – Төрледән-төрле юнәлешләргә караган, төрле аудиториягә исәп тоткан бик күп журналлар арасыннан күргәзмәгә килүчеләр нәкъ менә «Татарстан»ны яраттылар – битләрен ача-ача укыдылар һәм, һичшиксез, журналны тотып фотога төштеләр.

Фото: Ләйсән Сафина

– Беренче чиратта Төрек Республикасы тәкъдим иткән журналлар саны таң калдырды – 450 төрле! – дип дәвам итә Ләйсән Сафина. – Алар арасында балалар, хатын-кызлар өчен, әдәби журналлар, тагын да таррак юнәлешлеләре – мисал өчен, робот техникасы, диджитал it буенча журналлар, чигү эшенә багышланганнары, альманахлар... Мисыр, Гарәп Әмирлекләренең туристлык, психология, әдәбият темаларын яктырта торган журналлары да бар иде. Элеккеге союздаш республикалардан – Азәрбайҗан, Кыргызстан, Казахстан катнашты... Россиядән өч республика үз продукциясен тәкъдим итте – Татарстан, Башкортостан һәм Чувашия. Күршеләр фонында безнең республика, 10 журнал тәкъдим итеп, күргәзмәдә бик саллы күренде. Башкортостаннан ике басма – «Ватандаш» һәм «Агыйдел», Чувашстаннан өч балалар журналы килгән иде. Әлбәттә, болай аз күләмдә катнашу төбәкнең журналлар базары турында да, республиканың үзе турында да тулы күзалларга мөмкинлек бирми.

Күргәзмә Истанбулның Сиркеджи дип аталган тарихи тимер юл вокзалында урнашты. Әлеге мәйданчыкка беренче мәртәбә әләгеп, мин бераз борчылдым да: килүчеләр булырмы, үз аудиториябезне күрә алырбызмы? Әмма күргәзмә көннәрендә (8–12 июньнәр) кеше бик күп килде. Ләкин бу туристлар түгел, нәкъ менә Истанбул халкы, бу калада яшәүче диаспора һәм җәмгыять вәкилләре. Алар арасында биредә озак вакытлар гомер итүче татарларны да, бу шәһәрдә әле күптән түгел кенә яши башлаган яшьләрне дә күрдек. Һәрберсе безнең журналларны зур кызыксыну, ярату белән карады, чөнки бу ерак ватаннары – Татарстаннан бер сәлам кебек кабул ителде. Журналларны кулга тотып карыйсы, битләрен актарасы, укыйсы килә, диделәр алар. Алар безнең стенд фонында фотога төштеләр, һәм бу вакытта һәрвакыт кулларына «Татарстан» журналын алдылар. Шуңа күрә «Татарстан»ның Истанбул фотолары бөтен дөньяга таралды, дип әйтеп була.

Күргәзмәнең төп оештыручысы, Халыкара коммуникаторлар ассоциациясе президенты Шәмсетдин бәй Куздеджи болай дип билгеләп үтте: «Татарстан» журналының күргәзмәбездә беренче мәртәбә катнашуы безнең өчен бик күңелле. Без Татарстан Республикасында журналлар эшчәнлеген игътибар белән күзәтеп барабыз һәм алга таба да уңышлы хезмәттәшлеккә өметләнәбез. «Татарстан» журналы аерым игътибарга лаек, дип билгеләп үтәсем килә, бу аның тышлыгы, эчтәлеккә бай контенты буенча да күренә. Басмада күтәрелгән һәр тема үз укучысын таба. Журнал коллективына уңышлар, яңа темалар һәм укучылары санының артуын телим!»

– Журнал коллективына уңышлар, яңа темалар һәм укучылары санының артуын телим! – диде күргәзмәнең төп оештыручысы, Халыкара коммуникаторлар ассоциациясе президенты Шәмсетдин бәй Куздеджи.

– Төрледән-төрле юнәлешләргә караган, төрле аудиториягә исәп тоткан бик күп журналлар арасыннан күргәзмәгә килүчеләр нәкъ менә «Татарстан»ны яраттылар – битләрен ача-ача укыдылар һәм, һичшиксез, журналны тотып фотога төштеләр, – диде «Татмедиа» АҖ PR-директоры Ләйсән Сафина.

PRESSA

KazanExpress